# Казан утлары

10 ОКТЯБРЬ 1967





*Без кабызган утлар*
*сүнмәс алар,*
*Сүнмәс алар*
*хәтәр җилләрдә!*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

10
ОКТЯБРЬ
1967

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

— — □ — —

*Әнвәр Давыдов*

## *Октябрь кояшы*

1

Җәй. Кызларның энҗе-көмеш елмаюы өстенә
бакчалардан тамып төшә кып-кызыл пешкән чия.
Көн оркестрыннан шатлык уйната кояш-маэстро,
Идел-салават дугасында күккә үрли җилкәнчеләр.

Комбинезонлы яшь илаһлар, алиһәләр,
җирдән күккә йөретеп грацияле кулларын,
ап-ак оҗмах сала пыяладан, кирпечтән.
Зур мәйданда касә-мәрмәр:
Алсу төнбоек —
Мәңгелек ут
талпына, көн яктысына кушып яфрак-ялкыннарын.
Скверда бишек. Бала биталмасына ал нур төшкән.

2

Кеше нурдан тизрәк менә
галәмнәргә, Зөһрәләргә.
Тик иң биек тирәкнең дә
тамыры җирдә, тамыры җирдә.
Шкалада «50» тулды.
Без биектә. Җир күренми.
Кузгалган җир онытылдымы!
Бусагасыз түр түрмени!!

«Күзгә төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил елый,
Җил еламый, ач үлемнең куркусыннан ил елый...»

Онытылдымы соң бу зар-моң! —
Карлы Рәсәй сахрасында
салкын юллар. Халыкларның
киндер капчык — аркасында.
Бара халык кулын сузып
патша сарае катына.
Аның тиреннән ядрә коеп,
аны ук патша аттыра.

Кап-кара силләр шикелле акты яшь, акты газап,
Күкрәде болытлары бер бәрелешеп, ялкын ясап.

Бары да туа хәрәкәттән.
Айкалды халык ачуы,
Оешты бер ядрәгә, һәм
Октябрь кояшы туды.

Хәрәкәте көчләрен шул чор, халыкларның җыеп,
Илтте Ильич ил корабын, өр-яңа мотор куеп.
Кара янып сызлаган җирдә бурлаклар җилкәсе
Таң — кызыл юл сызды беренче Идел флотилиясе.
Канлы сәнәк япьләре... Төннәрдә обрез утлары...
Көнбатышка ирләрен озаткан тол авыл йортлары...
Күп кичердек... Тик өметсезлеккә бирмәде урын,
Партиябез — Ленинныбыз күрсәтеп торды юлын.
Үрлибез өскә. Үтелде иң җаваплы юл башы,
Көчлерәк балкый җиһанга Октябрьның кояшы.

3

Җир кояшны җентекләп күзәтә:
Кояштагы һәр хәрәкәт тәэсир ясый җир климатына
көнен дә, төнен дә.

Кара төнле баһадирларның кызыл каннары
Кайнап торган корыч булып тама
Америка тәненә. Көньяк Африка тәненә.
Кошмарлы төн. Төн бик авыр.
Тик кояш бар. һәм таң атар...

Бәрәкәтле ямь-яшел кырларын Вьетнамның күмеп
Китмәкче кара коллык ташкыны, Көнбатыштан килеп...

Израильләрнең мең ел әрле-бирле сугылуыннан
сугылган акча алтынга
напалм сатып алып, Якын Көнчыгышны
ничек урамакчы ханнар ялкынга!..

Әмма кояш бар.
Ул кара сил аккан җирләрне киптереп, бакча итә.
Ялкын ургылган сахрага тере сулы болыт илтә.

Бар җиһан якты кояшны җентекләп күзәтә.
Таң күтә.

1967.

— — □ — —

*Фарваз Миннуллин*

# ЯКТЫ ЮЛЛАР СЫЗЫП

*(Татар совет әдәбиятының үсеш этаплары)*

Кешелек җәмгыяте тарихында зур борылыш пунктлары, ашкын эпохалар була. Шуларның иң зурысын, иң ашкынын Бөек Октябрь революциясе ачып җибәрде. Революция капитал дөньясының, сыйнфый һәм милли изүгә корылган иске җәмгыятьнең нигезен җимерде. Илебез җир шары халыклары гасырлар буе хыял иткән яңа җәмгыять — коммунизм җәмгыяте төзү юлына чыкты.

Кешелек җәмгыяте тарихында әдәбият, сәнгатьнең шаулап чәчәк аткан чорлары була. Ярты гасыр вакыт эчендә без узган данлы юл мәдәният тарихына шундый эпоха булып керер. Әле 1905 елда ук, яңа, социалистик әдәбиятның үзенчәлеген һәм асыл бурычларын билгеләп, В. И. Ленин болай дигән иде: «Бу азат әдәбият булачак, чөнки ул рәхәткә туйган героиняга түгел, эч пошудан һәм симезлектән җәфа чигүче «өстәге ун меңнәргә» түгел, бәлки илнең чәчәге, аның көче, аның киләчәге булган миллионнарча һәм ун миллионнарча хезмәт ияләренә хезмәт итәчәк. Бу азат әдәбият булачак, кешелекнең революцион фикеренең соңгы сүзен социалистик пролетариатның тәҗрибәсе һәм җанлы эше белән җимешләндерәчәк, үткәннең тәҗрибәсе... белән хәзергенең тәҗрибәсе (эшче иптәшләрнең хәзерге көрәше) арасында үзара даими тәэсир булдырачак».

Чыннан да, революция иректе әдәбиятның, халык арасыннан чыккан талантларның үсүе өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр тудырды, язучы белән дәүләт, язучы белән халык арасындагы элекке мөнәсәбәтләрне тамырдан үзгәртеп корды. Революция мәдәният үсеше тарихында яңа дәвер башлап җибәрде.

Ленин һәм аның партиясе иҗат кешеләренә якты юллар сызып бардылар. Партиябез совет сәнгатенең торышына төпле бәя бирә торды, әдәбият һәм сәнгать әһелләре алдында торган мөһим мәсьәләләрне кузгата килде, безнең алга баруыбызны һәм совет сәнгатенең үсешен тоткарлаган тискәре күренешләрне тәнкыйть итте. Шундый житди һәм эшлекле ярдәм, даими кайгыртучанлык, иптәшләрчә принципиаль тәнкыйть сәнгать кешеләрен, шул исәптән язучыларны да, яңа иҗат уңышларына рухландырып торды.

Октябрь революциясе элекке мирасның иң яхшы традицияләрен үзенә алган бердәм совет әдәбияты, күпмилләтле әдәбият тудыру өчен җирлек әзерләде, патша Россиясендә изелеп яшәгән милләтләргә үз сәнгатьләрен, үз әдәбиятларын үстерү өчен уңай шартлар тудырды. Союздаш һәм автономияле республикалардагы «сәнгать эшлеклеләренең күп кенә талантлы яңа әсәрләре киң Бөтенсоюз аренасына, юк, Бөтенсоюз аренасына гына да түгел, бәлки халыкара аренага да чыкты. Бездә сәнгать һәм әдәбиятның теге яки бу өлкәсендә бик шәп казанышлары, күренекле талантлары белән горурланмый торган бер генә республика да юк» [1]. Моны үзебезнең татар әдәбияты мисалында да бик ачык күрергә мөмкин.

Ярты гасыр вакыт эчендә, халык хуҗалыгының башка тармакларындагы кебек үк, татар совет әдәбияты үсешендә дә алга таба кискен сикереш ясалды. Әдәбиятыбыз зур яңарыш, үсү процессы кичерде. Аның социалистик чынбарлык, халык тормышы белән бәйләнеше тирәнәйде, тематикасы төрләнде, идея һәм сәнгать камиллеге

---

[1] Л. И. Брежневның партиянең XXIII съездында сөйләгән докладыннан.

үсте, чикләре киңәйде, авторитеты бик нык күтәрелде. Татар язучылары әдәбиятны тирәнтен аңлый һәм тоя белүче үз мәңнәрчә укучы тәрбияләделәр, Бөтенсоюз һәм дөнья киңлекләренә чыгарлык дистәләрчә роман-повестьлар, сәхнә әсәрләре, шигырь-поэмалар иҗат иттеләр. Татар совет әдәбияты узган юл ачышларга шулкадәр бай: илле ел эчендә язучыларыбыз ирешкән уңышларның зурлыгын, бөеклеген бөтен тулылыгы, киңлеге һәм тирәнлеге белән хәтта күз алдына китерүе дә кыен.

* * *

Татар совет әдәбияты тарихы гражданнар сугышы елларыннан башлана. Әнә шул авыр елларда, ут, дары төтене эчендә революция алып килгән яңалыкны сурәтләүгә багышланган беренче әсәрләр — революцион җырлар һәм шигырь-поэмалар язылган.

Халыкны эчке һәм тышкы дошманнарга каршы рәхимсез көрәшкә күтәрелергә өндәгән, революция казанышларын яклап һәм саклап калырга чакырган бу әсәрләрне, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Бабич, И. Йосфи, Ш. Фидаи, Г. Харис, К. Әмири, Ә. Сәгыйди, С. Сүнчәләй, З. Ярмәки, С. Кудаш, Н. Исәнбәт кебек әдипләр белән бергә, кызыл сугышчылар, укытучылар, эшчеләр һәм игенчеләр иҗат иткән. Кызганычка каршы, ул авторларның күбесен без хәзер бөтенләй белмибез. Гражданнар сугышы елларында чыккан газета-журнал битләрендә псевдонимы, исем-имзасы ачыкланмаган күпме шагыйрь, никадәр поэма онытылып-чәчелеп ята...

Дөрес, бүгенге әдәбиятыбыз күзлегеннән торып хөкем иткәндә, ул еллар поэзиясеннән һәртөрле җитешсезлекләр, кимчелекләр табарга мөмкин.

Әйе, гражданнар сугышы елларында язылган әсәрләрдә тотып, капшап карарлык, тере, җанлы образлар юк диярлек, күп кенә әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре шактый зәгыйфь. Абстракт хисләр, риторика ташкыны астында күмелеп калган поэзия әсәрләрен дә байтак табарга була.

Әмма, шуның белән бергә, ул чор әдәбиятының үз матурлыгы, үзенә генә хас үзенчәлекләре, көчле яклары бар. Төрле архив, китапханә шүрлекләрендә тузанга күмелеп яткан иске газета-журнал подшивкаларын эзләп табыгыз да кулыгызга алып карагыз. Алар кулны пешерә, аларда басылган әдәби әсәрләрдән гражданнар сугышы елларының кайнар сулышы бәрелеп тора. Революцион пафослары, ашкынулы романтика һәм героик оптимизм хисләре белән көчле ул әсәрләр. Канлы сугыш кырларында иҗат ителгән әнә шул әсәрләргә революция уяткан яңа кешенең, яңа герой образының теләк-омтылышлары, ихтыяр көче, бунтарь рухы сеңеп калган.

Гражданнар сугышы елларындагы поэзия татар совет әдәбиятының алга таба үсешенә көчле йогынты ясады. Фронт кырларында, ут-төтен эчендә туганга күрә дә, безнең әдәбият гомер-гомергә сугышчан әдәбият, көрәшче әдәбият булып килде.

20 еллар! Иске белән яңаның каты көрәш еллары, искене җимерү, яңаны төзү, төрле «измнар», ялгышлар һәм зур ачышлар ясалган еллар. Романтик ашкынулар, төрле каршылыклар белән тулы давыллы еллар. Ул чорны без әнә шулайрак күз алдына китерәбез. Чөнки әдәбияты шундый аның.

Бу елларда, башка күп кенә мәсьәләләр белән бергә, әдипләр каршына, үзенең бөтен зурлыгы һәм мөһимлеге белән, бер төп мәсьәлә килеп басты. Яңа чорның, социализм эпохасының үз әдәбиятын тудырырга кирәк иде. Шагыйрьләр һәм драматурглар, прозаиклар һәм әдәбият галимнәре миллионнарга аңлаешлы әдәби форма, чорга лаек иҗат методы эзләделәр. Бу исә шактый катлаулы, четерекле һәм кыен мәсьәлә булып чыкты. Бу эшкә кайсы яктан тотынырга, яңа бинаның беренче кирпечләрен нинди нигездә сала башларга?..

Эзләнүләр төрле юнәлештә барды һәм һәр очракта да җиңү белән генә тәмамланмады. Бу юлда әдипләрне тирән упкыннар да, хәтәр чоңгыллар да сагалый иде. Берәүләр, адашып, формализм сукмагына килеп чыктылар, реакцион романтизм җәтмәсенә эләгүчеләр дә булгалады.

Кыен эшләрнең тагын берсе әдәби мираска мөнәсәбәт мәсьәләсе иде. Бу хакта да капма-каршы фикерләр әйтелде. Берәүләр революциягә кадәр иҗат ителгән әдә-

биятны тулысынча кире кактылар, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан мирасын, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал кебек әдипләрнең Октябрьга кадәрге әсәрләрен сызып ташларга чакырдылар. Икенче берәүләр исә иске мирасны тикшерминитми, тулаем килеш пролетариат ягына алуны куәтләделәр.

Әмма ни генә булмасын, ялгышулар, һәртөрле тайпылулар никадәр генә күп күренмәсен, егерменче еллар әдәбияты нигездә дөрес юнәлештә үсте. Әкренләп хаталар төзәлде. Әдәбият алдында торган бурычларны дөрес хәл итә барып, язучылар чорның уңай героен иҗат итү буенча да, миллионнарга аңлаешлы стиль тудыру юнәлешендә дә җитди уңышларга ирештеләр. Татар язучыларына ярдәмгә Габдулла Тукай иҗаты килде, алдынгы рус әдәбияты килде. Маяковский, Горький традицияләренең шифалы тәэсире дә көчле иде.

Әдәби хәрәкәтнең алгы сафында шагыйрьләр барды. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, чорга хас каршылыклар да поэзия өлкәсендә аеруча калку һәм тулы гәүдәләнде. Әдәбият тарихыбызның гаять үзенчәлекле, матур сәхифәләре 20 еллар башында яшәгән һәм иҗат иткән шагыйрьләр катнашы белән язылды. К. Нәҗми, Г. Кутуй, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, М. Җәлил... Саный китсәң, алар бик күп. Шулай да ике шагыйрьне аерым билгеләп үтәргә кирәк. Аларның берсе — Мәҗит Гафури, икенчесе Һади Такташ иде. Егерменче еллар поэзиясендәге иң зур фигуралар — шулар икәү.

Җитди кимчелекләре һәм йомшак яклары булуга да карамастан, егерменче еллар татар поэзиясе тәэсир көченең зурлыгы, сугышчан рухы белән аерылып тора. Ул поэзия мещанлык моралена, дини фанатизмга, нэпманнарга туктаусыз һөҗүм итте, капитализм җәмгыятенә, аның черек законнарына, һәртөрле искелеккә каршы рәхимсез ут ачты [1].

Драматургия өлкәсендә дә иҗади эзләнүләр барды, кызыклы ачышлар ясалды, социализм чорының конкрет күренешләрен чагылдырган үзенчәлекле әсәрләр язылды. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр», Ш. Усмановның «Канлы көннәрдә» һәм Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» исемле драмаларында, К. Тинчуринның «Американ», «Җилкәнсезләр» кебек комедияләрендә, М. Фәйзи һәм Ф. Бурнаш, Һ. Такташ һәм Т. Гыйззәт пьесаларында чорның сулышын, егерменче елларга хас тенденция һәм омтылышларны шактый тулы күзалларга була.

Революция алып килгән яңалыкны киңрәк, тулырак чагылдыру теләге торган саен үсә, көчәя барды. Бу — язучыларны зур күләмле эпик полотнолар иҗат итәргә этәрде. Егерменче елларның икенче яртысыннан проза әдәбияты җанланып китте. Зур-зур романнар, повестьлар, озын хикәяләр күренә башлады. Яңа кеше образын иҗат итү юлында кызыклы омтылышлар ясалды («Кызыл чәчәкләр», «Тирән тамырлар», «Рәуфә» һ. б.). Әмма бу чор прозасы һәр яктан килгән, эпик бөтенлек алган типлар бирде, дип әйтеп булмый. Югары таләпләргә җавап бирерлек чын сәнгать әсәрләренең күбесе үткән тормышка, капитализм җәмгыятен фашлауга юнәлдерелгәннәр иде. «Кара йөзләр», «Казакъ кызы» кебек, әдәбиятыбызның алтын фондына кергән гүзәл сәнгать әсәрләре шул елларда язылды.

Бу чор әдәбиятының һәм гомумән совет әдәбиятының иң зур вәкиле — Галимҗан Ибраһимов иҗатына киңрәк тукталасы килә. Галимҗан Ибраһимов мирасының әһәмияте киләчәк буыннарга калдырган хикәя, повесть һәм романнар саны белән генә билгеләнми. Безгә ул үз мәктәбен, үз иҗат стилен тудырып калдырды, социалистик реализм әдәбиятын тудырып калдырды.

Беренче карашка, аның һәр әсәре үзенә башка яңа бер дөнья кебек. «Кызыл чәчәкләр» «Тирән тамырлар» романыннан нык аерылган кебек, «Безнең көннәр» белән «Казакъ кызы»н да янәшә куеп булмый. Тема-проблемага, алынган материалның характерына карап, һәр әсәрдә образлар да, сюжет-композиция төзелеше дә башкача, яңача. Ләкин, игътибар беләнрәк караганда, ул әсәрләрнең хикәяләү алымында, образлар иҗат итү принципларында Галимҗан Ибраһимов кулы, Галимҗан Ибраһимов стиле ярылып ята. Галимҗан Ибраһимов каләме киң массаларны, зур иҗтимагый коллективларның көрәшен тасвирлауда тиңдәшсез иде. Ул үз әсәрләрендә бөтен бер

---

[1] Татар совет әдәбияты тарихы. Казан. 1960 ел. 78 бит.

халыклар язмышын, бер иҗтимагый хәрәкәт аша миллионнар язмышын бирергә омтылды. Эпик киңлек, зур иҗтимагый хәрәкәтләр аның әсәрләренең геройлар составын да билгеләде. Төгәл булмаган исәпләүләрдән чыгып кына караганда да, «Безнең көннәр» романында 130 дан артык, «Тирән тамырлар»да 60 лап образ-персонаж бар. «Яңа кешеләр» драмасында катнашучылар саны да шуннан әллә ни ким түгел.

Шунысы аеруча кызыклы, күп кеше катнашкан массовый сценаларны аның әсәрләрендәге иң уңышлы кисәкләрдән санарга була. «Безнең көннәр»дәге Дума алды җыелышын һәм мәдрәсә чуалышларын, «Яшь йөрәкләр»дәге солдатка алу күренешләрен, «Яңа кешеләр» драмасының икенче пәрдәсен, «Кызыл чәчәкләр»дәге ашлык сугу өмәсен, «Казакъ кызы»ндагы үлек күмү, кымыз, ит мәҗлесләрен генә алып карагыз! «Тирән тамырлар»дагы суд залы һәм суд барышы үзе генә ни тора! Никадәр җанлылык, динамика, табигыйлек, тормыш сулышы аларда!

Галимҗан Ибраһимов каләменең гомумиләштерү һәм тасвир көче гаять югары булуын әйтергә кирәк. Ул кечкенә мәйданнарда зур вакыйга сыйдыра, бик аз вакыт эчендә бөтен бер иҗтимагый хәрәкәтнең җанлы сурәтен тудыра ала. Шуңа күрәдер, ахры, аның әсәрләре бик тиз башланып, җәелеп китәләр дә. Иң күбе 10—15 бит, иң азы берничә җөмлә укыгач, сез инде Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең эченә керәсез, шундагы кайнап торган тормыш стихиясенә бирелгән буласыз.

Әдәби телнең нинди могҗизалар тудыра алуын белергә теләгән кеше Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен күбрәк укысын. Музыкаль симфония кебек аның теле. Ул тел настроение тудыра, тон ясый, рәхәтлек бирә. Әгәр сез, «Безнең көннәр»не укыганда, татар дөньясына, диңгез дулкыннары кебек шаулап, революция килүен, «Казакъ кызы»нда дала киңлеген, дала кояшы кызулыгын тоясыз икән — моның өчен сез Галимҗан Ибраһимовның гаҗәп бай, музыкаль теленә бурычлы. Әсәренә, алынган материалның характерына карап, искиткеч җылы, якты лирик та, кырыс, шомлы да ул тел. «Тирән тамырлар» романы: «Ф ә х р и н е  ү т е р е п  т а ш л а д ы л а р» дигән җөмлә белән башлана. Һәм шушы бер җөмләдән генә дә әсәрнең бөтен ритмикасын тоярга, сөйләнәчәк вакыйгаларның характерын сизенергә була. «Кызыл чәчәкләр» әсәренең зур уңыш казануы, һичшиксез, Галимҗан Ибраһимов теленең матурлыгына да бәйле.

Үз заманында да, соңгарак та Галимҗан Ибраһимов иҗатының татар совет әдәбиятына тәэсир көче гаять зур булды. Татар совет прозаиклары иҗатын, татар прозасының алга таба үсешен Галимҗан Ибраһимов мирасыннан аерып карау мөмкин түгел. Һәм ул тәэсир бер татар әдәбияты белән генә дә чикләнми. Галимҗан Ибраһимов иҗаты казакъ, кыргыз, башкорт, әзербәйҗан язучылары өчен дә тәҗрибә мәктәбе булды.

20 еллар прозасының күп кенә үзенчәлекләре тагын бер язучы — Ш. Усманов иҗатында шактый ачык һәм тулы чагылып калган. Ш. Усманов иҗаты язучының үз биографиясеннән, реаль тормышта ул үзе күргән вакыйгалардан, үзе кичергән хәлләрдән аерылгысыз. Ул белгәнне, күргәнне генә язган. Аның әсәрләренең тормышчанлык сыйфаты, ышандыру көче шуннан килә. Революциягә кадәрге тормышка багышланган хикәя һәм пьесаларында фабрика эшчеләре, шәһәр тормышы. Бу тормышны иң тулы тасвирлаган әсәрләренә мисал рәвешендә «Беренче адым» пьесасын китерергә була. Революциядән соңгы тормышка караганнарында — гражданнар сугышы. «Легион юлы» шул темага багышланган әсәрләр арасында иң җитешкәне, иң әһәмиятлесе.

Бер группага кергән әсәрләрендә еш кына уртак геройлар, уртак эпизодлар очрый, бер үк вакыйгалар кабатлана. Беренче карашка, Ш. Усмановның күләмле әсәрләре аерым эпизодлар җыелмасын хәтерләтә кебек. Аларда эшләнгән образлар да күренми, буйдан-буйга килүче үзәк бер вакыйга, конфликт, сюжет линиясе дә юк шикелле. Ләкин бу тыштан караганда гына шулай тоела. Чынында исә аның әсәрләрендәге менә бу характерлы эпизодлар җыелмасы күзгә күренми торган җепләр белән аерылмаслык итеп тоташтырылган, беркетелгән була. Аерым кисәкләрне, таркау күренгән эпизодларны бер үзәккә җыючы автор, мещанлыкның, бюрократизмның теләсә нинди чагылышларына кискен отпор бирүче, революциягә чын күңелдән бирелгән революционер образы бар аларда. Мещанлыкка көчле нәфрәт — Ш. Усма-

нов әсәрләрендә кызыл җеп кебек буйдан-буйга сузылып килүче төп мотив, шул хис аларны бөтен итә, шул хис аларны сәнгать әсәре итә.

Әгәр Ш. Усманов әсәрләрендәге иксез-чиксез энтузиазмны, революция эше өчен чын күңелдән яну һәм ашкынулы романтиканы, революцион рух һәм пафосны, мещанлыкка, бюрократизмга көчле нәфрәт хисләрен истән чыгарсаң — аның әсәрләре таркау, аның иҗатында эшләнгән образлар юк, аның иҗатына башка күп төрле кимчелекләр хас. Әгәр 20 еллар прозасының шул төп сыйфатларын игътибарга алмасаң, бу проза көчсез, йомшак. Инде шул көчле якларын искә алып хөкем йөрткәндә, очеркчлык, типик образлар булмау — бу чор прозасының кимчелеге түгел, ә үзенчәлеге булып чыгар. 20 еллар әдәбиятының көчле яклары соңыннан бөтен совет әдәбиятының, социалистик реализм методының да аерылмаслык сыйфатлары булып киттеләр.

Шуннан 30 еллар килде.

Бу елларда проза әдәби процессның алгы линиясенә чыкты, үсү, җитлегү дәрәҗәсе ягыннан поэзия һәм драматургия белән тигезләнде.

30 еллар озын хикәя һәм повесть жанрының чәчәк атуы белән характерлы. Дөрес, берничә роман да дөньяга чыга. Арада иң уңышлысы — Ш. Камалның «Матур туганда» романы. Кызганычка каршы, бу әсәрнең бүгенге көнгә кадәр үзенә лаеклы бәя алганы юк.

Поэзия төп ике юнәлештә үсә. Беръяктан, зур күләмле эпик поэма активлаша. Колхозчы крестьяннар һәм эшчеләр, кызыл сугышчылар һәм интеллигенция тормышына багышланган, мораль, әхлак проблемаларын күтәргән дистәләрчә поэмалар басылып чыга. Шуның белән бергә, поэзиянең кечерәк күләмле төрләре — җыр, романслар күбәя.

Бу исә язма поэзия белән халык авыз иҗаты арасындагы бәйләнешләрне тагын да көчәйтеп, үстереп җибәрде. Язма әдәбиятка, мул булып, фольклор традицияләре үтеп керде. Шагыйрьләр халык әдәбиятын, андагы тел һәм образлар байлыгын өйрәнүгә күп көч куйдылар, үз әсәрләрен халык авыз иҗаты элементлары белән баеттылар. М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, Н. Баян, Ә. Исхак, С. Хәким, Ш. Маннур кебек шагыйрьләрнең фольклор традицияләрен өйрәнеп язган әсәрләре халык арасында зур популярлык казанды.

Драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә шундый ук җанлылык хөкем сөрде. Хәер, татар совет балалар әдәбиятының чын-чынлап активлашып китүе 30 еллардан гына башлана да, дияргә мөмкин.

30 еллар әдәбиятына хас үзенчәлекләр һәм тенденцияләр аз өйрәнелгән. Хәлбуки, бу — шактый үзенчәлекле һәм кызыклы чор.

**«Кайда өзеклек, кайда эш бармый, анда сыйнфый дошман кулы тыгылган булыр».** Бу сүзләр М. Әмирнең «Безнең авыл кешесе» исемле әсәреннән алынды. Аларны егерме биш меңче колхоз председателе, коммунист Бикташев әйтә. Аның шул сүзләрендә 30 еллар әдәбиятының төп үзенчәлеге, төп пафосы чагыла.

20 еллар белән чагыштырганда, беренче бишьеллыклар әдәбиятының тематикасы да, идея эчтәлеге һәм образлар системасы да нык үзгәрә. Әдәбият заман темасына йөз белән борыла. Социалистик индустрия эшчеләре һәм колхозчы крестьяннар тормышы бу чор әдәбиятының төп темасына әйләнә. Язучылар промышленность предприятиеләрендә, шахталарда, төзелеш участокларында, колхоз-совхоз кырларында булалар, язылачак геройлары белән очрашалар, җанлы тормыш эчендә кайныйлар. Бу — аларга идея-политик яктан чыныгырга булыша, тормышны тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

30 еллар әдәбиятында чорның уңай героен иҗат итү юлында уңышлы адымнар ясала. Мисал рәвешендә, Ш. Камалның «Матур туганда» романын, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ын, Г. Бәшировның «Сиваш»ын, М. Әмирнең «Агыйдел»ен, һ. Такташ, Х. Туфан, Ф. Кәрим, Ш. Маннур, Н. Баян, С. Хәким, М. Җәлил поэмаларын, К. Тинчурин, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт, Г. Иделле пьесаларын һәм башка күп кенә уңышлы әсәрләрне күрсәтергә мөмкин.

Нинди иде ул герой, аңа нинди сыйфатлар хас иде? Бу еллар әдәбиятының төп уңай геройлары: җаны-тәне белән социализм төзү эшенә бирелгән, революция

интересларын барыннан да өстен санаучы большевик, эшче, крестьян, кызылармеец. Җәмгыять интереслары өчен, социализм интереслары өчен, шулар бәрабәренә ул герой шәхси бәхеттән баш тартырга да, үз шәхси интересларын корбан итәргә дә риза, кыенлыклар, мохтаҗлыклар күрергә дә әзер. Ул геройның без күбрәк социализм өчен көрәш юлында йөргән чагын күрәбез, аның белән күбрәк коллектив хезмәт процессында, көрәш процессында очрашабыз.

30 елларда иҗат ителгән күпчелек әсәрләр җыйнаклык, әдәби бөтенлек, кискен драматизм, укучыга булган эмоциональ тәэсир көченең зурлыгы, активлыгы белән характерланалар, алар конфликт бөтенлеге, конфликт кискенлеге белән аерылалар.

Шушы көчле ягыннан ук бу чор әдәбиятының, әгәр шулай әйтергә ярася, бер кимчелеге, җитешсез ягы да килеп чыга. Бу елларда иҗат ителгән кайбер әсәрләрдә җанлы кеше образы машиналар тавышы астында күмелеп калгалады. Андый әсәрләрнең авторлары, кеше хисләре турында сөйләүдән бигрәк, социализм төзү, машина ясау, күмер чыгару, колхозлар төзү турында сөйләделәр. Образларда «иҗтимагый» як «шәхси» якны каплап китте. Беренчелек иҗтимагый якка — көрәш, төзелеш мәсьәләләренә бирелде.

Инде язучы күпмедер күләмдә геройларның шәхси кичерешләренә, эчке доньяларына керергә мәҗбүр була икән, аларны да ул сыйнфый көрәш идеалларына буйсындыра иде. Моннан хәтта иң талантлы язучылар да котыла алмады. М. Әмирнең «Агыйдел» повестенда комсомолец Ильяс кулак кызы Мәһибикәне ярата, ләкин сыйнфый көрәш идеаллары хакына ул бу мәхәббәттән баш тарта. Г. Толымбайның «Куян солдат» әсәрендә ярлы кызы матур Мәһибәдәр, сыйнфый дошманның чын йөзен ачу өчен, кулак малаена кияүгә чыгарга ризалык биргән булып кылана. Мондый мисалларны драматургиядән дә, поэзия өлкәсеннән дә байтак китерергә мөмкин.

Бу, әлбәттә, шул заманның үзенчәлекле шартлары, әдәби-эстетик карашларның үсеш дәрәҗәсе белән аңлатыла торган күренеш иде. Әмма ни генә булмасын, «иҗтимагый» якка артык зур игътибар бирү әдәби образларның тәэсир һәм ышандыру көчен киметте, җанлы типлар иҗат итүдә билгеле бер схематизмга китерде. Андый әсәрләрнең уңай геройлары ярата, сөя, кайгыра, шатлана белүче тулы канлы җанлы образлар булудан бигрәк, идеяләр колы булып күз алдына басалар.

30 елларда завод-фабрикалардан, колхоз кырларыннан, төзелеш мәйданнарыннан әдәбиятка бик күп яшьләр килде. Бүген илледән узган, алтмышка җиткән язучыларыбызның күбесе әдәби хәрәкәткә шул еллардан актив катнаша башладылар. Әдәбиятның зур өлеше әнә шул яшьләр тарафыннан иҗат ителде. Бу чор әдәбиятының көчле һәм кимчелекле яклары турында хөкем йөрткәндә, мәсьәләнең бу ягын да истән чыгармаска кирәктер, мөгаен.

Сугыш башланды. 1917 елдагы кебек үк, әдәбият яңадан ут, давыл эченә, канлы көрәш кырларына күчте, нәфрәт ташкынына әйләнеп, дошманга каршы күтәрелде. Әнә шул авыр сынау көннәрендә татар әдәбияты халык белән бергә атлады, тагын бер мәртәбә Ватанга тирән мәхәббәт хисләре тәрбияләүче сугышчан әдәбият булуың раслады.

Бар җырымны илгә багышладым.
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Барыбызга да таныш бу шигъри юллар — Муса Җәлилнеке. Бу юллар патриот шагыйрьнең безнең көннәрдә чыккан барлык җыентыкларына кертелгән. Бу юллар безнең күңелләргә язылган.

Әгәр доньяның төрле почмакларында, чит-ят җирләрдә ятып калган солдат-әдипләр — әсәрләре миллионнарча кешеләр тарафыннан сөелеп, яратып укыла торган танылган, зур шагыйрьләр; менә бу якты җир йөзен, аның иксез-чиксез киңлекләрен, мәһабәт тауларын туйганчы, рәхәтләнеп бер карап калырга да өлгермәгән, язылмаган хикәя һәм повестьлары, поэма һәм романнары калган яшь язучылар — бер генә минутка баш күтәреп, телгә килә алсалар иде... Алар беравыздан:

— Әйе, Муса безнең уй-теләкләребезне бик тегәл, бик матур итеп әйткән. Без җырларыбызны да, гомеребезне дә туган илгә багышладык, — диярләр иде.

Искиткеч талантлы шигырь-поэмалар иҗат итеп калдырган Ф. Кәрим дә, ялкынлы публицист Г. Кутуй да, күренекле балалар язучысы А. Алиш та, Австрия кырларында ятып калган татар шагыйре, подполковник Н. Баян да, фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән патриот шагыйрь Х. Мөҗәй дә шул ук сүзләрне кабатлар, шул ук фикерне куәтләр иде. Алар шуны үзләренең үлемнәре белән расладылар.

Сугыш елларында әдәбиятның бөтен жанрлары, татар язучыларының барысы да — окопларда-гылары да, тылдагылары да — фронт өчен эшләде. Яшь аермалары, сәләт һәм талант дәрәҗәләре, әдәбиятыбызны баетуга керткән өлешләренең күләме төрлечә булуга карамастан, татар совет әдипләренең барысы да бер бөек максат — Ватан иминлеген саклау өчен көрәштеләр.

Даһи Ленин төзегән данлыклы Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә күп милләтле совет әдәбияты да, үзен барлыкка китергән һәм үстергән совет җәмгыяте белән бергә, фашизмга каршы авыр көрәш сынауларыннан җиңүче булып чыкты, үзенең зур адымнар белән яңа күтәрелешкә баруы юлында тулы бер эпоха узды [1].

Сугыш тәмамлануга, халык җимерелгән авыл, калаларны, промышленность предприятиеләрен торгызу эшенә кереште. Совет язучылары алдына да тормыш яңа таләпләр куйды, аларга яңа бурычлар йөкләде. Язучылар ул бурычларны мөмкин кадәр тулырак, яхшырак үтәү өчен көчләрен кызганмадылар. Әдәбият, сәнгать өлкәсендә яңа күтәрелеш чоры башланды. Әдипләребез тарафыннан актуаль темаларга багышланган, зур күләмле бик күп әсәрләр язылды.

Сугыштан соңгы әдәбиятның уңышлары безнең күз алдында. Моны барыбыз да беләбез, күреп торабыз. К. Нәҗминең «Язгы җилләр», «Г. Бәшировның «Намус», Ә. Фәйзинең «Тукай», Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», «Газинур», «Сүнмәс утлар», М. Әмирнең «Саф күңел», И. Газиның «Онытылмас еллар», «Гади кешеләр», Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Ә. Еникинең «Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», Г. Гобәйнең «Замана балалары» кебек повестьлары, күп санлы хикәяләр сугыштан соңгы прозаның характеры, колачы һәм күләме хакында хөкем йөртергә бай материал бирәләр. Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Фәйзи, С. Баттал, Ш. Маннур, Ш. Мөдәррис, З. Мансур, Ә. Ерикәй, Г. Хуҗи, М. Садри һәм башка шагыйрьләр күп кенә поэмалар, лирик шигырьләр яздылар. Драматургия өлкәсендә Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, М. Әмир, Р. Ишморат, Г. Насрый кебек әдипләрнең иҗаты аеруча уңышлы һәм нәтиҗәле булды.

Сугыштан соңгы елларда татар әдәбияты яңа темалар, яңа идеяләр, яңа образлар белән баеды. Әдәбиятта тормышчан образлар тудыруга, геройларның эчке тормышын тулы һәм дөрес ачуга омтылыш көчәйде.

Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил поэзиясе, «Тапшырылмаган хатлар», «Язгы җилләр», «Намус», «Алтын йолдыз» кебек әсәрләр татар әдәбиятын дөнья аренасына алып чыктылар.

Соңгы ун ел илебез тормышының барлык тармакларында барган тирән үзгәрешләр белән характерлы. Партиябез Үзәк Комитеты җитәкчелектә ленинчыл нормаларны һәм принципларны яңадан тормышка кайтарды. XX съездан соң урнашкан иҗади атмосфера гел ныгый, гел көчәя барды.

Илебез тормышындагы уңышлар әдәбиятыбыз, сәнгатебез үсешенә дә уңай йогынты ясады. Иҗат кешеләре өчен киң мөмкинлекләр, яңа горизонтлар ачылды.

Бүгенге татар әдәбияты бертуктаусыз үсә һәм ул үсеш, беренче чиратта, әсәрләребезнең сыйфаты күтәрелү хисабына бара. Язучыларның әдәби осталыклары артты, чынбарлыкны фәлсәфи үзләштерү куәтләре көчәйде. Алар бөтен ил күләмендәге проблемаларга багышланган, зур иҗтимагый конфликтларга корылган әсәрләр иҗат итү югарылыгына күтәрелеп киләләр...

Без күреп үттек: әдәбият тарихының төрле баскычларында аерым жанрларның үсеш дәрәҗәсе төрлечә булган. Бер чорда поэзия алга китә, әдәби процессны шагыйрьләр җитәкли. Икенче бер вакыт бу вазифаны драматурглар башкара. Бүгенге әдәбиятта проза алданрак бара. Проза әдәбиятының үз эчендә исә соңгы 7—8 елда повесть жанры аеруча активлашып алды. Танылган өлкән прозаикларыбыз һәм яшь

[1] Татар совет әдәбияты тарихы. Казан. 1960 ел. 445 бит.

авторлор тарафыннан бик күп яңа повестьлар иҗат ителде. Ә. Еники белән Р. Төхфәтуллин гына да татар әдәбиятына дистәгә якын повесть бирделәр. И. Гази, Ф. Хөсни, Г. Минский, С. Баттал, Н. Дәүли, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, башка күп кенә язучыларыбыз бу жанрны үстерү, камилләштерү эшенә зур өлеш керттеләр. Нинди сәбәпләр повестьларның шулай активлашып китүенә китерде соң әле? Күп инде алар. Шулай да төп сәбәпне чынбарлыктан, тормыштан, аның үзенчәлекләреннән эзләргә кирәктер. Партиянең XX съездыннан соңгы еллар нәкъ менә повесть жанры өчен күп уңай шартлар тудырды. Илебез тормышында булып узган күп төрле яңалыклар, зур үзгәрешләр язучыларга бай иҗат материалы бирде. Яңа проблемалар һәм темалар, өр-яңа мәсьәләләр күбәйде. Хикмәт аларның күплегендә генә дә түгел. Барыннан да бигрәк, алар гаять актуаль һәм үтә җитди иде. Күбесенчә хәзер үк, бүген үк беренче җавапны да бирергә кирәк иде. Язучылардан темп, оперативлык соралды. Һәм проза әдәбиятының әндый актуаль мәсьәләләрне хәл итү өчен иң кулай жанрларыннан берсе булган повесть активлашты.

XX съездан соңгы әдәбиятның тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге повестьлар активлашуда зур роль уйнады. Әдәбият гади кешеләр белән, аларның язмышы белән ныграк кызыксына башлады. Язучылар замандашларыбызның тулы канлы, тормышчан образларын тудыру юлында күп тырышлык күрсәттеләр. Ә кеше характерын, кеше психологиясен тасвирлау өчен бу жанрның зур мөмкинлекләре бар.

Шуның белән бергә, соңгы вакытта көчәеп килүче икенче бер тенденцияне дә онытырга ярамый. Роман жанры, тормышның бүгенге, актуаль мәсьәләләренә багышланган романнар активлашып килә. Укучылар Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», Ш. Маннурның «Муса», И. Салаховның «Күкчәтау далаларында», А. Расихның «Язгы авазлар» һәм «Ике буйдак», Г. Ахуновның «Хәзинә», Н. Фәттахның «Бала күңеле далада», Э. Касыймовның «Гомер ике килми», М. Хәсәновның «Саф җилләр» һәм башка яңа романнар белән таныштылар. Дөрес, элеккерәк елларда да халкыбыз тормышының үткәне һәм бүгенгесе турында әйбәт кенә романнар язылып торды, басылып торды. Әмма бу кадәр түгел иде. Татар совет прозасы бүгенге көннең яңа, үзенчәлекле, бик актуаль проблемаларын роман кебек зур, катлаулы жанрда сурәтләү юлында яңа бер баскычка күтәрелде дигән сүз бу.

Әйе, прозабыз бик нык үсте, камилләште. Моңарчы безнең әдәбиятта авыл темасы гына тулырак яктыртылып килә иде. Хәзер безнең фән һәм вузлар, интеллигенция һәм эшчеләр тормышына, семья, әхлак, мораль һәм башка темаларга язылган әсәрләребез күп. Язучыларыбыз схематизмнан һәм максатсыз тасвирлаулардан, иллюстрациядән арынып киләләр. Бүгенге прозада күтәрелгән, хәл ителгән, чишелгән проблемаларны санап чыгу өчен генә дә зур урын, күп вакыт кирәк булыр иде. Типик образ иҗат итү принциплары тагын да яңарды, баеды, төрләнде.

Шундый ук хәлне поэзия өлкәсендә дә күрергә мөмкин. Поэзиянең колачы киңәйде, укучыга булган тәэсир көче артты. Бүгенге поэзия һәрберсенең үз тавышы, үз стиле булган уннарча талантлы шагыйрьләр көче белән иҗат ителә. Х. Туфан, С. Хәким, С. Баттал кебек өлкән буын шагыйрьләр үзләренең яңа әсәрләре белән безне әледән-әле куандырып торалар. Ш. Галиев, Г. Афзал, И. Юзеев, С. Сөләйманова, Х. Камаловлар артыннан Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Г. Рәхим кебек яшь буын шагыйрьләр үсеп чыкты.

Драматургия күзгә күренерлек уңышларга ирешә. Р. Ишморат, Х. Вахит, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев, С. Кальметов пьесаларында яңа, әһәмиятле темалар һәм проблемалар күтәрелә.

Балалар әдәбияты өлкәсендә эшләүче язучыларыбызның иҗат җимешләре дә куандырырлык. Г. Гобәй, Җ. Тәрҗеманов, Л. Ихсанова, Ә. Бикчәнтәева, Г. Бакир һәм башка уннарча әдипләребез нәни укучылар өчен бик күп шигырьләр һәм поэмалар, хикәяләр һәм повестьлар, пьесалар яздылар. Татар совет балалар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре СССР халыклары телләренә һәм чит телләргә дә тәрҗемә ителә бара.

Әдәби тәнкыйтьнең һәм әдәбият фәненең үсеше елдан ел киңрәк колач ала бара. Соңгы берничә ел эчендә генә дә күренекле әдип, шагыйрьләребез иҗаты турында зур-зур монографияләр язылды, борынгы татар әдәбиятын һәм татар совет әдәбия-

тын өйрәнүгә багышланган тарих китаплары чыкты, әдәбиятыбызның аерым чорлары турындагы фәнни хезмәтләр дә ел саен күбәя тора. Аеруча куандырганы шул: әдәбият мәсьәләләре буенча язылган хезмәтләрнең ышандыру көче, фәннилек дәрәҗәсе артты, галимнәребез торган саен батыррак була баралар, тикшерүчесен көтеп яткан зур, кыен темаларга кыюрак алыналар. Бездә хәзер һәр яктан әзерлекле әдәбият галимнәре үсеп җитте, чын мәгънәсендәге фән өлгереп килә.

Шулай итеп, Бөек Октябрьның илле еллыгын татар совет әдәбияты зур уңышлар белән каршылый.

* * *

Илле ел эчендә әдәбиятыбыз гаять бай, гыйбрәтле үсеш юлы үтте. Әдәбият үсешендәге һәр яңа баскыч сыйфат үзгәрешенә китерде, татар әдәбиятының алтын фондына керерлек әсәрләр калдырды. Әгәр илле ел эчендә әдәбиятыбыз ирешкән ачышларның һәм сыйфат үзгәрешләренең төп асылы нидән гыйбарәт дип сорасалар, бер сүз белән:

— Әдәбиятны чынбарлыкка, кеше тормышына якынайтуда,— дип җавап биреп булыр иде. Әйе, илле ел эчендә татар совет әдәбияты даими һәм эзлекле рәвештә тормышка, кешегә якынная барды.



*Иске дөнья безгә кирәк түгел,*
*Күккә очсын аның көлләре,*
*Алтын аллаларга үчле күңел,*
*Кирәк түгел патша түрләре.*
*Без барыйк ярдәмгә мазлумнарга,*
*Без барыйк ачларга, ярлыга,*
*Ләгънәтләр яудырып явызларга,*
*Без чыгыйк көрәшкә, давылга.*

*„ЭШЧЕ МАРСЕЛЬЕЗАСЫ"*

## *А. И. Ульянова-Елизарова*

# КАЗАНДАГЫ ТОРМЫШ

Арча кырыннан ерак булмаган Беренче тауда, Орлова йортындагы флигельдә квартира алдык. Квартирабызның балконы һәм тау битендә матур гына бакчасы бар иде. Беренче катта нигәдер ике кухня, ә калган бүлмәләр өске катта иде. Кухня өстәге бүлмәләргә караганда тынычрак һәм укыр өчен уңайлырак булганга, Володя үзенә икенче, ягъни артык, кухняны сайлап алды. Ул анда күп кенә китаплар кертеп куйды һәм көннең күп өлешен китап укып шунда үткәрә иде. Биредә ул Карл Маркс «Капитал»ының 1 томын өйрәнә башлады.

Шуны хәтерлим, кичләрен, аның янына сөйләшеп утырырга төшкән чагымда, ул миңа Маркс теориясенең нигезләре турында һәм бу теория ача торган яңа горизонтлар турында бик кызып һәм дәртләнеп сөйли торган иде. Газеталар җәелгән плита өстенә утырган килеш кулларын селки-селки сөйләгәне хәзергедәй хәтеремдә. Аңардан ныклы ышаныч аңкый һәм бу аның белән сөйләшеп утыручыларга да күчә иде. Шул вакытта ук инде ул үзенең сүзе белән ышандыра һәм мавыктыра белә иде. Шул вакытта ук ул, берәр нәрсәне өйрәнеп, яңа юллар тапканда, шулар турында башкалар белән уртаклашмыйча, башкаларны үз ягына тартмыйча калмый иде. Андый тарафдарларны, шулай ук марксизмны өйрәнүче һәм революцион фикерле яшь кешеләрне ул тиздән Казанда тапты.

Безнең семья махсус күзәтү астына алынганлыктан, бу танышлар безгә килмиләр иде диярлек, алар җыела торган квартирага гадәттә Володя үзе бара иде. Ул телгә

алган фамилиялардан ике кешене генә — олы яшьләрдәге народоволец Четверговны (аның турында Володя бик яратып сөйли торган иде) һәм студент Чириковны гына (университеттан чыгарылганмыдыр — анысын белмим) хәтерлим; ул беллетрист-язучы булып китте, соңыннан революциядән читләште һәм хәтта дошманнар лагерена күчте. Владимир Ильич әнине кайгыга салмас өчен шактый сак эш итә иде. Александрны югалту бәхетсезлеген әнинең гадәттән тыш батыр кичерүе хәтта чит кешеләрдә дә гаҗәпләнү һәм хөрмәт тудырды. Без, балалар, моны аерүча нык сиздек, ул безнең өчен, безнең турыда кайгыртып үзен бик зур ихтыяр көче белән тыеп тора иде. Надежда Константиновнаның миңа әйтүенә караганда, Владимир Ильич аңа да әнием Александрны, ә соңрак сеңелем Ольганы югалтуны әни искиткеч батырлык белән кичерде, дип сөйләгән.

Әнинең безгә йогынтысы бала чагыбыздан ук бик зур булды. Мин бу турыда тулырак итеп бүтән урында сөйләрмен, бирәдә исә Казандагы тормышыбызда булган бер эпизодны гына искә алам. Володя тәмәке тарткалый башлады. Әни, аның сәламәтлегенә зарар килүдән куркып (чөнки бала чагында һәм яшүсмер вакытында ул бик үк таза түгел иде), аны тәмәке тартуны ташларга үгетли башлады. Тәмәкенең сәламәтлек өчен зарары турындагы бөтен дәлилләрне китереп бетергәч, — ә ул дәлилләр, гадәттә, яшьләргә аз тәэсир итә,— әни Володяга, син әле үзең эшләп акча тапмас борын, хәтта бик аз гына булса да (ул чакта без барыбыз да әни пенсиясенә яши идек), артык расходлар тотарга тиеш түгел, диде. Бусы — хәлиткеч дәлил булды, һәм Володя шунда ук — һәм бөтенләйгә — тәмәке тартуны ташлады. Әни миңа бу вакыйга турында канәгатьләнү белән сөйләде һәм, расходлар турындагы дәлилне, әлбәттә, соңгы дәлил итеп китердем, дип өстәп куйды.

Володя миңа кайбер җыелышлар, аларда укыла торган рефератлар турында рухланып сөйли торган иде. Һәрвакыттагыча, язга таба түгәрәк эше активлаша төште, һәм Володя еш кына кичләрен өйдә булмый башлады.

Соңгы вакытларда чыккан тикшеренүләрдән күренгәнчә, ул чакта Казанда берничә түгәрәк булган. Алар, конспирация таләпләре буенча, берләшә, хәтта очраша да алмаганнар. Бер түгәрәкнең кайбер члennары хәтта башка түгәрәкләрнең барлыгын да белмәгән, ә кайберләре, белсә дә, яки сизенсә дә, ул түгәрәкләргә кемнәр керүен белә алмаган. Фамилияләрне бик кирәк булганда гына әйтә торган булганнар. Ул вакытта үзәк түгәрәктә бик актив яшь революционер, нык ышанган социал-демократ Николай Евграфович Федосеев дигән кеше була.

Гимназиянең соңгы классыннан ук чыгарылган Федосеев актив рәвештә революцион эш алып бара башлый. Үзәк түгәрәк каршында легаль булмаган (яшерен) һәм рөхсәт ителми торган китаплардан китапханә оештырыла, ә яздан алып җирле басмаларны һәм сирәк очрый торган яшерен китапларны яңадан бастырып чыгару техникасы җайга салына. Владимир Ильич бу планнар турында ишетә, ләкин үзе ул түгәрәккә кермәгән иде. Ул Федосеевның үзе белән дә якыннан таныш түгел, аны ишетеп кенә белә иде. Ә шулай да, 1889 елның июлендә Казанда булган кулга алуларны ишеткәч, ихтимал, мин дә эләккән булыр идем, диде ул. Федосеев кулга алынган, аның түгәрәге тар-мар ителгән, Владимир Ильич йөргән түгәрәкнең дә кайбер членнары кулга алынган иде. 1889 елның маенда безнең бөтен семьябыз Самара губернасына, Алакаевка авылы янындарак М. Т. Елизаров ярдәмендә әнием сатып алган хуторга күчеп килде; шушы хәл генә Владимир Ильичны коткарып калды. Шул елның көзеннән мин М. Т. Елизаровка тормышка чыкканнан соң, без бөтен семьябыз белән Самарада урнашып калдык.

Шулай итеп, Владимир Ильич Казандагы погромнан очраклы гына котылып калды; бу погром нәтиҗәсендә Федосеев ике ел ярым чамасы гомерен төрмәдә — әлек судка кадәр, ә аннары суд карары буенча «Кресты»да (Петербургтагы Выборг төрмәсе шулай дип атала, төрмәгә хөкем ителгәннәрне шунда ябалар иде) үткәрде. Аулак Самарага күчеп килү Владимир Ильичка марксизмны тыныч лап өйрәнергә, ә соңрак университетка имтихан бирүгә әзерләнергә мөмкинлек бирде. Җәй көнен сәламәтлек өчен бик файдалы, матур урындагы хуторда үткәрү, әлбәттә, аның сәламәтлеген ныгытты.

Н. Габитов тәрҗемәсе.

——□——




*Атилла Расих*

## Роман

### Музыка тынды[1]

Фәрхетдин өй ишеген ачып, муенын сузды. Гажби карчык сәкедә йокы сүтә иде. Әйе, бәхет эзләп Казанга килгән егет шәһәрнең бер очыннан икенче очына сөрелеп йөри торгач, Яңа бистәгә, татар зираты артына ук килеп җитте.

Ул сак кына адымнар белән өй эченә узды да сандык өстендәге чиләктән бер чүмеч су чүмереп алды. Тыгын өй эче күксегән ис белән тулган иде. Карчык мышный-мышный йоклый. Аның мендәр-көрпәсез, ялангач сәке йөзлегендә ятуыннан, баш очында сабы сынган чокыр белән йомры таш шешә торуыннан Фәрхетдин Гажбинең исереп ауганлыгын бик тиз аңлады. Кортка шулай киндер бәлзәм белән шаяргалый иде. Фәрхетдин уртлый-уртлый туйганчы җылымса су эчте дә, җиң очы белән авызын сөртеп, карчык янына сәкегә барып утырды. Кортка йокы аралаш иреннәрен лебердәтеп нидер мыгырданып куйды. Фәрхетдин, күзләрен тасрайтып, сакланып кына киндер бәлзәм шешәсенә үрелде. Мондый нәрсәдән авыз иткәне юк иде әле аның. Тәвәккәлләп, таш шешәнең нечкә муенын авызына таба янтайтты. Кара син карт дунгызны! Шундый әче нәмәрсәне рәхәтләнеп эчә бит! Юк, батмый, мондый эчемлек Фәрхетдиннең күңеленә ятышлы түгел. Менә хәзер алты тиен көмешең булсын иде дә, Обжорный рәткә барып, туйганчы өреле үпкә-бавыр ашы ашасаң иде!

Фәрхетдин, карчыкны бераз күзәтеп торганнан соң, үзе дә кулларын баш астына куеп сәкегә ятты. Ул, түшәмдәге тараканнарга караган хәлдә, акча табу турында баш ватты, аннары күңеле белән авылына әйләнеп кайтты. Сөеп алган Хафазасы ни хәлдә икән, Хафазасы? Әнисе белән тату гына яшиләр микән? Әтисе бик артык ютәлли микән? Язгы каты җилле көннәрне хасталамыйча гына уздырды микән? Соң-

---

[1] Дәвамы. Башы 9 санда.

гы вакытларны якташларын бер дә очрата алганы юк шул Фәрхетдиннен!

Кортка тагы авызын чапылдатып нидер әйтте. Фәрхетдин аның инбашыннан тотып җилтерәтә башлады.

— Әй, Гаҗби әби дим, Гаҗби әби! Тор инде, әнә мәзин азан әйтте, тор!

Карчык бер күзен генә ачып Фәрхетдингә карады. Ул бик каты исерек иде. Торды да, аякларын киң ерып, сәке уртасына утырды; кәефләнеп бармак шартлата-шартлата, яшелле-күкле тавышлар чыгарып, нәни бәбиләрдәй, очына башлады.

— Гаҗби әби, бүген мин бер урыска утын ярыштым. Ул, иртәгә акчасы булыр, диде, әҗәтемне шуннан соң түләрмен, ями, — диде Фәрхетдин.

Ләкин карчыкның колагына дөнья хәлләре кирәклек түгел иде әле. Ул һаман очынуында булды. Керле аксыл яулыгы баш түбәсенә үк менеп җиткән, ә эчкелеккә бирелеп шешенгән бүшән йөзендә гамьсезлек билгеләре иде.

Ул Фәрхетдинне, ниһаять, абайлады. Селәгәйле тешсез авызын ерып көлемсерәп куйды.

— Кайттыңмыни әле син, чукынган зимагур?!

— Гаҗби әби, акча иртәгә була, — диде Фәрхетдин.

Карчыкның йөзе җитдиләнеп китте.

— Шулаймыни? Китер алайса. Мин сине бушлай ашатып яткырырга, син бит Апанай марҗасы түгел.

— Әйтеп торам бит: акча иртәгә була. Әле бирмәделәр. Бүген эшләдем, бер урыс белән утын ярдык.

Карчык өметсез рәвештә кул селтәде дә Фәрхетдингә таба төкереп үк җибәрде.

— Иртәгә турында сөйләргә син ишәкмени?! Җүнсез, дармаеt! Һәр көнне иртәгә дә иртәгә. Ичмаса, сүземне тыңламыйсың, җүнсез мажик чабатасы! Мин әйткән җиргә эшкә керсәң, тамагың тук, өстең бөтен булыр иде.

— Бик тә алама җир бит, Гаҗби әби. Ничек шунда мөселман башым белән эшләп йөрим инде.

— Мөселман, мөселман, ачыксаң керерсең! Рәхмәт әйт, мин сине тыгындырам. Мәнә бик ачуымны китерсәң, типкәләп чыгарырмын әле. Часка әйтеп өтермәгә яптырам мин сине бик ачуым килсә! Тик ачуым гына килми әле.

Утырган җиреннән тагы «эх-эх!» дип сикергәли башлады. Аннан тагы Фәрхетдингә җитдиләнеп дәште:

— Җүләр син, имә?

— Нишләп мин җүләр булыйм. Ничек итеп инде мин оятсыз түтәйләрнең лакан-чиләкләрен түгим, аларның пычракларын тазартып йөрим.

— Ә-ә, синең шулай минем җилкәдә утырасың киләмени? Мин сине, чабата, острукка яптырам! Якташ дип карап тормам.

— Мин бит синнән әҗәткә генә алып торам. Мин синең утыныңны ярмыйммени, суыңны китермиммени?!

— Мәнә, мәнә, син шул эшне тегендә дә эшлисең инде! Әллә бер-бер җиремне кисеп алырлар дип куркасыңмы? Курыкма, сине бик забиднигә кертмәсләр. Күбрәк ишек алдында йөрерсең.

— Анда, Гаҗби әби, эт көненә калмаса, бераү дә керми ди бит. Мин иманымны сатмадым әле. Мин лутчи хәер сорашам анда барганчы.

— Эт көненә калгансың инде син, кыяфәтсез тәре! Кашың кара, күзең кара, үз җаеңны үзең кара алайса. Чык та кит! Синең пычрак чабаталарыңны бик күрәсем килеп тормый әле!

Гажби җәһәт кенә иелде дә идәндә яткан киез катасын Фәрхетдингә атып бәрде. Карчыкның күзләре тонган, салынып торган бит тиреләре ачудан дерелди иде.

— Җаның тәмугка олаксын, эзең булмасын, өемне сасытып утырма, хәзер үк чыгып кит!

Фәрхетдин башын калкытты. Аның хәле чыннан да хәтәр иде. Соңгы салам иде ич бу! Инде булмаса, бәхет дигән нәрсә аңа елмаймый икән, башны иеп, авылга кайтырга гына кала. Хурлыгы ни тора!

Һай-һай-һай! Әллә күзне йомып кортканың киңәшен тотарга микән? Бик тә мактый бит инде зобани карчыгы! Әллә нинди байлыклар вәгъдә итә. Фәрхетдин: «Әйдә, беткән баш беткән», — дип уйланды. Сикереп торды да җиңгәчиләр йортына эшкә керергә риза икәнлеген әйтте.

— Җүләр,— диде Гажби, гадәтенчә ике сүзнең берен оятсыз сүзләр кыстырып. — Син ул җиңгәчәннең изгелекләрен белсәң иде! Тәме бер йөгергәч, үзеңне куа башласалар да, китмәссең әле, шыксыз багана! Ул бит изге җан, ул хаҗда булган кеше, хаҗия! Аның изгелекләрен, тиле, сөйләп бетерә торган түгел.

Иртәгесен алар Кабан күпере аша Суконный бистәсендәге Акком урамына юнәлделәр. Егет Гажби карчыкның яшьлеге җиңгәчиләр кулында үткәнлеген ишетеп белә иде. Ул яшь чакларында гына түгел, инде картаеп беткәч тә шунда йөргән. Бәлки, әле дә шул йорт тирәсендә кайнашыр иде, тик артык әчкечелеккә бирелүе генә аны харап иткән.

Алдан чапан бөркәнгән Гажби карчык атлый иде. Фәрхетдин арттарак уйланып барды. Шулай Устьеда крушник булып йөргәндә бер татар белән дуслашып китте ул. Егет аз сүзле, әмма фиддәй көчле иде. Шул бервакыт исерек баштан елый-елый ул үзенең мәңге төзәлмәслек җан җәрәхәтләрен ачып салды.

Аның сөйгән кызы бер заман шул җиңгәчиләр кулына эләккән. Хәзер инде ул үзенең юньсез эшен ташлап, егеткә кияүгә чыгарга да риза, тик егет аңардан чиркана, аны кешелек сыйфатларын югалткан, үлгән, беткән дип хисаплый икән. Шулай итеп егетнең бөтен язмышы чәлпәрәмә килгән, ул сөйгәнен җуйган.

Хәтерендә, Фәрхетдин шул чакны үзенең Хафазасын исенә төшереп торды. Аннан соң атна буена алладан Хафазаның шундый көнгә калмавын сорап йөрде. Ә хәзер инде нәрсә булып чыга? Хафазасы түгел, ә ул үзе шул йортка таба бара!

Гажби карчык яшел чапан чабуларын җилфердәтеп вак-вак житез адымнар белән йомылып алга таба бара бирә. Әйтерсең лә, Фәрхетдин теләсә аны куып җитә алмый! Егет адымнарын кызулата төште. «Аллага тапшырдык, — дип уйланды, — күрәләтә ачтан үлеп тә булмый бит! Белмәссең, бәлкем әле Фәрхетдин абзагыз көннәрдән бер көнне кәтириңкәне әйбәтләп кенә төреп, кесәсенә салып куяр да, түшне киереп, җырлый-җырлый Нәдергә кайтып китәр».

Шундый татлы хыялларга бирелеп, Фәрхетдин Гажбине куып җитте. Озакламый кортка бер катлы зур агач өй янына тукталды.

— Артта калма, — диде. Зур капкадан елдам гына кереп тә китте. Фәрхетдин эченнән: «Аллага тапшырдык», — дип, биек коймалар һәм зур агач корылмалар белән әйләндереп алынган ишек алдына таба атлады.

Фәхешханә хуҗасы Гайнияне алар ишек алды түрендәге флигельдә очраттылар. Картаюына карамастан, йөзенә кершән-иннекне мул яккан, мич хәтле, карчыга борынлы бу хатынга Фәрхетдинне сынап бер күздән кичерү җитте. Ябык булса да, егетнең җилкәләр киң, куллар таза! Ярыйсы үгез бу! Гайния сүз саен диярлек, күрәсең, гадәтенчәдер, каш сикерткәләп, ярым елмаеп сораша башлады:

— Утын яра беләсеңме?
— Була, — диде Фәрхетдин.
— Ә пүлән ботаклы булса нишләрсең?
— Ботак-чатагы булса, чөй белән ярасың инде.
— Ә чөйне каян алырсың?

Гаҗби пырхылдап көлеп җибәрде. Фәрхетдин, аптырый төшеп, җилкәләрен җыерып куйды.

— Ничек инде?

Күрәсең, хуҗа хатынның теләгәне булды, ул зур эчен тоткан хәлдә ихахайлап көләргә тотынды.

Ләкин болар барысы да кереш сүз урынындагы шаяртулар гына иде әле. Җитди сүз соңрак башланды. Фәрхетдингә нинди эшләр башкарылырга тиешлеге әйтелде, үзен ничек тотарга кирәклеге аңлатылды. Эшнең иге-чиге юк иде. Фәрхетдин шул эшләр саналган чакта бары сүзнең тизрәк бетүе һәм эшкә урнашу турында гына уйланды. Хыялланды да. Менә, ялчы сайлаганда җүнле бай башта ашатып карый ди бит, әллә, бәлкем, бу бикә дә шулай кыланыр. Алай була калса, Фәрхетдин ашап та карар инде бер!

Ләкин хыял хыял булып кына калды. Бикә бу егет тамагын туйдырып килгән дип белде, ахры. Чәй дә тәкъдим итмәде. Шунда ук кухня өчен утын ярырга кушты, аннары ишек алдын себереп алырсың, диде.

Шулай итеп, Фәрхетдин эшкә кереште. Ул ара-тирә ишек алдына чыккалаган, бизәнгән, калфаклы кызларны хәйран калып күзәтте. Кызларның яшьрәкләре Фәрхетдин яныннан тавыш-тынсыз гына, башларын иеп узалар. Ә олыраклары, инде тәмам әрсезлекнең теге ягына җиткәннәре, егеткә оятсыз, яман сүз әйтми калмыйлар. Фәхешханә үзе — урам якка караган зур өйдә. Фәрхетдин беренче көнне үк ул бинада зур бер зал барлыгын белде, аннан исерек авазлар гына түгел, ә моңлы татар музыкасы да ишетелә иде. Нинди әргән икән соң ул? Гармун дисәң, гармун түгел! Фәрхетдин түзмәде, икенче көнне үк пәрдәсе капланып җитмәгән тәрәзә почмагыннан карап торды. Әлбәттә, музыкантның пианинода уйнаганлыгын ул белми иде. Аңа бу уен коралы могҗизанә бер нәрсә булып тоелды. Ләкин, аның каравы, икенче музыкантның скрипкада сыздыртканлыгын ул күрү белән төшенде. Андый каз муенын Нәдердә дә, Казанга килгәч тә күргәне булды аның. Ләкин ул очраткан сукыр музыкантларның скрипкалары күбрәк озынборын безелдәвен хәтерләтә иде. Ә бу скрипка исә адәм баласыдай җырлый, йөрәк тамырларын чымырдатып елый иде. Колагына музыка авазлары кергәндә ирексездән Фәрхетдиннең күз алдына ямьле Зәй буйлары, андагы тугайлар, болыннар, сабый чак белән бергә бәйләнеп истә калган иң бәхетле минутлар килеп баса, гуган-үскән якларны өзелеп сагыну тойгысы туа. Әнә ул яклар! Сөзәк таулар тезмәсе. Урамдагы биек өянкеләр, челтерәп аккан чишмә сулары...

Чын музыканы беренче тапкыр шундый яман агы чыккан юньсез урында ишетүе Фәрхетдиннең күңелен айкалдырып җибәрде. Гүзәллек белән пычраклыкның ни өчендер шулай бер бинада гомер сөрүе хәтта аңа да мәгънәсезлек булып тоела иде.

Ул кайчакларны эш арасында, артык тәкатьсез калып, ишек алдына караган тәрәзә янына бара. Аннан тәмәке төтене, аракы, сыра исләре бөркелә, стаканнар челтерәве, шау-шу һәм сүгенү тавышлары килә. Ләкин шулар арасыннан ук пианино белән скрипкада башкарылган моңлы татар көйләре ишетелә. Көннәрдән бер көнне Фәрхетдин, кыюланып, ачык тәрәзәгә башын тыкты. Музыкантлар тәрәзә янына ук утырганнар, имеш. Алар икәү. Олырагы, сипкеллесе, пианино уйный, ә скрипка тотканы исә — кара тутлы яшь кенә егет. Алар икесе дә кара киемле, икесенең дә башында — хәтфә түбәтәй. Ә залда мәхшәр, анда

вак-вак өстәлләр тирәсендә кешеләр утыра. Барысы да татар агайне, кайсы түбәтәй кигән, кайберсе башына кызыл фәс чәпәгән, майлы киемлесе дә, тәкъва киемлесе дә, европача киенгәне дә бар. Шулар арасында бизәнгән кызлар...

Фәрхетдин аларына бер күз атты — шул җитте. Эчтән генә кызларны хурлап төкереп куйды. Ул күзләрен зур ачып музыкантларга текәлде. Бик рәхәт иде шуларның уйнауларын карап тыңлаулары. Их, менә кухня кешесенең су сорап интектерүе дә булмаса!

Көннәр бер-бер артлы узып, Фәрхетдин, иямәшә төшкәч, күңелләрне тетрәтерлек итеп музыка чалучыларны якыннан ук күрү турында хыяллана башлады. Аныңча, музыка телен белүче кешеләр үзенә бер төрле хикмәт ияләре, сихер осталары, гади кешедән күп өстен затлар иде. Шул ният белән ул чарасына да кереште. Ләкин байтак вакытлар эше барып чыкмады. Ә инде бер көнне бу теләге тормышка ашкач, Фәрхетдин моңа шатланды да, кайгырды да.

Ул көнне кичке якта ук күк йөзен караңгы авыр болытлар каплап алган иде. Күп тә узмады, яшенләп, күк күкрәп яңгыр яварга кереште. Инде бер төркем куе авыр болытлар таралып өлгермәде, көнбатыштан икенчеләре күренде. Алар шәһәр өстен тоташ томаладылар, яңгыр төн буе яварга әзерләнә иде. Мондый төндә Печән базары әһелләренең бу якларга ишелеп килү ихтималы чамалы. Күрәсең, шуңардыр, залда тәртип саклаучы ике агайның берсен бикә башка йомыш белән шәһәр якка җибәрде.

Тик төн тыныч узар дип ул бик ялгышкан икән. Кителмәгәндә моңарчы бирдә күренмәгән сәүдәгәр кыяфәтле бер адәм, яман исереп, җәнҗал куптарды. Башта ул үзенең кампаниясе белән матур гына утырган, һич саранланмыйча, акчаны уңга да, сулга да сипкән, үзе яраткан «Баламишкин»ны музыкантлардан биш тапкыр уйнаткан, барлык кызларны бастырып җырлаткан. Мәгәр соңыннан, тәмам сәрхүшләнеп, тирә-юньдәге кешеләр белән бәхәскә кергән. Бераздан бәхәс җәнҗалга күчеп китеп, теге сәүдәгәр үзе белән телләшеп утырган кешенең яңак төбенә сугып җибәргән. Мондый хәлләр залда булмый түгел иде, шуңа күрә дә анда тәртип урнаштыручы, үгездәй таза ике агай хезмәт итә.

Фәрхетдин ул көнне, каты эшләп, тәмам сөякләре таралган хәлдә, нәрәп йокыга киткән иде. Төн уртасында аны төрткәләп аякка бастырдылар. Тәмам акылын югалтып, кулына ни очраса, шуның белән кунакларны тукмый башлаган исерекне ялгыз агай үзе генә тынычландыра алмый, имеш.

Фәрхетдин залга килеп кергәндә җәнҗалчы бер почмакка кереп аркасын терәгән һәм кулындагы утыргыч белән үзенә ташланырга батырчылык иткән һәркемгә селтәнә иде. Берничәсенә бу тинтәк исеректән эләккән дә инде. Тәртип урнаштыручы Котдус агайга да берне чәпәгән ул.

Фәрхетдиннең куркудан тез буыннары калтыранып китте. Ул, чыгып ычкынудан хәерлесе булмас, дип ишеккә дә күз аткалады. Ләкин бу эшнең ахыры үлем белән бер диярлек иде шул.

— Әйдә, син сул яктан, мин уңнан, — дип пышылдады Котдус. Агайның йөзе агарган, күзләре тонган, ләкин күңелендә сунарчы комарлыгы уянганлыгы күренеп тора иде.

— Гардавуе да күренми бит аның шундый чакны, — дип куйды кемдер.

— Мондый яңгырда йөрергә тилемени алар, — диде икенче берәү.

Залдагы барлык халык, кызыксынып, дуамал исерек тирәсенә җыелган иде. Тәти кызлар куркышып бер почмакка өелгәннәр. Бары музы-

кантлар гына үз урыннарында, бу мәгънәсезлек кайчан бетәр икән дигәндәй, күңелсезләнеп утыралар.

Котырынган сәүдәгәргә Фәрхетдиннең якынлашырга һич исәбе юк иде. Ләкин музыкантларның күзгә чалынуы, аларның шушы җүләр бай аркасында тынып калуы егеткә уйланмаган кыюлык бирде. Һәрхәлдә, ниндидер эчке бер аваз аңа, шушы үзең гашыйк булган ике кешегә син яхшылык эшләргә тиеш, дия иде.

— Алайса мин уңнан чыгыйммыни? — дип сорады ул Котдустан.

— Мин уңнан, — диде Котдус тупас кына.

— Ярый алайса, — диде Фәрхетдин, — бисмилләһиррәхманеррәхим!..

Ул, бөтен гәүдәсе калтыранган хәлдә, халыкны этеләп исереккә таба бара башлады.

Җәнҗалчы таза гәүдәле, шактый куәтле кеше иде. Аның кап-кара кечкенә күзләрен кан баскан. Берәрсе үзенә дә тондырган, ахры. Чиккән зәңгәр түбәтәе астыннан кан саркып каткан. Бай казакиен салып ыргыткан, жилетчан, сул як кесәдән кендегенә кадәр калын алтын сәгать чылбыры салынып төшкән.

Фәрхетдин белән Котдус, халык боҗрасын узып, сәүдәгәргә якынлаша башладылар. Фәрхетдин Котдустан күзен алмады. Ул нинди гамәл кылса, үзе дә шуны эшләде. Ләкин алай да һөҗүм уңышлы чыкмады. Бай Котдуска тагы бер тапкыр утыргыч белән кундырды, ә Фәрхетдиннең эченә типте. Икесе дә мәтәлеп барып төштеләр. Кайберәүләр хәтта кәефләнеп көлеп җибәрде, кемдер ачы череддек тавыш белән: «Үтерде, кяфер!» — диде. Ләкин Фәрхетдиннең әле алай бик тиз генә үләргә исәбе юк иде. Ул үлсә дә хәзер авыртудан бигрәк гарьлегеннән үләр иде. Егетнең ачуыннан башы чыңлап китте. Ул атылып торды да, халык аңына килгәнче, исерекнең утыргычын тартып алып, башына китереп тондырды. Утыргычның соңгы аягы да шартлап сынды. Кемдер: «Сөбханалла!» — дип куйды. Бай исә, бераз вакыт иләс-миләс килеп торганнан соң, гөрселдәп идәнгә ауды.

— Афәрин! — диде берәү Фәрхетдингә кул изәп.

Кемдер:

— Син нишләттең байны, йөзең кара! Үтерде бит, бәдбәхет! — диде.

Аяксыз утыргыч һаман Фәрхетдин кулында иде әле. Кузгала башласа, җәнҗалчыга тагы сугыйм микән дип тора иде. Ләкин янында гына әйтелгән сүзләр аны айнытып җибәрде.

— Башыңны өтермәдә черетәчәкмен мин синең, мәлгунь, әгәр абыйга ул-бу була калса, — диде бая «үтерде бит» дигән кеше. Кемдер йөгереп кухня яктан чиләк белән су алып чыкты һәм байның канлы башына су коя башлады.

— Ә сез, әфәндем, юкка бу егеткә яныйсыз, — диде баягы «афәрин» дигәне, — ул бары үзенең вазифасын гына башкарды. Рәхмәт аңа.

— Синнән сорамыйлар, тар балак, — диде теге байның энесе.

— Афәрин, афәрин, йөз кәррә афәрин! Ул булмаса, барыбызны имгәтеп ташлар иде ерткыч.

Байны яклаучы, хәзергә ачуын йотып, идәндә ухылдап яткан исерек янына иелде. Шул чак Фәрхетдин арттан үзен мактап «афәрин» дип торган кешегә борылды. Тегесе исә дустанә елмаеп, аңа күз кысты. Ул европача киенгән, үзе дә әйтеп бетергесез чибәр: янып торган кап-кара күзле, сызылып киткән кара мыеклы. Җитмәсә, беләзекләрендә манжет һәм муенында үрә катып торган ак яка. Ул янында торган шәкертчәрәк киемле шадра егеткә нидер әйтте дә, сөйкемле генә елмаеп, Фәрхетдиннең уң як иңеннән тотты.

— Әйдә, егет, киттек моннан. Әйдә, бу кабахәтне алып китәрләр әле, мин сине сыра белән сыйлыйм.

Фәрхетдин тетрәнүеннән айнып җитмәгән иде әле, тегенең әйткәннәренә сүзсез буйсынды. Алар өчәүләшеп музыкантлар янындагы өстәлгә таба юнәлделәр.

— Шул кирәк ул кан эчкечләргә! — диде әлеге кеше, һаман Фәрхетдиннең батырлыгын күз алдында тотып. — Исемең ничек синең, егет?

Фәрхетдин исемен әйтте дә кеше мактап торганда бераз туарылмый кала алмады.

— Мин әле аны кызганыбрак... — дип куйды.

— Шулаймы?

— Шулай булмый ни! Ул эчкә типкәндә мин карап тора алмыйм инде. Үзе лә бит Котдус абыйның башына утыргыч белән томырды. Мин әле аны кызганыбрак суктым. Юкса...

— Җиткән монысы да, Фәрхетдин, — диде чибәр кеше. — Әнә бит әле дә аңына китерә алмый аптырыйлар.

Алар өчәүләшеп өстәл тирәсенә утырышканда, извозчик килгәнлеген хәбәр иттеләр. Теге җәнҗалчы байны иптәшләре күтәреп алып чыгып киттеләр.

— Җаны җәһәннәм, — дип куйды чибәр кеше, — бик әтәчләнгән иде!

— Әйтмә инде, барлык кешедән батыр булып кыйланган иде, мәлгунь, — диде моңарчы тын гына утырган шадра егет. Нәкъ шул чакны беләгенә тастымал аскан половой күренде. Ул биегәндәй көяз генә басып килде дә өстәлгә озын шешәләр тезеп китте. Фәрхетдиннең күзләре уйнарга әзерләнүче музыкантларга күчте. Чибәр кеше сыраны бокалларга коеп:

— Яле, батыр егет, безнең танышу хөрмәтенә берне күтәреп җибәрик әле,— диде.— Мин Җәгъфәр дигән кеше булам, ә бу абыең,— ул иптәшенә күрсәтте, — Баһрам атлы була.

Фәрхетдиннең ул кадәр исе китмәде.

— Менә мин карап торам да очына чыга алмыйм, — диде ул бокалдагы сырадан авыз иткәч. — Бер карасаң, бу абыйлар нәкъ теге гадәти кеше сыман, ә үзләре ничек өздертәләр. Минем гомеремдә мондый нәмәрсәне күргәнем юк иде.

— Син музыкантларны әйтәсеңме? — дип сорады Җәгъфәр.

— Музыкантмыни алар?

Җәгъфәр дә, Баһрам да көлеп җибәрделәр.

— Шул музыкантлар булмаса, — диде Җәгъфәр, — әллә син безне, олы башыбызны кече итеп, яман аты чыккан шушы урынга килер иде дип уйлыйсыңмы? Аңла, татар баласы, милли моңнарыбызны без бары фәхешханәдә генә ишетә алабыз.

Җәгъфәр бокалларга тагы сыра салды да җитди сүзне дәвам иттерү өчен Фәрхетдингә таба борылды. Ләкин Фәрхетдин шул дәрәҗәдә музыка белән мавыккан иде, Җәгъфәр, елмаеп, әйтер сүзен йотты.

Музыка тынгач, Фәрхетдин, үз алдына сөйләнгәндәй:

— Их, көнозын шуларны тыңлап утырыр идем. Хәтта төннәрен дә йокламас идем, — диде. Ләкин Баһрам белән Җәгъфәр арасында җитди сүз башланды. Алар егетнең әйткәннәренә игътибар итмәделәр.

— Әгәр кызыксынасың икән, мин әйтә алам, — диде Җәгъфәр Баһрамга шыпырт кына,— мин әле генә Ленинның «Шаг вперед, два шага назад»ын укып чыктым. Мин бу турыда Хөсәен белән дә бәхәсләштем.

— Минем ул китапны укыганым юк, — диде Баһрам, — тик мин синең Хөсәеннән ераклашуыңа гына аптырыйм. Сезне су белән дә аерырлык түгел иде. Мин бит сезнең Мөхәммәдия мәдрәсәсенә бергәләп килеп йөргәнегезне бик әйбәт хәтерлим.

— Нишлисең, бик якын дус иде дә... — дип куйды Җәгъфәр кулларын җәеп.

— Белмим, мин бу мәсьәләләрдә бик надан, — диде Баһрам.

— Әйдәгез әле, — диде Җәгъфәр, — бокалны күтәрик.

Ләкин Фәрхетдиннең бөтен игътибары һаман музыкага кадакланган иде.

— Аңлый микәнни бу егет, ә? — дип сорады Баһрам музыкантларга ымлап, — әллә болай гына... сәерсенеп кенә микән?

— Аңлый, аңлый, ул бит молодец! — диде Җәгъфәр, күз кысып. Ул кәефләнә төшкән иде.

— Абый, менә шул сыраны скрипка сыздыртучыга бирим микән әллә? Рөхсәтме, — диде кинәт Фәрхетдин. — Минем шул абыйны сыйлыйсым килә.

— Калдык-постык эчеп йөрүче түгел ул сиңа, — диде Баһрам ачулана төшеп. Фәрхетдин чатак сүз әйтүен аңлап, кызарып китте.

— Синең музыкантларны сыйлыйсың киләме? — диде Җәгъфәр.

— Мин алар өчен җанымны кызганмас идем, тик үземнең акча юк, — диде Фәрхетдин.

— Хәзер сыйлыйбыз без аларны. Баһрам, синдә әз генә булса да акча булмы? Биреп тор миңа. Мин иртәгә үк кайтарырмын.

Баһрам теләмичә генә куен кесәсенә тыгылды.

— Бар, менә уйнап туктагач та чакыр музыкантларны, — диде Җәгъфәр Фәрхетдингә, акчаны өстәлгә салып.

Фәрхетдин, балалар кебек куанып, музыкантлар янына китте. Халык хәзер кимегән иде, шулай да яңгыр тукталгангамы, я булмаса бая гына барын да өркеткән җәнҗалчы киткәнгәме, залда җанлылык хөкем сөрә. Музыкага кушылып, ара-тирә калфаклы кызларның чыркылдашканы ишетелә, бокаллар чыңлый иде.

Фәрхетдин стенага сөялеп үен беткәнен көтеп торды. Ниһаять, пианино уйнаучы сипкелле кеше инструментка таянган килеш башын учына куеп ял итә башлады, скрипка уйнаучы да ялтыравыклы скрипкасын футлярына салды.

Фәрхетдин кыяр-кыймас кына музыкантлар янына барды.

— Абый, сезнең икегезне дә әнә теге өстәлдә утыручы Җәгъфәр абый чакырган иде.

Бераздан алар бишәүләшеп бер өстәл тирәсенә утырышканнар иде инде. Җәгъфәр, бераз исерә төшкән хәлдә, сөйләп китте:

— Халкыбызның бердәнбер музыкантлары сез, әфәнделәр. Сез аяныч бер хәлдә яшисез. Ләкин шушы фәхешханәдә генә уйнап булса да, безнең моңнарыбызны халыкка җиткерәсез. Моның бер мисале, әфәнделәр, сезнең каршыгызда утыра. Ул менә шушы гади вә садә вә батыр татар егете. Без дә менә Баһрам дус белән сезнең музыкагызга гашыйк. Хәтта бары сезне тыңлау өчен генә бирегә килдек тә. Ләкин менә Фәрхетдин кебек үк сезгә гашыйк булган кешене минем очратканым юк иде әле. Аның гыйшкы әйтеп бетергесез.

Бу сүзләрне ишеткәч, пианист Ситдыйк та, скрипкачы Ибраһим да көлеп Фәрхетдингә борылдылар.

— Нигә соң безне бер дә залга кереп тыңламадың? Мин бит синең бу йортның иң зур түрәсе икәнлегеңне беләм, — диде Ибраһим.

— Ничек беләсең? — диде Фәрхетдин хәйран калып.

— Һәр кичне, без уйный башлагач, тәрәзә төбенә килеп тыңлый ул безне, — диде Ибраһим Җәгъфәргә.

Бу Фәрхетдин өчен һич көтелмәгән бер хәл иде. Музыкантлар мине күрәләрдер дип аның моңарчы һич уйлаганы булмады.

— Мин бәләкәй чактан ук андый саз чалуга әвәс, — дип куйды Фәрхетдин, авызын җыя алмыйча.

— Андый табигатең бар икән, — диде Ситдыйк, — значит, моннан соң һәр көнне безнең янга бер керми калмыйсың инде. Ә нигә анда

ишек алдында гына тынларга, синең мондагы кунаклардан кай җирең ким?

— Эштән соң кирәргә була шул, бикә сүз әйтмәсә, — диде Фәрхетдин.

Ул чын күңеленнән шат иде. Менә бит ничек! Ә ул начар урын дип шушында килергә теләми киреләнеп йөргән иде. Менә бит ул нинди кешеләр белән танышты! И-и, болай булгач, Фәрхетдиннең көннәрен ямьләндерә торган нәрсә табылды!

Ләкин егет ялгышкан иде. Алар шулай күңелле генә утырган чакны кинәт бинаны полиция камады. Бу хәлне аңлау белән, беренче булып урыныннан Җәгъфәр сикереп торды. Ул ачык тәрәзәгә ташланды. Ләкин соң иде. Алар Баһрам белән кайсы тәрәзәгә һәм ишеккә генә ташланмасыннар, һәр җирдә полиция торганлыгы беленде. Халыкка урыннарыннан кузгалмаска куштылар. Кая керергә белмәгән Җәгъфәр белән Баһрамны һәм, бары алар белән бер өстәлдә утырган өчен генә булса кирәк, Фәрхетдинне дә эләктереп частька алып киттеләр.

Фәрхетдингә, һич гаепсез булганы хәлдә, бер атна төрмәдә ятып чыгарга туры килде. Ә Җәгъфәр белән Баһрамны тоткынлыкта калдырдылар.

Фәрхетдин кайтканда көн матур, аяз иде. Ул үзенең иреккә чыгуына куанып, дәртләнеп, ашкынып кайтты. Ләкин ишек алдына узып өлгермәде, Котдус аны утын сараена алып керде дә тәшвишләнеп сөйли башлады:

— Үзеңне яңадан төрмәгә утыртканчы тай моннан, егет, — диде. — Ярый, монда булмадың, юкса Хөснетдин бай сине эзләтеп йөрде. Ул үзенә кул күтәрүеңне гомергә онытачак түгел.

Фәрхетдин өчен аерата шунысы үкенечле иде: ул бит моннан соң беркайчан да Ибраһим беләнСитдыйкның уенын ишетмәячәк! Шулай музыка тынды дигән сүз.

## Тизрәк Казанга, Казанга!

Хөсәен куркыныч төш күреп, йөрәге авыртуына уянып китте. Чыннан да йөрәк җилкенмәслек түгел иде: ниндидер кара сакаллы явыз бер кеше катырак тоткач та уалырга торган нәфис хрустальдәй яшь кызны камчы белән яра. Юньләбрәк караса, бу кыз Хөсәеннең сеңелесе, имеш. Болай да туган сеңелесе исенә төшкән саен Хөсәеннең йөрәге әрни иде. Мондый минутларда ул үзенең зур гаделсезлеккә, ахмаклыкка юл куюы турында уйлап газаплана иде. Бу төш күрү утка керосин сибү кебек булды.

Хөсәен өйдә юк чакны була бу хәл. Аның сеңелесен яучылап Әлмәт бае — икмәк җыючы Якуп Ильясов — кеше җибәрә һәм Хәдичәбикә, күп уйлап тормастан, шул байга кияүгә чыгарга үзе ризалык бирә.

Хөсәен бу хәбәрне Казанга кайткач ишетте. Нишләргә белмәстән, сеңелесен акылына килергә үгетли башлады. Ләкин соң иде инде. Һәрхәлдә, ул чак Хөсәенгә шулай тоелды. Ләкин соңыннан аның күңелендә шөбһә туды. Ә бәлки ул бу эшнең ахмаклык икәнен җитәрлек дәрәҗәдә, тиешенчә исбат итә алмагандыр? Хөсәен бу эше өчен үзен һич кичерә алмый башлады. Ниндидер бер чара күрергә кирәк, дигән фикер белән яшәде.

Әле бүген аның күргән төше башта көйдереп алганнан соң аны озак уйланып ятарга мәҗбүр итте. Йокы тәмам качты. Әйе, Хәдичәбикәне тагы бер күреп сөйләшергә кирәк дигән карарга килде ул. Ни булса шул. Мондый мәсьәләдә тирәнтенрәк уйласаң, беркайчан да соң түгел. Өйдәгеләр уянгач, Хөсәен үзенең бүген үк Әлмәткә китәчәген хәбәр итте.

Ләкин Хөсәен шул көнне үк китә алмады. Комитет членнары белән очрашып, алардан үзенә тиешле аңлатмалар, белешмәләр алырга кирәк иде. Әлмәткә баргач-баргач, ул комитет эшен дә башкарырга тиеш...

Ниһаять, уйлаганның өченче көнендә ул мәрхүм әтисенең толыбын киде дә, ямшек атына утырып, ерак юлга сәфәр чыгып китте.

Әлмәткә Чистай аша барасы. Димәк, Хөсәен каенатасында берәр кич кунмый булдыра алмастыр. Аннары андагы ышанычлы кешеләрне күрми китү дә форсаттан файдаланмау булыр иде. Хөсәен юлга чыкканчы ук боларның барысын да җентекләп уйлады һәм тиешле хәстәрен күрде.

Аргы Кабанны үнда калдырып, тауга күтәрелгәч, ул борылып Казанга карап алды. Шәһәр үзенең таш өйләре, еракта аерата күп булып күренгән мәчет һәм чиркәүләре белән гөрләп артта калды. Бераздан соң инде Казан калкулыклар, урманнар артында югалды. Көн әз генә буранлап тора. Хөсәен толып якасы белән битен каплап куйды, кузлада утырган ямшекнең ара-тирә атына чөңгергәләвен, я авыз эченнән генә җыр көйләвен ишеткән хәлдә, уйларына чумды.

Калкулыклар, урман һәм елгачыклар белән бизәлгән туган як. Тирә-яктагы еш-еш күренгән салам түбәле фәкыйрь авыллар. Чуар чакрым баганалары. Һәм кинәт бара торгач күзләрнең явын алып алга килеп баскан колонналы ап-ак таш алпавыт утарлары. Аннан тагы юл читләрендә калган фәкыйрь, хәерче татар һәм урыс авыллары, авыллар, авыллар... Тынлык. Чакрым баганалары. Кинәт бик озакка юлны буып тезелеп килүче олаулы атлар кәрваны. Ул ара да булмый, атларын мичәүләп җиккән почта ямшеге. Аны әллә кайдан сизәсең, кыңгыраулар чыңлавы салкын саф һавада җил уңаена бик ерактан ишетелә. Почта атлары һай-һу белән яннан узып китә.

Кабан исемле авылга җитәрәк, ыжгырып торган аргамакларда нинди дер зур түрә очрады. Хөсәеннең ямшеге атларны юл читенә чак каерып өлгерде. Юкса түрәнең шәп юртаклары тәгаен мескеннәрне бәреп егып таптап китәрләр иде. Җегерҗәй авылы янында Хөсәеннәргә каршы атлы казаклар отряды килеп чыкты. Болар, мөгаен, крестьян чуалышын бастырырга баралар иде. Хөсәен рәхимсез казакларны ачу аша күзәтте. Аның хәтта бу эшне өнәмәвен ямшеккә дә сиздерәсе килде. Тик ямшекнең теле бераздан болай да ачылды. Ул, атлы казаклар киткән якка чыбыркысы белән күрсәтеп:

— Тилерә башлады бит бәндә, арт сабакларын укытырга баралар! — диде.

Хөсәен, дәшмичә, ямшеккә карап алды. Теге исә бай йоклый ахры дип сорау белән текәлде. «Нужа чигеп яшәүче инде юкса, — дип уйланды Хөсәен, — әмма йөзендәге явыз шатлыкны күр син!»

— Әйбәт эшме соң сезнеңчә? — дип сорады Хөсәен.

— Әйбәт булмый ни! — диде ямшек. — Бөтен дөньяны җитлар болгата бит. Байга итагать кылып, алланы онытмыйча гына тырышып эшләсәң, аллаһы тәгалә беркайчан да адәм баласын рәхәтеннән калдырмый.

— Казанда ел саен ачлыктан меңләгән кеше үлә. Шуларның барысы да ялкау микәнни?

— Кулдагы бармак тигез түгел бит. Адәм баласы да шулай, кемгә ни язылган. Язмыштан узмыш юк, агай-эне.

— Алай икән, — диде Хөсәен, тынып. Әлбәттә, белмәгән кеше белән сак булырга кирәк иде. Охранка соңгы вакытларда бик күп аумакайларны сатып алды. Шымчылык артык ишәеп, көчәеп китте.

Хөсәен әле шушы җәй башында булып узган вакыйганы хәтерләде. Алафузов эшчесе Шәрифулла абзыйларның квартираларында чәй мәҗлесе исеме астында чираттагы түгәрәк утырышы җыелган иде.

Фәкыйрь булса да, бик чиста өй эче. Түр якта чүпрәк палас өстенә җәелгән киндер кызыл ашъяулыкка әзерләнгән табын. Тәрәзә пәрдәләре төшерелгән. Кунаклар ашъяулык тирәсендә чәй эчә-эчә сүз алып баралар. Хөсәен өчен бу «мәҗлес»кә җыелган барлык кеше таныш. Ул инде аларны күптән белә, һәрберсе белән аерым-аерым озаклап сөйләшкәне бар. Ул аларның исемнәрен генә түгел, ничек яшәүләрен, нинди холык иясе икәнлекләрен дә белә.

Хөсәен халык җыелып беткәнче янәшәсендәге абзый белән сөйләшеп утырды. Бу, Җиһанша исемле кеше — Алафузовның күн заводы эшчесе. Иркен күңелле, түгәрәк йөзле, кара сакаллы кеше. Хөсәен белән ул һәрвакыт ничектер оялчан елмаеп, күн буяулары сеңгән кулларына карап сөйләшә.

— Менә бит ничек килеп чыга ул, Хөсәен туган, — диде Җиһанша, — минем кызга Габдесамат мәхдүмнең күзе төшкән, и нәрсә булган: әле тегесе яучы да җибәрмәгән, имеш-мимешләр ишетелү белән, хатын бирик тә бирик дип колак итемне ашый башлады. Менә бит хатыннар!

Хөсәен көлеп куйды.

— Кызыгызны әнисе үзенчә бәхетле итәсе килә, значит. Мәхдүм бит — бай. Тамак тук, өс бөтен булачак. Ләкин кыз ничек карый соң бу эшкә?

— Кыз белми әле, берни дә белми... Әле болай сөйләвем безнең сыйныфый аңның кайчак ни дәрәҗәдә түбән булуын күрсәтү өчен генә.

Тиздән табын тирәсе түгәрәкләнде, килергә тиеш кешенең барысы да җыелды. Хөсәенгә әңгәмәне башларга вакыт икәнлеген әйттеләр. Бирегә җыелучылар — Алафузов эшчеләре. Тукучылар, күнчеләр, шорниклар, кара эш башкаручылар... Хөсәен араларыннан тик бер кешене генә танымый. Ахры, яңа кеше иде. Чандыр гәүдәле, ач яңаклы, капкара кашлары уртада тоташып ук торалар. Әйе, яңа иптәш икән. Хөсәен өчен бу барыбер түгел. Ул аны, әлбәттә, белергә тиеш. Конспирация кагыйдәсе шулай куша.

— Бирредә бер яңа иптәшне күрәм мин. Кем дип белик инде сезне? — диде Хөсәен.

Түгәрәккә йөрүчеләрне инәсеннән җебенә кадәр башта Садыйк тикшерергә тиеш иде. Ышанычсыз кеше монда булырга хаклы түгел. Ләкин шулай да Хөсәен Садыйк аша түгел, ә үзе сорашып белергә теләде.

— Мин ремонтный мастерскойдан. Слесарь, — дип куйды егет. Хөсәеннең сизгер күңеле эшченең интонациясеннән үк нидер тойды.

— Исемегез ничек соң сезнең? — диде Хөсәен.

— Мортаза.

— Күптән эшлисезме Алафузовта?

— Әле икенче ае гына, — диде Садыйк, егет өчен җавап биреп.

— Моңарчы кайда булдыгыз соң?

— Абый дип әйтимме, кордаш дипме, күп йөргән кеше инде мин. Әле Казанга килгәнче Урал якларында себерелеп йөрдем. Булдым Златауста, булдым Миястә, соңгы вакытны, монда килгәнче, значит, булдым Нижний Тагилда.

— Мортаза үзе яшь булса да, дөньяны күп күргән инде, — диде Садыйк.

Хөсәен артыгын сорашмады, ләкин күңеленә беренче танышудан соң ук ниндидер юшкын утыруын тойды. Үткән әңгәмәдә ул кешелек җәмгыятендә сыйныфларның барлыкка килүе турында сүз алып барган иде. Бүген исә әңгәмә феодализмга алмашка килгән капитализм турында барачак. Ул, гадәтенчә, мөмкин кадәр аңлаешлы итеп, сүзен тормыш мисаллары белән бизәп аңлата башлады. Барысы да гадәттәгечә ихлас күңел белән тыңлыйлар иде. Алар аңларга тырыштылар.

Хөсәен Мортазаны да күзеннән ычкындырмады. Ә теге исә бер үзе, башкалардан үзгә буларак, ышанычсыз көлемсери төшеп утыра. Кинәт ул утырган урынында кыбырсый башлады. Ахырда түзмәде:

— Эшчеләр оешырга тиеш дисең дә син, иптәш, — диП куйды, — тик бит андый эшнең ахыры хәерле булып бетми!

— Шулаймы? — диде Хөсәен.— Сез шундый фикердәме? Ә моны ничек исбат итә аласыз?

— Ә мин аны үз шкурамда татыдым. Без Златауста шулай дулап карадык. Арт сабагыбызны бик шәп укыттылар. Менә шул булды. Сез әйткәнчә булмый ул, туган. Әкият сөйләшеп утырудан бернинди дә файда юк монда.

— Ә нишләргә кушасыз соң, иптәш?

— Нишләргәме?

— Әйе.

Мортаза үзенә текәлеп сүз көткән кешеләргә ачу аралаш карап алды.

— Берәм-берәм һәрберсен акылга утыртырга!

— Ничек, террор ясапмы?

— Кем ничек булдыра.

— Юк инде, Мортаза туган, — диде Хөсәен, — без андый юлдан бара алмыйбыз. Монда, минемчә, сезгә социал-революционер әфәнделәрнең карашы йоккан.

Мортазаның йөзенә кан йөгерде, болай да куе кара кашлары тагы да күперенкерәк булып киттеләр.

— Мин сезнең тел төбегезне сизенеп торам, иптәш, — диде ул, — сез эксплуататорларның канэчкеч аждаһалар икәнлеген онытасыз. Онытасызмы, әллә яшерергә тырышасызмы, — бусы да мөмкин.

— Ни өчен мөмкин?

Мортаза елмаеп куйды.

— Сез үзегез дә сәүдәгәр малае түгелме соң? Миңа шулай диделәр. Белмим тагы!

Хөсәен, кашларын җыерган хәлдә, үзен юкка чыгарырга тырышкан Мортазага текәлде. Ләкин җавап бирергә өлгермәде, аны яклап берничә тавыш ишетелде:

— Син, егет, безнең Хөсәенне шельмовать итмә, аны бел, — диде Миңнулла Вахитов. — Син кем дә, ул кем. Без сине беренче тапкыр күрәбез әле, ә ул безнең өчен җанын фида итәргә әзер тора.

Кинәт Мортаза тезләнгән килеш күтәрелде дә кулларын җәеп җибәрде.

— Иптәшкәйләрем! Мин тәпи йөри башлаганнан бирле байларга ялчылык итәм. Инде бер дә яшәргә әмәл калмагач, Себер якларына ычкындым. Мин инде ул Хөсәен иптәш әйткән сыйнфый дошманның кем икәнлеген сезнең барыгыздан да яхшырак беләм. Монда, егетләр, акыл сатышып, гыйлем өйрәнеп утыруның совсем кирәге юк. Байлар безнең каныбызны гомер буена эчтеләр и эчәләр. Чыдар тәкатьләр калмады бит, егетләр! Безгә аларны берәм-берәм менә кандала урынына сытып үтерергә кирәк.

Мортаза еш-еш сулый, күзләре кызарып киткән, артык киеренкелектән куллары дерелди иде. Ул, тыела алмыйча, аты-юлы белән сүгенеп җибәрде. Тыңлаучыларга бу шактый нык тәэсир ясады. Мондый буталчык тудыру остасы белән көрәшүе, әлбәттә, җиңел булмаячак. Ләкин Хөсәен каушап калмады, ул тынычлыгын югалтмаска тырышып, ачык, аңлаешлы дәлилләр китереп, ни өчен террорга юл куелмаска тиешлеге турында һәм ни өчен, меньшевиклар әйткәнчә, дошманны йон уңаена сыпырмаска кирәклеген аңлата башлады. Ул озак сөйләде, тыңлаучыларның йөзләренә карап, ул үзенең җиңгәнлеген белде. Әйе, ялгыш сүзләр әйтүче кеше провокатор да, явыз ниятле дә түгел, бары ялгы-

шадыр кебек иде ул чак ана. Бары ул эшче белән ныклап шөгыльләнергә генә кирәк, дип уйланды Хөсәен.

Шулай уйланып, сорауларга җавап бирергә керешкәндә кинәт Хөсәен турысындагы тәрәзәгә чиртә башладылар. Бу — хәвеф, бик зур хәвеф икәнлеген белгерткән, хәзер үк ычкынырга дигән сигнал иде. Барысы да тиз генә өйалдына чыктылар. Аның уң як стенасында яшерен ишек ачылып китте. Барысы да берәм-берәм өй белән койма арасындагы аралыкка керделәр. Бераздан өйгә тентү белән полиция ябырылды. Ләкин бу вакытта «кунаклар» аралыктан шулай ук яшерен капка аша күрше ишек алдына узганнар иде инде. Ни өчендер яңа иптәш Мортаза гел Хөсәен тирәсендә булды. Моның серен Хөсәен соңыннан гына белде. Ә ул чакны башына да китермәде. Киресенчә әле. Хәвефсез урынга килеп чыккач, алар иртәгесен кичкырын Бакыр бабай бакчасында очрашырга булдылар. Мортаза Хөсәеннән татарча язылган прокламацияләр һәм китаплар китерүен үтенде. Хөсәен дә вәгъдә бирде. Тәгаен, ул шулай артык ышаныч күрсәтеп тозакка төшәчәк икән. Ләкин шул ук төнне аның өенә Садыйк килеп чыкты. Төсбит юк иде егеттә. Ул эчке әрнү белән бу Мортаза дигән кешенең провокатор, охранка кешесе икәнлеген һәм иртәгә аның янына бармаска кирәклеген хәбәр итте.

— Ачык авызлык күрсәттем, сизми калдым, оят, билләһи, диде ул.

— Син аның шундый кеше икәнлеген кайдан белдең, менә дәлилләрең бармы? — дип сорады Хөсәен. Дәлилләре бар иде. Кичә үзләре утырган өйнең капкасына күмер белән тәре билгесе куелган булган — бусы, тәгаен, полиция өчен. Инде бу эшне аңлау белән Миңнулла Вахитов дәрес вакытында тышка чыккан булып, алгы якта эленеп торган өс киемнәрен тенти башлаган һәм менә шул Мортазаның кесәсеннән күмер табып алган.

Хөсәен уйга калды. Ни әйтсәң дә, моны аныклау өчен ниндидер тагы берәр гамәл кирәк иде. Шунда ук план кордылар. Ләкин барысы да үзеннән-үзе хәл кылынды, иртәгесен Мортаза юкка чыкты.

Әлеге Мортаза кебек үк төксе йөзле ямшекнең сүзләрен тыңлагач, Хөсәен шул хәлләрне хәтерләде. Сак булырга кирәк иде.

Казаннан яктырмас борын ук чыккан булсалар да, юлчылар көн кичкә авышкач кына Лаеш юлы чатлыгындагы мәгълүм постоялый дворга життеләр. Сукырда гына алыштырылган булса да, атлар арыды, чөнки декабрь ахырларында гына дөньяны айкаган бураннардан соң юл рәткә кермәгән иде.

Капканы жирән сакаллы юан урыс үзе ачты. Ул постоялый двор хуҗасы. Күрәсең, Хөсәенне әтисенең толыбы буенча танығандыр, ачык чырай белән каршы алды.

Иркен ишек алды йөк төялгән чаналар, өсләренә чикмән яки чүпрәк палас ябылган атлар белән тулы. Хөсәен бу постоялый дворда бик тыгын буласын, үзенең моннан киткәндә житәрлек кандала ияртәсен яхшы белә иде. Ләкин нишләмәк кирәк, ямшек киреләнде. Шуңа күрә биредә төн уздырырга күнми булмады.

Алар шапшак, караңгы бинага керделәр. Бүлмәнең буеннан буена зур такта өстәл сузылган. Идәндә дә, эскәмияләрдә дә юлчылар ята. Ачы тир исе, тәмәке һәм сарымсак сасысы бөтен өй эчен тынчыткан. Хөсәен бусаганы атлау белән, бәлки моннан чыгып китү хәерлерәктер дигәндәй, беркавым тукталып торды. Ләкин, ни әйтсәң дә, өй эчендә җылы иде. Ул кулындагы әйберләрен өстәл буендагы озын эскәмиягә ташлады. Покларга иртәрәк иде әле. Хөсәен, утка якынрак урнашып, кесәсеннән газеталар чыгарды. Идәндә ятучылар шунда ук баш калкыта башладылар. Ә бераздан Хөсәен укырга керешкәч, кызыксынуларын һич яшерә алмыйча, өстәл тирәсенә елыштылар. Асылмалы лампа тоныкк яктылык сибә, хуҗа зур буфет шкафы тирәсендә үзенең

чэйнекләре, шешәләре белән маташа. Хөсәен аңа мөрәҗәгать итте. Хуҗа, барысына да баш өсте дип, самоварның бик тиз әзер буласын әйтте.

Тиздән, эшләрен бетереп, Хөсәеннең ямшеге дә керде. Почмакта чикмәнен иДәнгә җәеп яткан сары сакаллы рус сорап куйды:

— Порт-Артур турында газет ниләр яза, аңлатмассызмы икән, әфәнде?

Хөсәен үзе дә, Петербург газетасын кулына алу белән, узган елның февраленнән бирле барган рус-япон сугышы хәбәрләрен карый иде. Менә рәхимсез диңгез сугышы башланганга елга якын вакыт узды инде. Әле һаман бетәргә уйламый. Әйдә, җимерелсен патша армиясе. Революцияне тизләтер.

Хөсәен Казанда чыга торган «Волжский листок» газетасыннан бүген япон гаскәрләренең Мукденга таба юнәлергә тиешлеге турында укыды. Алсыннар Мукденны да!

Хөсәен укыган җиреннән башын күтәрде дә эле генә Порт-Артур турында сораган сары сакаллы агайга текәлде.

— Әллә ни яңалык юк,— диде.— Японнар йөз мең кеше югалту бәрабәренә крепостьны алганнар. Шул.

Хөсәеннең тыныч кына җавап бирүе, күрәсең, картны һич тә канәгатьләндермәде, ул:

— Крепостен белмим, — диде, — минем улым шунда хезмәт итә иде, шул беткәндер дип куркам.

— Тегеләр ягыннан йөз мең солдат кырылганны, бездән ул иксез-чиксездер инде, — дип куйды өстәлнең аргы башында утыручы кеше.

— Бардыр, — диде Хөсәен. Газетаны кычкырып укый башлады. Ул тынгач, бүлмәдә сүз кызып китте. Барлык кеше диярлек әңгәмәгә кушыла иде. Адмирал Макаров һәм матросларның фидакарьлеге турында бара сүз.

Хөсәен сак кына әңгәмәгә юнәлеш бирде, агайлар үзләре дә сизмәстән нәрсә бирә соң ул безнең батырлыклар, үзебезгә нинди өлеш чыгара, дип бәхәс башладылар. Ниһаять, алар шәһәрләрдә эшчеләрнең баш күтәрүләре, стачкалар турында, сигез сәгатьлек эш көне өчен көрәшүләре хакында сүз куертырга керештеләр. Хөсәеннең төксе йөзле ямшеге түзмәде, кашларын җимереп, мыгырданып алды:

— Яһүдләр болгата. Барысы да шулар аркасында...

— Нигә сез революционерлар белән танышмыни, беләсезмени аларны? — дип сорады Хөсәен.

Ямшек имәнеп китте. Ләкин җавап кайтарырга өлгермәде, ул арада тузган аксыл чәчле, ябык гәүдәле хезмәтче өстәлгә дыңгырдатып бер чиләкле самовар китереп куйды.

— Әйдә чәйләп алабыз, — диде Хөсәен ямшеккә. Самовар борынына үрелде.

Ул чынаякка су агыза гына башлаган иде, хуҗа, фонарен күтәреп, кемнедер каршы алу өчен ишек алдына чыгып китте. Ишек ябылып житмәс борын суыктан тәмам күшегеп беткән бер кеше бүлмәгә атылып килеп керде. Аның өс-башы юка, артык фәкыйрь иде. Кеше өйгә керү белән утыннары чатнап янып торган мич авызына барып иелде. Хөсәен, эшен бүлеп, студент шинеле кигән бу сәер кешене күзәтеп торды. Ниһаять, теге, мич авызында кулларын угалый-угалый, тирә-ягына күз салды.

— Җәгъфәр! — диде Хөсәен кинәт аны танып. Җәгъфәр ут капкандай сискәнеп Хөсәенгә таба борылды. Хөсәен аның кулга алынуын ишеткән иде, ләкин ни өчен биредә ул хәзер?

Җәгъфәр Хөсәен янына килде дә тирә-ягына ялт-йолт каранып алды.

— Алла хакы өчен миннән берни дә сорашма!

Бик-бик сәер иде бу. Хөсәен, ни дип уйларга да белмичә, хәйран калып, Җәгъфәрне күздән кичерде. Әле күптәнме бу егет бик батырланып Хөсәен белән бәхәсләшкән иде. Ни булган моңа, шул кадәр мескенләнгән?!

— Бир кулыңны, башта исәнләшик һич булмаса, — диде Хөсәен.

— Исәнме, туган, — диде Җәгъфәр. Ул тәкатьсез булып ач күзләре белән өстәлдәге ашамлыкларга текәлде.

— Әйдә, сал бу «җөббәңне», — диде Хөсәен, — утыр, чәйләп алыйк. Җылынырсың.

— Хөсәен, гафу ит, җаным, ал бер шкалик хәмер. Суык минем җилеккә кадәр үтте, мин чәй белән генә җылына алмамдыр, ахры.

Хөсәен чәй эчкәндә, әле һаман җылына алмаган куллары белән стаканны кысып каршысында утырган Җәгъфәрнең саргайган йөзенә карап, төрлесен уйланды. Менә ул адәм язмышы! Үзен арслан дип исәпләп йөргән кешегә бер селтәнеп сугу җиткән — пыяла өлгеседәй уалган да төшкән.

— Бөтенләйгәме? — дип сорады Хөсәен.

— Әйе.

— Димәк, азат иттеләр.

— Атай карт янына кайтам, — дип куйды Җәгъфәр, сорауга туры җавап бирмичә, — белмим, кабул итәрме, юкмы?

— Нигә итмәсен, — диде Хөсәен. Ул Җәгъфәрнең Биләр ягыннан булуын, бер карун байның малае икәнлеген белә иде. Хөсәен аның белән беренче тапкыр Мөхәммәдия мәдрәсәсендә танышты. Егет ислахчылар арасында, янача укыту өчен, мәдрәсәләрдә Европа мәктәпләрендәгечә укыту булсын дип көрәшеп йөрде. Кайнар йөрәкле, кызу канлы иде ул. Ниһаять, ул мәдрәсәне ташлап чыкты. Хосусый укытучылардан русча дәрес ала башлады. Ләкин күп тә үтмәде, бу хәлне ишетеп, әтисе аны ярдәменнән калдырды. Әмма Җәгъфәр анда да үзенекен итте, чибәрлеге, кыюлыгы җитәрлек иде, — бер тол бай хатынга йортка керде. Хатынның сәүдә эшләренә тыгылмады — аны алганда ук шулай сөйләшенгән иде, — үз эше белән: укуы һәм, үзе әйтмешли, «азатлык эше» белән шөгыльләнде. Ул башта эсерлар белән чуалды, ләкин соңыннан социал-демократлар партиясенә керде. Кая барып сугылырга белмәгән, сөрлегеп, адашып үзенең кыйбласын табарга тырышып та таба алмаган бу егет Хөсәенгә якын, кызганыч иде. Ә инде менә берничә ай төрмәдә ятып чыгу аның бөтенләй канатын сындырган, күрәсең. Ни өчен соң ул шундый өтек люмпен кыяфәтендә?

Җәгъфәр китерелгән аракыны стаканга берьюлы салып эчеп бетерде дә Хөсәен турап өстәлгә салган казылыкны комсызланып кимерергә кереште. Бераздан аның маңгае кызарынды, күзләре ялтырый башлады.

— Җәгъфәр, — диде Хөсәен, — безгә барыбер төнне бергә уздырырга туры киләчәк. Монда йоклый алмабыздыр. Әллә хуҗадан бер бүлмә сорап, шунда төн чыгабызмы?

— Шулай шул, — диде Җәгъфәр, — аның өске катта номерлары да бар иде бит. Әй, хозяин! — дип кычкырды ул, батырланып китеп. Хуҗа сакалын сыпырып өстәл янына килде. Ул тагы аракы сорыйлар дип уйлады ахры, бүлмә дигәнне ишеткәч, бераз аптырый төште.

— Минем таныш кеше бу, — диде Хөсәен, — авыру, бик туңган, аңа йокларга урын кирәк.

Бераздан алар ләхеттәй тар, тыгын бер бүлмәдә икесе дә шыгырдавык караватларда яталар иде. Ичмаса, монда иркенләп сөйләшергә була, һәр сүзеңне эләктерергә тырышкандай, авызын ачып тыңлап утырган ямшек юк монда.

— Я, Җәгъфәр, сөйлә? — диде Хөсәен.

— И Хөсәен туган, Хөсәен туган, — диде Җәгъфәр уфтанып, — мин барысыннан да ваз кичеп, авылга кайтырга булдым.

— Ни өчен?

— Шулай, Хөсәен, башка чара юк.

— Ничек инде алай? Кайда синең ялкынлы яшьлек антларың? Сине төрмәдә бик җәфаладылармы әллә?

— Төрмәдә мине сатып алырга тырыштылар.

— Хуш?

— Сатылмадым һәм сатылмам да, алла боерса!

— Ә менә шул ваз кичүең соң?..

— Хөсәен, тыңлале, — диде Җәгъфәр. Яткан җиреннән күтәрелде дә үз башыннан кичкәннәрне сөйли башлады. Аны фәхешханәдә музыка тыңларга кергән җирендә кулга алалар. Филерлар аны күптән күзәтеп килгән булалар. Ләкин, бәхеткә каршы, бу юлы аның үзе янында бернинди дә тыелган әйбер булмый. Үзен кулга алганнан соң ясалган тентү вакытында гына өеннән цензура рөхсәт итмәгән берничә китап табалар. Шуннан соң һәр көнне үзәккә үткеч допрослар башлана. Гадәттә ул бик матур тонда башлана, әйбәт мөгамәлә, папирос тәкъдим итүләр, үз кеше булып сөйләшү. Ләкин, кагыйдә буларак, азагы бик начар бетә. Мәсхәрә итү, куркыту, җикерену. Төрле-төрле ысуллар белән Җәгъфәрне сатылырга, охранкага хезмәт итәргә үгетлиләр. Чыннан да, шундый байлыкка-мөлкәткә ирешкән кешегә җыен чит ил шпионнары белән җуләрләнеп йөреп ни калган? Аның киләчәге тәэмин ителгән, бәхетле, матур тормышта яшәргә хаклы кеше ул. Ә бит Җәгъфәрдән әллә ни сорамыйлар да: бу бозыклыкларны оештыручы кайбер кешеләрне генә күрсәтсен.

Җәгъфәр бирешми, барлык көченә көрәшә, барысыннан да баш тарта, мин берни дә белмим, ди. Ниһаять, көннәрдән бер көнне, һич көтелмәгәндә, аны иреккә чыгаралар. Бу нинди хәл, димәк, тегеләрне җиңдем, үземнекен иттем, дип уйлый ул. Ашыгып, ни өчендер моңарчы һич очрашуга килмәгән бай хатыны янына кайта. Кайта һәм тагы бер тапкыр көтелмәгән хәлгә тара. Хатыны, хурлап, Җәгъфәрне куып чыгара. Үзен төрмәдән азат иттерүче ул икән. Бай хатын дөнья кадәр акча исраф иткән. Ләкин Җәгъфәр, зинһар, үзе өчен эшләнгән эш бу дип уйламасын, бары Җәгъфәрнең төрмәдә дигән исеме үзен пычратмасын өчен генә Гөлҗиһан акчасын җәлләмичә шуны эшләгән. Инде котылып кайттың, бик шәп булды, — дүрт ягың кыйбла хәзер! Ни өчен дип аптырыйсыңмы, — бер дә прокламацияләр таратып, урысча укып йөргәнең өчен түгел, бары фәхешханәгә йөргәнең өчен. Барысын да гафу итәм, иллә мәгәр монысын гафу итә алмыйм...

Җәгъфәр Хөсәенгә шуларны сөйләде дә, эче бушап калганга тынычлангандай, караватына кире ауды.

Хөсәен сүзсез генә уйланып ятты. Үзен революционер дип атаган кеше ничек шундый очракта чигенә ала? Аның иптәшләре, дуслары юкмыни? Ни өчен ул чын ирек сөюченең хыялы булган профессиональ революционерга әверелеп идән астына китмәгән. Эш нәрсәдә?

— Әйткәннәреңнең очы очка ялганмый, Җәгъфәр, — диде Хөсәен, — син хата артыннан хата ясап гомер уздырасың. Нигә кирәк ул синең, үзең яратмаган хәлдә, бай хатынга ияләшүең?!

— Революция өчен, көрәш өчен кирәк булды ул.

— Инде синең хәзер чигенеп, шулай ук үзең яратмаган әтиеңнең канат астына ташлануың нигә кирәк? Анысы да, бәлки, революция өчендер!

— Анысы яшәү өчен. Мин ул син теләгән рәвештәге кан коюларны, экспроприацияләрне эченә алган рәхимсез революцияне теләмим, чөнки мин аның файдасыз, кирәксез бер нәрсә икәнен ачык күрәм.

— Син чын мәгънәсендә умырткасыз меньшевикка әверелгәнсең. Әгәр дә шул юнәлештә тагы бер адым ясасаң...
— Анысы булмас, — диде Җәгъфәр кискен рәвештә.
— Хәтереңдәме безнең беренче адымнарыбыз. Без ул чакны бернинди чигенүләрсез көрәшергә, гомер буе көрәшергә ант иткән идек. Бу эшкә күп булса өч ел вакыт узды, ә син инде чигенүдән оялмыйсың. Аны хурлык санамыйсың.
— Син бу карашың белән Маркснең диалектикасын инкарь итәсең.
— Ничек итеп?
— Шулай. Синеңчә, кешенең күңеле бер дә үзгәрмәскә тиеш. Син метафизик, Хөсәен. Кайчандыр ант әчкәнбез, имеш. Бәлки, мин шул ике-өч ел эчендә баш чатнаганчы көннәр-төннәр буе уйланып дөреслекне эзләгәнмендер һәм тапканмындыр. Мин ант иттем дип эзләнү хокукымны югалтырга тиеш идеммени? Бу бит үз-үзеңне кол итү, иректән мәхрүм итү. Без шул ирек өчен көрәшмәдекмени?
— Кызык икән синең фәлсәфәң! Әгәр инде эзләп тапмагансың икән, шул юлга басам, дип ант итмә. Син, турысын гына әйткәндә, куркак. Рәхмәт әйт бикәңә. Әгәр ул ришвәт биреп коткармаса, син, мөгаен, охранка кешесенә әверелгән булыр идең. Мин бит синең ниятләреңне, уйларыңны аңлыйм. Синең котың алынган, шуннан соң син революция юлыннан ваз кичкәнсең. Син барына да кул селтәп, үзең яратмасаң да, ашатып тоткан байбикәңә сыенмакчы буласың. Ләкин син теләгәнчә барып чыкмаган, очраклылык комачау иткән. Син хәзер...
Хөсәен сүзен әйтеп бетермәде, Җәгъфәр җәһәт кенә яткан урыныннан сикереп торды. Караватын каты шыгырдатып, аякларын салындырып утырды да кулларын селки-селки сөйләргә тотынды.
— Син мине юкка хакарәтлисең! Син мине аңламыйсың. Бу синең бары тирәнтен уйлый белмәвеңнән, рәхимсезлегеңнән генә килә. Сез, большевиклар, барыгыз да шундый рәхимсез. Кеше турында, аның тирән эчке кичерешләре турында уйламыйсыз сез. Мин сезне беләм инде. Мин сезне сынадым инде. Барысын-барысын төрмәнең тар караңгы бүлмәсендә башымнан кичердем. Мин барысын да бәяләдем!
Ул ачуыннан, гарьлегеннән тәмам буылып, ни әйтергә белмичә туктальп калды.
Әйе, хәзер аның белән бәхәсләшүдә мәгънә юк иде. «Ләкин ул шулай да жәл, каһәр, — дип уйланды Хөсәен, — жәл, жәл».
Хөсәен утны сүндерде дә, бераз черем итеп булмасмы дип, урынына ятты. Тышта чатлама суык һәм күгелҗем ай яктысы. Бәләкәй тәрәзәдән туктаусыз җил өрә. Хөсәен толыбына әйбәтләбрәк төренде. Инде йокыга китәм дигәндә, Җәгъфәрнең сүз башлавына айнып, күзләрен ачты.
— Мин жанкай-җанашым тарафыннан сөрелгәч, иптәшләр янына бардым, — диде ул. — Мин аларның ярдәменә мохтаҗ идем. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, алар миннән шикләнделәр.
— Синең иптәшләрең хәзер кем икәнен беләм. Әйдә йоклыйк, — диде Хөсәен, башыннан ук ябынып.
— Юк, син мине тыңларга тиеш, — диде Җәгъфәр, — мин авыр бер хәлдә калдым. Ә минем мескен буласым килми...
— Соң алайса нигә безгә мөрәҗәгать итмәдең?
Җәгъфәр бер сүз дә дәшмәде. Ләкин аның әйтер сүзе бетмәгән иде әле.
— Хөсәен, — диде ул кинәт исенә төшкәндәй җанланып, — син Петербурдагы хәлләрдән хәбәрдармы? Соңгы көннәрдә булган вакыйгалардан. Патшаның Кышкы сарайга килгән эшчеләрне аттыруы турында?
Хөсәен селтәнеп толыбын ачып җибәрде.

— Кем әйтте сиңа?

— Менә бүген әйттеләр. Китәр алдыннан. Ике йөз мең эшче тәреләр, иконалар күтәреп патшага барганнар.

Хөсәен терсәкләренә таянып башын күтәрде.

— Нигә барганнар, нигә?

— Ничек нигә, тормыш шартларын яхшыртуны сорап...

— Шуннан?

— Шуннан теге солдат тезгән дә, халык Сарай алдына җыелгач, аттырган.

Хөсәен бөтенләй аякларын салындырып ук утырды.

— Син моны белеп лыгырдыйсыңмы, әллә үз башыңнан чыгарыпмы?

Җәгъфәр карынкы тавыш белән көлеп куйды.

— Ә ниемә хәҗәт ул миңа алдау?! Белмим, син ничек ишетми калгансыңдыр.

— Бу бит, беләсеңме, искиткеч вакыйга! — диде Хөсәен җанланып. — Син, ахмак, шуны ишеткәннән соң да әле авылга әтиеңнең җылы мич башына киткәнсең!

— Ә мин шул вакыйганы ишеткәч киттем дә, беләсең килсә.

Хөсәен шул дәрәҗәдә үз уйлары белән мәшгуль иде, Җәгъфәрнең ни әйткәнен дә ишетмәде. Ничек соң, ничек ишетмичә калды ул? Ах, кичә беркемне дә күрә алмады шул! Димәк, вакыйга бары бүген генә мәгълүм булган. Тукта, бу бит бөтен Россия хәрәкәткә килә дигән сүз!

— Патша эшчеләрне аттырган дисеңме? — диде ул аякка басып.

— Шулай, аттырган. Хәзер бөтен Петербур туздырылган кырмыска оясы шикелле, ди.

Хөсәеннең бөтен тынычлыгы юкка чыкты, барысы да — бу Җәгъфәр дә, хәтта сеңелесенең язмышы да киләчәк вакыйгалар каршында кечкенә, әһәмиятсез булып калдылар. Ах, нишләп соң ул бүген иртәнчәк берәр иптәшен күрмәде, тәгаен, комитетка ул кичә үк билгеле булгандыр инде. Анда ашыгыч утырышлар уздыралардыр, барлык кешегә эш йөкләнгәндер. Юк, юк, болай кул кушырып утырып булмый. Хәзер үк, хәзер үк Казанга кире кайтырга кирәк!

Хөсәен утны яндырды да каударланып киенә башлады.

— Нишләвең бу? — диде Җәгъфәр, аптырый төшеп.

— Башта ук әйтәләр аны, сафсата, — диде Хөсәен, киез итекләренә үрелеп. Берничә минуттан соң ул почта ямщеге белән Казанга таба оча иде инде.

## Төньяк комитетыннан вәкил

Санкт-Петербургтагы канлы якшәмбе вакыйгалары бөтен илне тетрәтте. Вакыйгалар, шашкын дулкыннар өермәседәй, Казанны да үз эченә алып кереп китте. Казан социал-демократлар партиясе комитеты җитәкчелегендә беренче булып Алафузов заводы эшчеләре баш күтәрде. Алар артыннан типографияләрдә, мастерскойларда, башка вак предприятиеләрдә чуалышлар башланды. Ул арада университет студентлары, ветеринария институты студентлары һәм тагы бик күп урта мәктәп укучылары баш күтәрде. Әйтерсең лә, моңарчы буылып торган куәтле ташкын үзенә юл ачып, алга омтылган иде. Ләкин шундый җаваплы көннәрдә Казан комитеты меньшевиклар басымы аркасында ленинчыл «Вперед» газетасын танудан баш тартты. Мондый хәлгә, әлбәттә, юл куелмаска тиеш иде. Шуңа күрә Казан большевикларына ярдәмгә, үзәкнең киңәше буенча, РСДРПның Төньяк комитетыннан вәкил җибәрелде.

Ул февраль аеның буранлап торган бер кичендә Зеленый Дол дачный поезды белән килеп төште. Вәкил Зөягә кадәр Мәскәү поездында килгән иде. Иделне, күпер булмау сәбәпле, җәяүләп кенә боз өстеннән үтте. Ул Казанга җиткәндә, инде кичке сигезенче яртылар иде.

Вәкил бик яшь иде әле. Гади генә өс-баш: кыска тужурка, колакчынлы бүрек, эшчеләр кия торган арзанлы итекләр. Әгәр аның пенсне күзлеге булмаса һәм интеллигентларча шактый нәфис йөзенә игътибар итмәсәң, тәгаен бу берәр яшь эшчедер дип уйларга булыр иде. Хәлбуки, вәкил сыйфатында Казанга килгән Яков Свердлов, әле егерменче яшендә генә булса да, җитлеккән профессиональ революционер иде.

Яковның кулында кечкенә генә төенчектән башка нәрсә юк. Аны ерактан килгән кеше дип уйларлык та түгел иде. Ул, шау-шулы перронны узып, вокзал алды мәйданына чыкты да, гадирәк извозчик яллап, тиз арада станция тирәсеннән китеп барды. Ярты сәгатьтән соң ул Казан большевикларының иң активларыннан берсе саналган Иван Адамович Саммер квартирасында иде инде. Явка Саммерга билгеләнгән иде. Иван Адамович исә Казанны яхшы белүчеләрдән, үзенең тәҗрибәсе һәм тапкырлыгы белән үзәк каршында да, җирле иптәшләре каршында да зур абруй казанган ышанычлы бер революционер. Дөресен әйткәндә, бу укымышлы кыяфәтле, эре сөякле кеше Яковны шактый сәерсенеп, хәтта күңелсезләнә төшеп каршы алды. Артык яшь, малай сыман, артык өтек кыяфәтле иде шул ярдәмгә килгән бу вәкил. Тик шулай да Иван сер сынатмады, Төньяк комитет тәкъдим итеп, ышанып җибәргән икән, димәк, беренче тойгыга бирелмәскә кирәк, дип уйлады.

Һәм, чыннан да, алар өстәл янына утырышып бераз сөйләшкәннән соң Саммерның шикле уйлары тарала башлады. Яковның күп нәрсәләрдән хәбәрдарлыгы, принципиальлеге ачыла барды. Саммерның комитет хәлләре турындагы сүзен тыңлаганнан соң, Свердлов хәзер үк, хәтта мөмкин булса бүген үк, комитет утырышын җыярга кирәклеген әйтте.

— Моның өчен безгә кайбер иптәшләрне күрергә кирәк бит, — диде Саммер.

— Күрәбез, кирәк икән, күрәбез, — диде Свердлов

Саммер бераз уңайсызлангандай кулларын җәйде.

— Ә сезнең иминлегегез мәсьәләсе ничегрәк соң?

Свердлов күзлек пыялаларын ялтыратып, башын калкытып алды.

— Һо! Мине монда танымыйлар, ә сезнең кебек юлдаш булганда, күзәтеп торсалар да, курыкмыйм.

— Алайса, кузгалдык, — диде Саммер тәвәккәлләп. Ләкин шундук туктап, уйчан бер төстә Свердловка текәлде. Полициядән качып гомер сөрүче профессиональ революционер, юлдан әле яңа килеп төшкән. Ул бит бөтенләй ачтыр.

— Карагыз әле, бәлки, без чыгып киткәнче бераз тамак ялгап алырбыз? — диде Саммер.

— Шулай дисезме? Алайса әйдәгез, мин бер стакан чәйдән баш тартмыйм.

Саммер үзенең тар, караңгы бүлмәсенә чәй, шикәр һәм ашамлык алып кергән арада Свердлов бик җитди кыяфәттә Казан газеталарын караштырып утырды. Аның чәчләре куе, йөзе ябык, өстендә вак кына шакмак бизәк төшерелгән билбаулы ситсы күлмәк. Яковның ябыклыгына һәм өс-башының артык фәкыйрьлегенә карап та аның авыр яшәгәнлеген белергә булыр иде. Саммерга шунысы ошады: бу егеттә төшенкелекнең әз генә дә эзе юк иде. Киресенчә, ул көләч, шаян, барысына да өмет белән, якты чырай белән карый. Менә ул газетаны читкә куйды да кабыклы килеш пешерелгән бәрәңгене әрчергә керешге. Ул бәрәңгене дә оста әрчи иде. Саммер әле яртылаш кына әрчелгән бәрәңге белән

маташканда, ул инде бәрәңгесен тозга манып, тәмләп, арыш ипие белән ашый да башлады.

Яков ашаганда да Саммерга сораулар биргәләде. Казанда революцион хәрәкәт көчәйгәннән-көчәя, ләкин шулай да житәрлек оешкан бер төс алмаган икән. Ничегрәк соң, эшчеләр белән аралашу ничек? Меньшевиклар белән эшчеләр алдында турыдан-туры бәхәс корып караганыгыз бармы?

Тамак ялгау күп булса ун минут дәвам итте. Саммер чәйнекне икенче бүлмәгә чыгарып кире кергәндә, Свердлов өстенә киенгән, йөнтәс бүреген кулына алган иде. Алар, караңгы өй алдын узып, тәбәнәк, чалыш баскычтан аска төштеләр. Урамда җәяүле буран әле һаман кар себерә иде. Городовой будкалары янындагы тонык яктылык сипкән фонарьларны юлчылар читләтеп уздылар. Ниһаять, ике ишек алдын кичеп, алар бөтенләй аулак, тын бер тыкрыкка килеп чыктылар. Бу Суконный бистәсендәге Кабан күле буе урамнарының берсе иде.

Хәзер ул кадәр ашыкмаска да була. Алар, тынычланып, әңгәмәләрен дәвам иттерделәр. Бу юлы сүз хәрбиләр арасындагы эш турында иде. Хәзер алар арасында большевистик пропаганда алып бару соң дәрәҗәдә мөһим. Бу эш белән дә комитет җитәрлек шөгыльләнмәгән. Свердлов Казанны районнарга бүләргә кирәклеге турында, аерым группалар төзү, шул җөмләдән хәрби группа төзү, кирәклеге турында үз фикерен әйтте. Саммерча да бу дөрес иде. Ләкин большевиклар тәкъдим иткән политик власть өчен көрәшне бары комитетта меньшевиклар йогынтысы беткәннән соң гына җәелдереп җибәрергә мөмкин. Хәлбуки, бу хәлне бер селтәнүдә үзгәртеп булмый. Чөнки комитетта күп тәҗрибә туплаган, оста һәм хәйләкәр меньшевиклар бар.

Алар шулай кызып сөйләшеп барганда, кинәт фонарь баганасы янында тукталып калдылар. Һич көтелмәгәндә каршыга бер кеше килеп басты. Саммер алга чыкты, Свердловны артына яшерде. Беравык тукталып, теге ят кеше белән күзгә-күз карашып тордылар. Ләкин куркырлык берни дә юк иде. Юлларында очраган кеше гади бер исерек булып чыкты. Исерек яңадан черек такта коймага сөялде. Ул Яковка ят бер телдә нидер сөйләнеп сукрана башлады.

— Ни сөйли ул? — диде Свердлов. — Сез аңламыйсызмы?

— Аңлыйм. Ул русларны сүгә, — диде Саммер көлемсерәп. — Сезнең аркада без бәхетсезлеккә дучар ителдек, ди. Денебезне дә, телебезне дә кысасыз, үзебезне хайван рәтеннән йөртәсез, ди.

Свердлов, хәйран калып, башта ни әйтергә белмичә торды.

— Кара син аны!

Ул сукранып калган әлеге кешегә борылды да кискен рәвештә Саммерга:

— Беләсезме,— диде,— без барысы турында да сөйләштек, ә менә мондагы рус булмаган халыклар турында, алар арасындагы эш турында ләм-мим сүз булмады.

— Анысы шулай, рәхмәт аңа, — диде Саммер көлеп. — Ләкин икебезнең берсе чыгышыбыз белән рус булсачы, ичмаса...

— Юк, мин шаяртмыйм, Иван Адамович. Комитетта җирле халык белән эш алып барыламы соң? Бу бит бик, бик җитди мәсьәлә.

— Алып барыла, Яков Михайлович.

— Түгәрәкләр эшлиме?

— Әйе, түгәрәкләр дә эшли.

Саммер үзе белгән татар большевистик түгәрәкләрен санап китте.

— Ә тел белү мәсьәләсе ничегрәк соң, сездә татар телен белүчеләр бар инде алайса?

Саммер, чак кына мактана төшеп:

— Безнең оешмада татарлардан профессиональ революционерлар да бар, Яков Михайлович, — диде.

— О-о,— дип куйды Свердлов. Күрәсең, ул мондый җаваптан бик канәгать иде.

— Бездә җаны-тәне белән бирелеп эшләүче бер татар егете бар. Ана үз халкы арасында революцион эш алып баруны без ышанып тапшырдык.

— Ул комитет члены инде, әлбәттә?

— Юк, ул комитет члены түгел.

— Менә мин тагы меньшевистик йогынтының исен тоям,— диде Свердлов. — Алар бүген рус патриотлары булып ходайдан Япониянең җиңелүен телиләр, ә иртәгә, язмыштан узмыш юк, дип, чын шовинистка әверелерләр!

Бераз вакыт сүзсез бардылар.

— Кем дигән кеше ул? — диде кинәт Яков.

— Теге татар турында сорыйсызмы?

— Әйе.

— Ул учительская школаны бетергән кеше. Исеме — Хөсәен, фамилиясе — Ямашев.

— Сез мине шул иптәш белән очраштырырсыз әле, зинһар, — диде Свердлов.

## Тәгъзимә нишләргә кирәген белә

Менә өченче көннән бирле инде Тәгъзимәнең үтереп башы сызлый. Имче карчыкны да чакырып карады. Тик өшкертүләр, ырымнар килешмәде. Инде докторның нәрсә икәнен дә белми түгел иде Тәгъзимә, бергә баракта торганда дусләшып киткән Анфиса исемле марҗа, докторга күрен син, диде. Ә анда бару җинел эш түгел, аның өчен болай да тakы-токы ризыкның бер өлешен балаларының авызыннан өзәргә кирәк. Тәгъзимә, әллә бәлкем, болай да җайланыр әле, дип, бүген дә мастерскойга килде. Тик эбәткә свисток булганчы ук бөтенләй хәлдән тайды, йөзе күм-күк булды, аяк-куллары дерелди башлады. Күршесендә постау тузаннарын туздырып, онытылып, ач яңаклы җирән марҗа эшли иде. Тәгъзимә түзмәде, шуңа дәште.

— Нишләргә инде миңа, Маруся, үләм бит, җаным. Әллә мастер белән сөйләшеп багыйм микән? Җибәрмәс микән кайтарып? Әтлек ясамас микән?

Маруся, җәһәт кенә борылып, Тәгъзимәгә карады да аптырап ук китте. Тик мастерны абайлап, йөзен чытты.

— Бик җене чыккан чак ахры этнең. Ай-һай, — дип куйды. Шулай да түзмәде, машинасын туктатып, урыныннан купты. — Әйдәле!

Алар, тотынышкан килеш, машиналар шау-шуы эчендә мастер янына киттеләр. Тәгъзимәнең аяклары камырга әверелгән кебек, йөрәге авырттырып кага, күңеле тәкатьсез болгана иде. Ул бераз барганнан соң, туктап, хәл алды, бер урында салкын таш стенага сөялеп торды. Ниһаять, алар рәхимсезлеге белән даны таралган мастерга якынлаштылар.

Мастер Пальчиков, илле яшьләрендә булыр, — сакал-мыексыз, бушан йөзле кусә кеше. Аның хатыны да, бала-чагасы да юк. Әйтүләренә караганда, гомумән, ул семья корырга сәләтсез, гермафродит. Хәлбуки, ул күңелендә хатын-кызга карата һәрвакыт ачу саклый иде. Әчми дә, тартмый да, әмма телендәге әшәкелек башка беркемдә дә бу кадәр юктыр. Әйтүләренә караганда, аны завод администрациясе дә өнәп бетерми. Тик ул фидакарь бирелгәнлек белән хуҗаларның күңелен табарга тырыша. Күрәсең, шуның аркасындадыр, ана җил-давыл тими.

Һәрвакыт бүредәй астыртын карап кына сөйләшүче бу кешедән Тәгъзимә җаны-тәне белән курка, мөмкин булганча, аның күзенә чалынмаска тырыша иде.

**Ләкин** хәзер бүтән чара калмады.

**Мастер** кисүчеләрдән тегүчеләргә постау ташып йөри торган житендәй ак чәчле, ябык чырайлы бер кыз бала белән сөйләшеп тора иде. Дөресрәге, ул аны ялкау дип тирги, штраф салам дип яный иде. Арты белән торуына карамастан, хатыннар якынлашканын тойган кебек ул бу якка таба борылды.

— Ни кирәк? — диде.

Маруся Тәгъзимә өчен әйтте:

— Матвей Савельич, Тәгъзимәнең хәле бик начар. Отгул бир, зинһар.

— Отгул? Шул гына җитмәгән иде!

— Юк, Матвей Савельич, күрмисеңмени? Ходайдан оял!

— Ходайдан? Басурманка өченме? Үлмәс. Эшли бирсен.

Тәгъзимә, авыртуын җиңеп, үзе сүзгә кереште.

— Авырмаганда мин эшләмим түгел ич, Матвей Савельич.

— Тинтәк, мастерскойның патша хәзрәтләре заказын башкарганын беләсеңме син? Син нәрсә, үзең антихрист булгач, японнар безнең изге Россияне тар-мар итсеннәр дисеңмени?!

— Мин берни дә әйтмим. Мин моңарчы начар эшләмәдем, үзең дә күреп торасың. Бүген миңа эшләрлек хәлем калмады...

— Җибәр инде, — диде Маруся, ялына төшеп, — күреп торасың ич, Матвей Савельич.

Һич көтелмәгән бер хәл булды, кинәт мастерның йөзе уйчанланып китте. Күзләрендә Тәгъзимәгә карата сынап карау, хәтта ниндидер бер рәхим-шәфкать җылысы чагылгандай булды.

— Бар, син эшеңдә бул, — диде кинәт Пальчиков Марусяга, — мин үзем ни эшләргә кирәклеген белермен.

Аптырап, бу эшнең төбендә берәр начарлык ятмыймы, дигәндәй, һаман кузгала алмый торган Марусяга ул:

— Бар дип әйтteләр бит сиңа, — диде. Аты-юлы белән сүгенеп куйды. Ләкин мастерның тавышында әле дә ниндидер ышаныч бар кебек иде. Тәгъзимә: «Тырышлыкларымны исәпкә алган, ахры», — дип уйлады.

Маруся үз машинасына таба киткәч, Пальчиков Тәгъзимәне конторкасына алып керде. Хатынга бер сүз әйтмәстән, стенада эленеп торган телефонның боргычын әйләндерергә кереште.

Тәгъзимә, чалыш урындыкка утырып, шыксыз бәләкәй бүлмә эчендә мастерның сүз башлавын көтте. Кинәт бүлмәгә бер ир кеше килеп керде. Ул очлары бөтерелгән сары мыеклы, яшькелт күзле, башына котелок кигән, франтрак киемле иде.

— Менә сезгә яраклы хатын, — диде Пальчиков, кул биреп күрешкәч бик төче елмаеп, — уңган, әйткән сүзне тыңлый. Ярый торган... христианка булмаса да.

— Аның мөселман кешесе булуы кирәк тә, — диде мыеклы.

— Менә нәрсә, — диде Пальчиков, Тәгъзимәгә мөрәҗәгать итеп, — бу әфәнде әйткәнне башкарсаң, сиңа отгул булыр. Кирәксә, өеңә докторын да чакыртырбыз. Тик әйткәнне тырышып башкар. Ә инде әйткәнне эшләмәсәң!.. — Мастер бармак янап куйды.

— Ул кадәр куркытмагыз мадамны, — диде котелоклы кеше көлемсерәп. — Ул эшне башкару аның өчен чүп тә түгел.

— Алайса сез үзегез сөйләшегез, — диде мастер тагы төчеләнеп һәм конторка ишеген каты ябып чыгып та китте.

Тәгъзимәнең башы һаман үтереп сызлый, күңеле болгана иде. Ләкин шулай да ул, көчләнеп булса да, әйткәнне тыңларга һәм аңларга үзен мәҗбүр итте. «Әйдә, чәнчелеп китсеннәр, көчем җитсә, рәхәтләнеп үтәрмен, тик хәзергә җибәрми генә газапламасыннар», — дип уйлады.

Мастер чыгып китү белән, мыеклы кешенең йөзе җитди бер кыяфәткә керде. Һич көтелмәгәндә саф татар телендә сөйләшә башлады ул.

— Мөселманча укый-яза беләсеңме?

— Белмим шул. Хәреф танымыйм, абый, — диде Тәгъзимә куркына төшеп.

— Ярый, отыры яхшы, — диде мыеклы кеше, хатынны тынычландырып.— Менә нинди йомыш сиңа, сеңел дип әйтимме, апа димме,— диде ул бераздан. Кесәләреннән пачкалап төрелгән кәгазьләр чыгарды. Шикләнеп ишеккә күз атты, аннары Тәгъзимәнең янына ук килеп шыпырт кына тагы сүз башлады: — Менә бу кәгазьләрне күрәсеңме? Алар язулы кәгазьләр.

Әлбәттә, Тәгъзимә күреп тора. Зәңгәр кара белән юка гына кәгазьгә нидер язганнар. Шундый язулы кәгазьләр бик күп.

— Менә шуны үзең белгән татарларга өләшергә кирәк. Бөтенесенә. Кемне беләсең, барысына да. Тик яшерен генә. Сизмәсеннәр.

Мыеклы, тәгаен, рус иде. Ул татарча бик әйбәт сөйләшсә дә, Тәгъзимә аның татар булмаганлыгын анык сизде. Ходаем, Тәгъзимәнең ниндидер яшерен кешеләр турында, аларның патшага дошман икәнлекләре турында, начар сүзләр язылган язулар таратып дөньяны болгатып йөрүләре турында ишеткәне бар иде бит. Инде үзе шул тозакка килеп каптымы?! Моның ахыры хәерле булып бетмәсен Тәгъзимә аңламыймы соң!

Хатынның башы әйләнеп китте. Ул авып төшмәс өчен, үзе утырган урындыкның тактасын тотты.

«Менә нинди була икән ул патша дошманнары! Кара, һич кенә дә әйткәнчә түгел. Алар качып-посып кына йөриләр, дигәннәр иде. Бу бит...» Тәгъзимә бу патша дошманының эшне үзләренең мастерлары аша йөртүенә хәйран калып утырды. Бик тиз арада мастер турында әллә ниләр уйларга өлгерде. Ләкин аның катнашы белән эшләнә микән соң бу эш? Тәгъзимә түзмәде:

— Нәрсә язылган монда? — дип сорады.

— Мондамы? — диде әлеге кеше көлемсерәп, аннары мыек чылгыйларын бөтереп куйды. — У, монда! Иң дөрес сүзләр язылган монда. Язуда синең нидән бәхетсез булуың турында күрсәтелгән.

Тәгъзимә тагы сорарга батырчылык итте:

— Безнең Матвей Савельич та сезнең яклымыни?

Кеше чак кына уйланып торды. Кысык яшькелт күзләрен тераэп Тәгъзимәгә карап куйды.

— Юк, ул берни дә белми, — диде. — Аңа да бер сүз дә әйтә күрмә. Үзең генә бел. Кемнән алдың дип сорасалар, мастерскойга килгән иде бирәү, кем икәнен белмим, диген. Революционер диген, социал-демократ диген. Әйтә белерсеңме?

— Юк, әйтә белмим, — диде Тәгъзимә.

— Ярый алайса, әйтмә. Таптым, урамнан таптым, диген, сөйләштекме?

Кинәт котелоклы кешенең мәсхәрәле елмайган күзләрендә ачу очкыннары кабынып алды.

— Но таратмасаң, сиңа начар булачак!

Тәгъзимә ике ут арасында калганын тойды. Күрәсең, бу дәһшәтле тойгы аның йөзенә үк бәреп чыкты. Мыеклы кеше моны күреп дустанә көлемсерәде дә, Тәгъзимәнең иңбашына орынып:

— Курыкма, курыкма, — диде, — сиңа бит бу эшне эшләү берни түгел. Хәзер кайтып ял ит. Бераздан доктор җибәртербез. Ул дару бирер, терелерсең. Борчылма.

Тәгъзимә, аллага тапшырып, төргәкне кулына алды. Урыныннан купты. Чыгып китәр алдыннан, исенә төшкәч, тагы сорау бирде:

— Ә син соң минем кайда торганымны беләсеңме?

— Мин барысын да беләм, — диде котелоклы кеше.

Бу һич көтелмәгән, уйланмаган бер хәл иде. Тәгъзимә хатыннардан ишетмәде түгел. Кайберәүләре хәтта теге патша дошманнарын ничектер үз итеп тә сөйлиләр иде әле. Тик моңарчы Тәгъзимә ул эшнең асылы белән кызыксынмады. Андый куркыныч нәрсәләр башына килсә, өч баләкәченең язмышы турында уйлап тиз айный иде. Ә хәзер нәрсә инде?

Тәгъзимә, кулындагы төенчегенә әледән-әле куркынып карый-карый, өенә кайтып китте. Бик куркыныч иде. Куркуы шундый көчле иде, хәтта башының чатнап авыртканы да ничектер артык сизелми, күнел булгануы да беткән кебек иде. Ул хәзер прокламацияләрне төенчеге-ние белән атып бәрергә дә риза. Тик белмәсләр дисеңмени? Теге кеше: «Мин барын да беләм», — диде бит. Тизрәк котылырга кирәк бу хәерсез нәрсәләрдән!

Тәгъзимәнең бистәдә якын кешеләре бар иде. Шушында узган авыр, михнәтле елларда байтак кешеләр белән аралашылды, күрше-күлән, дус-иш, авылдаш, хәтта ерак кардәш-ыру да табылды.

Менә өйгә кайтып җитәргә бер чат кына калды инде. Тәгъзимә өч тәрәзәсе урамга караган, үзе янтая төшеп җиргә ингән бер катлы өй алдына килеп җиткәч, ирексездән тукталып, уйга калды. Шушы өйдә аның авылдашы Шәрифулла абзый тора бит. Тол хатын каршында ул бик абруйлы, хөрмәтле кеше. Теге, Әгъзам вафат булган авыр көннәрдә шул кешеләр Тәгъзимәнең беләгеннән тотып калдылар ич. Шул бит инде Тәгъзимәнең иң якын киңәшчесе. Инде хатын баш җитмәслек авыр бер мәсьәлә алдында калган икән, бәлки шул олы кеше белән киңәшү мәслихәттер?

Шәрифулла абзый да Алафузовта эшли иде. Ул ат белән йөк ташып, мастерскойдан мастерскойга, цехтан цехка йөри. Бу эше аңа бераз гына булса да хөрлек бирә, шәһәр тирәсендә йомышы булганда ул күрше-күлән үтенечен бөтенләй дә бушлай башкаргалый. Көндез атын ашатырга өенә кайта.

Тәгъзимә кечкенә капкадан ишек алдына күз салды. Тик берни күрергә дә өлгермәде, каяндыр атылып капкага Шәрифулланың төпчек улы Гыйззәтулла килеп җитте.

— Атаң өйдәме? — диде Тәгъзимә.

Малай, җавап кайтарганчы, беравык күзләрен шарландырып, ни әйтергә дә белмичә торды.

— Хәзер белеп чыгыйм алайса, шунда тор, — диде ул, ниһаять. Ләкин Тәгъзимә Шәрифулланың өйдә икәнлеген сизгән иде инде. Чөнки аның ак бәкәлле көрән-чаптар аты ишек алдында, чанадагы печәнгә кушылган иде.

Гыйззәтулла озакламый әйләнеп чыкты.

Шәрифулла абзыйларда бүген кунаклар бардыр, дип уйланды Тәгъзимә. Хуҗа яңа кунакны озак көттермәде, Тәгъзимә өйгә керү белән, түр яктан алгы якка чыкты.

Шәрифулла, чыннан да, бер күрү белән үк күнелгә ягылып кала торган бер абзый иде. Аның ябыграк аксыл йөзе дә, яшь соры күзләре дә, хәтта җеп кебек мыегы һәм ияк очында гына калдырып татарча кисәрткән сакалы да, ару күлмәк өстеннән кигән җиңсез камзулы да — барысы да көлеп-елмаеп тора кебек иде. Тәгъзимә, ирексездән, әллә булмаса берәр бәйрәм-мазармы бүген, дип уйланды. Ләкин бу турыда сорамады. Шәрифулланың хатыны — Мәһитап апа Гыйззәтулла янына йомыш кушарга чыккан арада, гозерен әйтеп калырга ашыкты.

Тәгъзимәнең сүзләрен ишеткәч, картның йөзе үзгәреп китте. Башта сагаеган кебек булды, аннан куркыныган төс чыкты.

— Кая әле, — диде ул. Төргәкне алып, сәке читенә утырды да, бераз язуларны караштыргач, коры гына:

— Кем бирде моны? — диде. — Мастерскойдан бирен чыгардылар дисеңме?

— Юк инде, мастерскойдан түгел, Шәрифулла абзый, — дип алдашты Тәгъзимә, — әйтәм ич, кайтышлый.

Шәрифулла сәкегә ятыбрак тәрәзә пәрдәсенә үрелде, аның бер читен күтәреп, күзәтүче юк микән дигәндәй, карап алды. Тәгаен, бик хәтәр эш кушканнар иде Тәгъзимәгә.

— Язу үзебезчә, мөселманча икән, — диде Шәрифулла. — Кәнишне, әллә ни зур грамыты юк миндә, шулай да, үзебезчә язылган булгач, шәт, укып чыгарбыз.

Иреннәрен селкетеп авыз эченнән генә язуны укый башлады. Прокламацияне күзләренә бер якынрак китерә, бер ераграк чигерә иде карт. Кинәт аның йөзендәге кызыксынуы тирән аптырауга күчте, авызы ачылып ук китте. Ул бер Тәгъзимәгә карап нидер әйтмәкче дә булган иде, ләкин эчтән тынды, бары: «Менә сиңа!» дип кенә мыгырданды.

— Грамыты җитенкерәми шул, грамыты, — диде ул тагы.

— Танымыйсыңмыни, ул инде теге... ни... әрвәлүтсиянир язуы. Берүк син башка кешегә әйтә күрмә инде аның турында. Ник дисәң, миңа шулай куштылар, юкса син, Шәрифулла абзый, минем башны Себер җибәртерсең.

— Юк бит, алай булмый ул, — диде карт кыркурак бер тонда. — ничек инде, килен!? Ни язылганын белми торып, аны агай-энегә таратырга була димени?!

— Алла хакы өчен, Шәрифулла абзый, алай димә. Әгәр без әйткәнне эшләмәсәң, башың бетә синең, диделәр. Инде бичара сабыйларым ятим калалар бит.

— Тукта, килен, булмаган хафага бирелмә, мин теге якка чыгып күзлегемне табыйм әле, әллә, бәлкем, анда әйбәт сүзләр дә язылгандыр.

Карт шулай диде дә түр бүлмәгә юнәлде.

— Кеше булса, берүк күрсәтмә инде, — дип калды Тәгъзимә, авырткан башын учы белән тотып.

Шәрифулла ишекне ачып эчкә узды. Анда идән уртасында ашъяулык тирәли өч ир кеше утыра иде. Шәрифулла бирге якта, самовар янында утыручы кара тутлы, калын иренле егеткә язуларны сузды.

— Кара әле, Гафур, минем баш җитми, бу нинди хикмәт тагы? — Шәрифулла бу язуларны каян алганлыгын әйтте.

Гафур өрә-өрә чәй эчә иде. Үзенә сузылган кәгазьләрне сәерсенебрәк алды. Калкурак зур кара күзләрен озак кына язуга төбәп торды, берәздән, эчтән генә укыса да, аның иреннәре хәрәкәтләнә һәм кара куе кашлары тибрәнә башлады. Шәрифулла да мөгаллимнең язуны укып хәйранга калуын тойды. Ниһаять, егет прокламацияне укып чыкты да:

— Кем бирде моны? — дип сорады. Аның тавышы калын, ягымлы, дулкынланган минутында да артык сабыр, тигезлеген үзгәртми торган тавыш иде. Шәрифулла Тәгъзимә турында сөйли башлады.

— Берни дә аңламыйм, валлаһи, — дип куйды Гафур бот чабып. Хәзер аның йөзенә әллә елмаю, әллә нәфрәтләнү, әллә булмаса тагы да ныграк сәерсену галәмәтләре чыккан иде. Ул әле һаман үзе язган прокламация караламалары белән шөгыльләнүче, берничә дә игътибар итмичә, ниндидер кечкенә китапка чумган Хөсәенгә дәште. Хөсәен, тез чәнчеп утырган килеш, укуында булды, ишетмәде.

— Хөсәен, — диде Гафур кабатлап, — аңлатып бирче безгә, бу нәрсә бу, ни дигән сүз?

Хөсәен, ниһаять, эшеннән аерылып, үзенә таба сузылган прокламацияне алды. Прокламация гектографиядә зәңгәр кара белән басылган. Хөсәен язып бастыра торган прокламацияләргә охшаган иде. Боларның

башына да теге прокламацияләрдәге кебек үк: «Российский социал-демократический рабучий партия. Тоташыгыз, бөтен дөньяның эшчеләре», — дип язылган иде. Ләкин болар барысы да күз буяу өчен эшләнгән нәрсәләр. Чөнки эчтәлеге нәкъ партия өндәүләренең киресе иде. Хөсәен ачуыннан кызарына төшеп укуын дәвам итте. Бу прокламация аша халыкка мөрәҗәгать итүче ниндидер кешеләр татар халкының барлык бәхетсезлеген руслар аркасында дип белдерәләр иде. Алар татарларны, берләшеп, русларга каршы канлы көрәшкә өндиләр.

— Провокация, — диде Хөсәен, ачу белән янган күзләрен күтәреп, — ничектер моңа чик куярга кирәк. — Ул авыр сулап уйланып торды.

— Каяле, — диде аның уң ягында утырган Садыйк, — нәрсә язганнар соң?

Хөсәен бер сүз дә әйтмичә прокламацияләрне сузды.

— Мин үзем дә аптырап киттем, — дип куйды Шәрифулла, кулларын җәеп.

— Мөгаен, моның төбендә охранканың мәкерле эше ята, — диде Хөсәен. — Шәрифулла абзый, — диде ул, бераз уйланганнан соң, — бу язуларны бер эшче хатын китерде дидегезме?

— Әйе шул, Тәгъзимә атлы бер хатын. Тегү мастерскоенда эшләүче минем авылдаш.

— Нинди кеше соң ул?

— Нинди дип, ялгыз хатын инде. Өч баласы бар. Ире анау елны вабадан үлеп киткән иде, хәзер көнкүреше ташка үлчим инде.

— Укый-яза белми инде, әлбәттә?

— Кая! Язу тану тагы ул бичарага!

Хөсәен ачуыннан кызарып ук китте.

— Кабахәтләр! Сайлый белгәннәр үзләре дә!

— Житмәсә, бу араларда хасталанып та йөри әле бичара, — диде Шәрифулла.

Хөсәен кашларын җыерып бик житди уйланды да:

— Сез аңа бу язуны башта укып күрсәтегез, Шәрифулла абзый, — диде. — Инде таратырга кушканнар икән, таратсын.

Садыйкның күзләренә куркыну билгесе йөгерде.

— Ничек инде алай, Хөсәен?! — диде ул, кулларын сузып. — Ничек күрәләтә үз-үзебезгә начарлык эшлик?! Минемчә, Хөсәен туган, хәзер үк бу язуларны хатыннан алып ертып ташларга кирәк. Үз кешеләребез үзебезгә этлек ясап йөрмәсеннәр, к чорту матерь!

Хөсәен салмак кына җилкәсен сикертеп куйды.

— Хатын таратмаса, аңа көн бетәчәк бит! Шунысын уйлыйсыңмы?

Гафур да сүзгә кушылды:

— Әлбәттә, әйткәннәрен үтәмәсә, ул хатын мотлакан бетәчәк.

— Берни дә эшләтә алмаячаклар, — диде Садыйк, үз сүзендә нык торып. — Нигә шулай дим мин? Чөнки тегеләр хатынга кул тидерсәләр, үзләренең фальше корып ятканлыкларын ачачаклар.

Хөсәен мыек астыннан гына елмаеп куйды.

— Садыйк дус! Аңардан иртәгә үк, тараттыңмы, дип сораячаклар. Әгәр ул «юк» дисә...

— Нигә, «юк» димәсен!

Хөсәен көлеп үк җибәрде.

— Нинди беркатлы кеше син! Аннан менә нәрсә, — диде ул житдиләнеп. — Әллә син охранка бары шушы хатынга гына биргән дип уйлыйсыңмы?

— Бирмәсә соң! Барыбер. Ичмаса, без күргән хәтлесе эшчене агуламасын. Ертып ташларга, мондый эш белән шөгыльләнмә, Себер китәсең, дияргә кирәк.

— Юк, юк, алай түгел, — диде Хөсәен, йөзен чытып. — Болай итегез, Шәрифулла абзый: хатынга нәрсә язылганын укып күрсәтегез. Аннары мондый язуның ялган икәнлеген аңлатыгыз, социал-демократлар эше түгел бу, диегез. Әгәр охранканың беренче йомышын үтәсәң, сиңа икенчесен дә бирәчәкләр, син әкренләп шулай шымчыга, эшчеләрнең дошманына, сатлык җанга әвереләчәксең дип әйтегез. Менә шул. Калганын үзе хәл итәр.

— Ә киңәш сораса, «Нишлим соң?» — дисә? Ул бит шулай дип керде.

— Сез, аның күзләренә карап: «Белмим шул», — диегез.

Тәгъзимә исә бу арада борчыла ук башлаган иде инде. Шәрифулла абзыйның теге бүлмәдә артык озак торуы аның күңеленә әллә нинди уйлар кертте. Инде хуҗа хатыныннан: «Ни булган, бик озаклады»,— дип сорарга авызын ачканда гына, урта ишектән Шәрифулла килеп чыкты.

— Чәнчелгере, күзлекне таба алмый мием чередә, — диде ул.

Шәрифулла сәкегә утырып язуны тотлыга-тотлыга укырга тотынды. Башта сүзнең ни турында барганлыгын Тәгъзимә аңламыйча торды. Бәлки, чыннан да, шулайдыр дигән уй үзды аның башыннан, ә бераздан тирәнтенрәк уйланырга мәҗбүр булды. Аның күңелендә язудагы сүзләргә каршы дәлилләр, үзе белгән җанлы вакыйгалар, бер-бер артлы калка башлады. Туктале, алар сезнең кан дошманыгыз — урыслар, диләр. Ә бит менә бүген маржа башы белән Маруся аның өчен тырышып йөрде. Тукта, ире үлгәч, аны Анфиса заводка урнаштырмадымыни? Ни өчен аларны Тәгъзимә дошман күрергә тиеш була соң?! Пальчиков — мастер, рәхимсез, зобани кеше. Ул Тәгъзимәне эттән дә болайрак күрә. Ләкин бит шул ук Пальчиков Маруся белән Анфисага да эткә караган кебек карый. Юк, юк, мондагы сүзләрнең очы очка ялганмый. Пальчиков — җир бит; рус кешесе булганы өчен Тәгъзимәнең дошманы түгел, ә кабахәт булганы өчен, миһербансыз, комсыз булганы өчен дошман. Ә Марусялар, Анфисалар? Алар ничек дошман булсыннар, ди. Әгәр үзенә яхшылыклар итәргә торган бу иптәш хатыннарына Тәгъзимә кул күтәрсә, җир йотар аны. Әгәр Анфиса, Маруся кебек яклаучылары булмаса, Пальчиковлар Тәгъзимәне тере килеш ашаган булырлар иде. Ходаем, бу нинди хәл инде! Болай булгач, теге мастерскойдагы хатыннарның ниндидер әрвәлүтсиннәргә өметләр баглап сөйләнүләре дөрескә чыкмады. Алар шундый явыз җаннар икән ләбаса!

Шәрифулла, прокламацияне укып чыгу белән, Тәгъзимәнең фикерләрен аңларга теләгәндәй, бераз вакыт тынып, күзлеге аша хатынга карап торды.

— И алла, — дип куйды Тәгъзимә, көрсенеп, — кемгә ышанырга инде болай булгач. Шул язуларны таратучы явыз җаннарны мактаган хатыннарны беләм бит мин.

Шәрифулла кәефләнеп мыек астыннан гына елмаеп куйды. Хатын үзе дә дөреслекне ялганнан аера белә иде, шунысы куанычлы. Кара син Хөсәенне! Белә шул адәм күңелен, ә? Кинәт Шәрифулла кыюланып Тәгъзимәгә аңлата башлады. Тәгъзимә таратырга тиешле прокламациянең башына: «Тоташыгыз, бөтен дөньяның эшчеләре», — дип язылган иде.

— Мин сиңа бу прокламациянең ялган икәнлеген бик ансат күрсәтә алам,— диде Шәрифулла.— Ничек инде ул язуның бисмилласы итеп «Тоташыгыз» ди, ә эченә «аерылышыгыз» дип яза. Бары безнең татарның башына җитү өчен язган моны дошман!

— Ихластан да шулай шул, — дип куйды Тәгъзимә. Кинәт ул сәкедә яткан кәгазьләр төргәгенә кыргый, усал бер караш ташлады. Шәрифулла ни дип уйларга да өлгермәде, Тәгъзимә калтыранган куллары белән аларны алды да янып торган учак авызына таба атлады.

Юк, Шәрифуллага нинди дә булса киңәш бирергә туры килмәде. Хатын ни эшләргә кирәген үзе белә иде.

Ә өч көннән соң РСДРП комитеты татар телендә халыклар дуслыгына багышланган прокламацияләр басып таратты. Анда охранка провокациясенә карата да язылган юллар бар иде.

«Татар иптәшләр! Патшаның ярдәмчеләре — жандармнар, Кулаков вә башкалар үзләренең провокаторлары аша сезнең арагызда төрле язулар тараталар, — диелгән иде анда. — Алар татарларны русларга каршы котырталар. Ул листовкалар социал-демократлар исеменнән таратыла. Ләкин аларга ышанмагыз, иптәшләр! Исегездә тотыгыз, без Россия халыкларын җәберләүче вә изүче рус хөкүмәте белән сезне көрәшкә чакырабыз. Әмма уртак дошманны бары тик рус халкы белән союзга кереп кенә җиңеп була, дибез...»

## Учаклар дөрләп янсын

Монарчы шәкертләр хәрәкәте пыскып торган сүрән учакны хәтерләтсә, канлы якшәмбе көннәреннән соң ул дөрләп, ялкынланып яна башлады.

Хәзер шәкертләр арасында төрле-төрле җәмгыятьләр баш калкытты. Фатих Әмирхан оештырган «Әл-ислах» гектографта гына булса да үз газетасын бастырырга әзерлек алып бара. Кемнәрдер прокламацияләр, язма журналлар чыгара. Хәрәкәт көчәйгәннән-көчәя.

Һәм, бәхеткә каршы, шул ук шәкертләр арасында Хөсәеннәрнең дә ышанычлы ярдәмчеләре бар. Алар шәкертләр арасында яшерен прокламацияләр тараталар, җыелыш һәм моназараларда әйтәсе сүзләрен әйтәләр, бәхәскә керәләр. Әйе, мәдрәсә, — начармы, яхшымы, — татар егетенең беренче тапкыр китап белән танышу урыны. Хөсәен дә бит үзенең уку юлын шул мәдрәсәдән башлады. Мәдрәсә белән исәпләшмичә, аны игътибар даирәсендә тотмыйча булмый. Шәкертләрнең күпчелеге — авыллардан килгән кешеләр. Аларның фәкыйрьрәкләре җәйләрен казакъ, башкорт арасында укытучы-мулдәкәлек итә. Ахыр чиктә мәдрәсә аша киң катлау татар, казакъ, башкорт крестьянына йогынты ясап та була ич.

Февраль кичләренең берсендә Хөсәен «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә барышлый шулай уйланды. Аны иртә белән үк җыелыш турында кисәткәннәр иде. Ул хәбәр итүчеләргә: барам, чыгыш ясыйм, дип сүз бирде. Андый мәдрәсә җыелышларында күп тапкырлар булганы бар аның. Ак чырайлы, шау-шулы шәкертләр дөньясы. Тормыштан ерак торган тәҗрибәсезлек, сукырлык. Ил хәсрәтен чигеп сөйләшү урынына бары шәкерт зары, бер якны каеру. Хәер, бу эштә аларны гаепләп тә булмый инде. Алар шундый шартларга куелган кешеләр. Хәлбуки, халкыбызның дәртле яшьлеге башлыча шунда бит.

Менә ул ике катлы кызыл кирпеч бина. Хөсәен чәчәктәй үсмер елларын шул мәдрәсәгә йөреп уздырды. Монда һәр нәрсә таныш.

Хөсәенне мәдрәсә ишек алдында Гафур Коләхметов, Галимҗан Сәйфетдинов һәм Габдрахман Мостафин каршы алдылар. Болар өчесе дә — ышанычлы якын дуслар. Мәдрәсәнең үзендә укып, шунда яшәп, Хөсәеннәр ягыннан эш алып баручы кеше — Габдрахман Мостафин дигәне. Аның шәкерт икәнлеге киеменнән үк күренеп тора. Гафур да, Галимҗан да европача киенгән булсалар, Габдрахман ак илтер бүректән, читек катадан.

Хөсәен һәркайсы белән кул биреп күрешкәч, алар ашыгып өске катка менеп киттеләр. Залда җыелыш башланган иде, ахры, өскә күтәрелүгә, ябылып бетмәгән ишектән тавышлар ишетелде. Кемдер кычкырып

нидер аңлата, кемнәрдер риза булмыйча гүлиләр иде. Коридорны узып, шактый зур залга кергәч, җыелышның башланганлыгы анык беленде. Зал шыгрым тулы. Урын житмәү аркасында, байтак кеше аягүрә басып тора. Алар стеналарга сөялгәннәр. Арада тәрәзә төпләренә урнашканнары да бар. Хөсәен, ишектән керү белән, түрдә яшел постау ябылган өстәл артындагы кешегә игътибар итте. Пенсне күзлекле, өстенә костюм, башына хәтфә кәләпүш кигән, чандыр гына, зифа буйлы бу кеше шәкерт реформасы башында торучы Фатих Әмирхан иде. Хөсәен, Габдрахман артыннан калмыйча, тыгызланып халык арасына узды, һәм, ниһаять, алар үзләренә буш тәрәзә төбе табып, утырыштылар.

Фатих Әмирхан, кулындагы кечкенә кыңгырауны булдыра алганча каты чылтыратып, шәкертләрнең шау-шуын бераз басты да:

— Җәмәгать! Шәкерт әфәнделәр! Әгәр сез мине җыелышка рәис итеп сайлагансыз икән, буйсынырга да авырсынмагыз, — диде. — Тәртип-низамга чакырам!

Ул тагы бераз вакыт кулындагы кыңгыравын чыңлатып торды. Хөсәен таныш-белешләрдән кемнәр килгәнен белер өчен залны күздән кичерде. Әйе, хәтәр бәхәсләр булачак. Чөнки шәкертләр арасында төрле карашлы кешеләр, эсерлары да, меньшевиклары да, либерал буржуазия вәкилләре дә, милләтчеләре дә бар.

Сүзне житү чәчле, ак якалы, манжетлы яшь егеткә бирделәр. Ул шәкертләрнең кул чабып каршылауларына бик шат иде, ахры, чыгып, нәзакәтле генә баш игәннән соң, халыкның азатлыгы, мәдрәсәләрнең яңартылуы — барысы да дини реформага бәйләнгәнлеген аңлата башлады. Янәсе, дин ул — безнең төп корал, шул ислам дине аркасында гарәп халкы кыргыйлыктан котылып, зур культура тудыра алды һәм Европаны уятты. Ораторның сөйләвенә караганда, акылсыз муллалар тарафыннан ислам диненең бозылып китүе генә эшне харап иткән. Ораторга гөр килеп кул чаптылар.

Нәүбәттәге оратор шулай ук европача киенгән, житү чәчле, ләкин башына чуклы кызыл фәс кигән иде. Ул милләтнең бәхете төрки халыкларның берләшүенә бәйләнгән дип сөйләргә тотынды. Аныңча, әгәр дә Россиядәге төрки телдә сөйләшүче егерме биш миллион халык бер байрак астына җыелса, үзенең көчен-гайрәтен күрсәтсә, барысы да ал да гөл булачак. Чыңгыз, Бату хан заманнарын хәтерләгез. Әнә шул көннәрне кире кайтару өчен көрәшергә кирәк, диде.

Шәкерткә барысы да бата иде. Беренче ораторны алкышлаган кебек, икенчесен дә алкышлап кул чабып озаттылар. Әйе, шәкерт өчен асылда ислах — яңару, реформа кирәк иде. Аның күпчелеге өчен ахыр чиктә нинди флаг астында моңа ирешеп булуы хәлиткеч әйбер булып күренми иде.

Хөсәен, записка җибәреп, Фатих Әмирханнан үзенә сүз сорады.

Хөсәенне күпчелек шәкерт белә иде монда. Соңгы вакытларда аңа, митингларда булсын, җыелышларда булсын, күп кенә чыгышлар ясарга туры килде. Шәкертләр дә хәзер мәдрәсәдә генә утырмый бит. Алар да һәркайда булалар, шуңа күрә Хөсәенне күпчелек таный иде.

Хөсәен, сүз бирелү белән, Фатих Әмирхан утырган өстәл янына чыгып басты. Зал бер мәл гүләп алды. Күпчелеге казаки, түбәтәй, читек кигән, әле мыекка пәке тидермәгәненнән алып инде сакал-мыекны шартын житкереп үстерә торганнарына кадәр, барысы да ораторга текәлделәр. Хөсәен, гадәтенчә, тыныч һәм үзенең хаклыгына ышанган хәлдә сүзгә кереште:

— Иптәшләр, шәкерт дуслар! — диде ул. — Сезнең зарларыгыз, сезнең чын белемгә, мәгърифәткә ашкынуларыгыз минем өчен бик яхшы аңлашыла. Чөнки мин үзем дә шәкерт булган кеше, үзем дә шушы диварлар арасында яшьлегемне уздырган кеше. Әлбәттә, ислах кирәк, әлбәттә, урта гасыр схоластикасы арбасына утырып, без халкыбызны

тәрәккъый иттерә алмаячакбыз. Ләкин моңа ирешү өчен безгә нишләргә кирәк соң? Беренче булып сүз алган әфәнде әйткәнчә, ислам байрагы астына җыелыргамы, я булмаса икенче оратор тәкъдим иткәнчә, милләтчелек байрагын күтәрергәме? Социал-демократларның, ягъни безнең, бу мәсьәләгә карашы ачык. Бернинди дин дә, милләтчелек байрагы да халыкларга азатлык һәм, шул җөмләдән сезгә, шәкертләргә реформа бирмәячәк!

Динне яңартырга кирәк дип сөйләгән әфәнде сезгә тарихи дөреслекне бозып күрсәтә. Беркайчан да ислам диненең дә, башка диннәрнең дә мәгърифәткә хезмәт иткәне булмады. Ислам дине белән гарәп галимнәре беркайчан да тату яшәмәделәр. Рәсми дин аларны һәрвакыт эзәрлекләде. Һәм ул эле дә шулай, иптәшләр.

Кинәт шәкертләрдән бер төркем бик каты тавышлана башлады. Уртада утыручыларның берсе:

— Дәһри! Дензсез! Сатлык мөкаллид! — дип кычкырды. Хөсәен туктарга мәҗбүр булды. Ул мондый хәлнең буласын күздә тоткан иде, тик ул әйтәсе сүзен әйтми китмәячәк!

Фатих Әмирхан тагы, аягүрә басып, кечкенә кыңгыравын чылтыратырга керешге.

— Тәртип, тәртип, туганнар!

— Сөйләмәсен, долой! — дип кычкырды баягы тавыш.

— Бу ни дигән сүз! Без ирек, хөрлек турында сөйләшмибезмени? Хөсәен әфәнде дә бу иреккә хаклыдыр бит, — диде Әмирхан. Ниһаять, бер төркем шәкерт:

— Сөйләсен, сөйләсен! Без тыңларга телибез! — дип кычкыргач, залның тына төшүеннән файдаланып, Хөсәен сүзен дәвам иттерде. Динне, аның тарихын әйбәт белгән шәкертләргә авызлары капланырлык итеп, тарихи фактларга таянып сөйләргә кирәк. Бәхеткә каршы, Хөсәеннең бу җәһәттән әзерлеге начар түгел иде. Ул марксизм тәгълиматын үзләштергәннән соң үзендә булган, шул исәптән, мәдрәсә биргән белемнәрен янадан тикшереп чыкты. Моңарчы игътибар ителми узылган күп кенә нәрсәләрне яңача бәяләргә кирәк булды, чөнки аның шул ук белемнәрне алган, шулар белән ук тукланып яшәүче кешеләр арасында да эшлисе бар иде бит. Хөсәен инкарь ителмәслек фактларны тезеп, исбатлый башлагач, зал ирексездән тынычланып калды. Хөсәен сүзне католик чиркәвеннән, фәннең шул чиркәү белән көрәшеннән башлады, аннан әкренләп ислам флагы астында хакимлек сөргән хәлифәләрнең гарәп галимнәрен җәберләвен, аерым кешеләрнең нинди авыр золмәт астында хакыйкатьне эзләвен әйтте. Ораторның үзенә дә тыңлаучыларның ышанырга мәҗбүр булуы сизелә иде. Мәсьәлә ачыкланды. Һәр төрле караш үз урынын алды. Җилгәртелгән ашлыктай аерылды.

Дингә реформа ясарга кирәк, аны хәзерге чор таләпләренә җайлаштырырга кирәк, барлык ислам дөньясы шул флаг астына кушылса, барлык төеннәр чишеләчәк, дигән кеше һәм аның тарафдарлары түзмәделәр, сызгырырга, идән дөбердәтергә керештеләр.

Фатих Әмирхан тагы житез генә аягүрә торып басты, Хөсәен исә, мондый дулауның булачагын көткәндәй, хәтта шуны алдан сизүенә шатланган кебек, тыныч кына елмаеп, шау-шу басылганын көтә бирде. Ниһаять, каршы як та, Хөсәенне аңлаган һәм аңларга тырышкан кешеләр дә телгә килде. Алар: «Сөйләсен, комачауламагыз!» — дип кычкырырга, рәиснең тәртип урнаштыруын таләп итәргә керештеләр, зал өчдүрт минут каты гүләгәннән соң гына тына төште. Хөсәен, берни булмагандай, сүзен дәвам иттерде. Ул тагы мисаллар китерде, Әбугалисина, Фараби, Якуб Көндиләрнең ислам галәмендәге тормышы, аларның голәмә тарафыннан нинди зур җәфалар күреп, хезмәт итүләрен сөйләде.

— Мина сезнең әйткән туры сүзне күтәрә алмавыгыз аңлашыла, әфәнделәр, — диде Хөсәен теге үзе алдыннан чыгыш ясаучыларга.— Сезнең өчен, әлбәттә, марксизм байрагына караганда, ислам байрагы файдалырак, кулайрак. Ләкин мин ышандыра алам, сезнең бу көчәнүләрегездән берни дә килеп чыкмаячак. Чөнки әйткәннәрегезнең берсе дә тарихи дөреслек түгел. Ислам байрагы никадәр генә хәтәр булып күренмәсен, ул байрак тузган, искергән инде, аның белән әллә кая ерак китә алмассыз! Менә мин икенче ораторның сүзләренә тукталыр идем. Ул милләтчелек байрагын күтәреп чыкты. Менә монысы хәтәррәк. Чын азатлык өчен көрәш барган чакта хәрәкәткә буталчыклык кертү куркынычы бар. Шулай да без, марксистлар, аннан да курыкмыйбыз, чөнки безнең аңарга каршы куярлык һәм аның да дөреслеккә корылмаган, инсаният бәхетенә хезмәт итә алмый торган бер теория икәнлеген исбат итәрлек дәлилләребез бар.

Хөсәен милләтчелектән ярдәм эзләгән ораторга мөрәҗәгать итте. Ул алгы сафта, кулларын күкрәгенә кушырып, әгәр кирәк икән, хәзер үк этәчтәй сугышырга әзер икәнлеген сиздереп, кукраеп утыра иде.

— Сез, әфәндем, тарихка мөрәҗәгать итеп, чыгышыгызны Чыңгыз ханнан башладыгыз вә вакытыгызны шундый шәүкәтле заманнарның яңадан кайтуы белән хыялланып уздырдыгыз. Ләкин, чынлыкта, әфәндем, безнең каннарыбызның Чыңгыз хан биргән өлеше иранлылар канындагы Хулагу хан өлешеннән, Мысыр гарәпләре канындагы мәмлүкләр биргән өлешеннән бер дә артык түгел. Сездә, әфәндем, милли горурлык юк, безнең каннарыбыз үзенең мәдәнияты белән Европа кыйтгасында беренче урынны алучылардан булган Болгар халкына барып тоташа. Без карт, чал тарих иясе булган тырыш, зирәк бабаларыбызны онытмыйк. Инде миңа ышанмыйсыз икән, мәшһүр галимебез Шиһаб Мәрҗани хәзрәтләренең «Мостафадел-әхбәр»енә мөрәҗәгать итегез. Әйе, әйе, әфәндем, сез милләт өчен ут йотасыз, хәлбуки, милләт тә, халык та, аның мәдәнияты да, туган теле дә кирәкми сезгә. Сезнең тырышлыкларыгыз бары милләтне, татар халкын бетерүгә генә китерәчәк. Сез төрки халыклар, госманлылар дисез, әфәндем. Ләкин сез бу төрки халыкларның бер милләттән тормаганлыгын ачык беләсез бит. Шәкертләрнең күбесе — казакъ далаларында, төрекмәннәр арасында, ниһаять, Бохара якларында булган кешеләр. Әйтегез, зинһар, тел, гореф-гадәт, тормыш шартлары ягыннан бездән аермаслыкмыни алар? Сез аңларга тиеш, алар үзләренә бер милләт һәм аларның безнең белән уртаклыклары руслар белән поляклар арасындагы уртаклыктан артык түгел. Шулай булгач, тарихи шартлар аркасында барлыкка килгән милләтләрне ничек итеп көчләп бер кунычка тыкмакчы буласыз сез? Димәк, бу мөмкин булмаган бер нәрсә, алар уртак социаль максатлар өчен кулга-кул тотынышып көрәшсәләр дә, барыбер үзләренең милли үзенчәлекләрен югалтмаячаклар. Димәк, бу вежүткә ашмый торган ми череткеч бер утопия генә. Инде сез милли азатлык дисез, милли азатлык булмыйча торып шәкертләр өчен ислах мөмкин бер нәрсә түгел, дисез. Нәрсә, сез рус дәүләтенә каршы сугыш ачмакчы буласызмы? Явыз, рәхимсез ак патша мондый хәлдә бөтен Казан губернасын кан дәрьялары белән күмеп ташлаячак. Нәтиҗә нәкъ кителгәннең киресенчә чыгачак. Тодеуш Костюшконың, яхут дагстанлы Шамилнең азатлык хәрәкәтләре ни белән беткәнен белмисезмени?

Ләкин, кадерле шәкерт иптәшләр, халкыбызны бәхет-сәгадәткә ирештерү, алдынгы милләтләр сафына бастырып озын гомерле итү, бөтен дөнья мәдәниятына лаеклы өлешен керттерү имканияте юк түгел! Моның өчен миллият байрагы да, ислам байрагы да кирәкми, ә марксизм байрагын күтәрергә кирәк.

Хөсәенне тагы бүлдерделәр. Арттан берәү дулап:

— Безнең мөселман агай-эне сыйныфларга бүленмәгән! Бездә эшче юк, без барыбыз да — хәллеләр дә, хәлсезләр дә — бер җәфаны кичерәбез, урысларына барып сөйлә бу әкиятеңне! — дип кычкырды.

— Дөрес түгел бу, иптәшләр, — диде Хөсәен тавыш-гауганы басарга тырышып, — дөрес түгел! Бездә дә нәкъ башка Европа милләтләрендәгечә сыйныфлар бар. Ышанмасагыз, иптәшләр, үзегез барып белешегез: Алафузов фабрикаларының өчтән бер эшчесе татардан тора, вә һәркайда татар эшчесе иңеләтә изелә! Ә авылларда нинди хәерчелек хөкем сөргәнлеген сез үзегез дә яхшы беләсез бит, туганнар! Авыл байгуралары, алпавытлары ярлы крестьянның канын тереләтә эчәләр. Бары дөм-сукыр, яхут акны кара дип күрсәтергә теләгән явыз җаннар гына бездә сыйнфый көрәш юк дип әйтергә базалар!

Сыйныфлар бар. Сыйнфый дошман көчле. Чөнки аның хөкемендә гаскәр бар, дәүләт бюрократиясе бар, төрмәләр, жандармнар бар, ниһаять, патша үзе алар ягында.

Хөсәен сүзен тәмамларга җыенган иде инде. Ләкин ишек ачылып китте дә махсус күзәтү өчен куелган шәкертнең куркынган йөзе күренде. Ул кулын күтәреп шундук Фатих Әмирханга ниндидер ишарәләр ясый башлады.

Рәис тиз генә аягүрә басты, Хөсәенгә мәгънәле караш ташлады һәм:

— Иптәшләр, әфәнделәр, — диде. — Сүзне хөрмәтле шагыйребез Мәҗит Гафури әфәндегә бирәбез!

Хөсәен тиз генә яндагы ишеккә таба китте. Мостафин белән Галимҗан Сәйфетдинов күптән кул изәп аны чакыралар иде инде. Кемнәрдер шул ук ишектән йөгерә-йөгерә чыгып киттеләр. «Димәк, полиция, я булмаса филерлар!» дигән уй узды Хөсәеннең башыннан. Ах, аның Мәҗит Гафурины да күрәсе килә иде бит. Моңарчы Троицк, Уфа якларында яшәгән шагыйрьнең башлангыч хикәя һәм шигырьләре белән ул таныш иде. Ниһаять, ул аның хәзер Казанга килгәнлеге турында да ишетте. Күрергә кирәк иде аны, танышырга, сөйләшергә. Әгәр дә Гафури кебек шигырь язарга сәләтле кешеләр аңа ярдәм итсә, нинди әйбәт булыр иде.

Хөсәен ишек янында тукталды да күзләре белән халык арасыннан Гафурины эзли башлады. Сул кул як стена кырыннан урта буйлы, чандыррак егет зал алдына таба ашыга-ашыга бара башлады. Ул сул аякка аксый иде. Менә ул рәис өстәленә сул кулы белән таянды, бернинди кереш сүз әйтмәстән, кычкырып шигырь укырга тотынды. Тәгаен, барысы да баштан ук уйланып куелган иде. Шәкертләрнең политик җыелышын үзенә күрә шулай гөнаһсыз гади әдәби кичә итеп күрсәтү иде бу. Хөсәен тагы ишеккә карап алды. Залда әлегә ят беркем дә күренмәгәч, ул тагы тукталып шагыйрьне тыңлый башлады.

Гафуриның тавышы артык көчле булмаса да, ягымлы һәм ничектер моңлы иде:

Вакыт житте һәрбер эшне тикшерергә,
Ярамас күзне йомып тик йөрергә,
Һиммәт итсен һәрбер кеше хәл кадәре,
Җитешмәгән урыннарны житкерергә...
Барчабыз уйлап карап, карар биреп,
Тиештер бер-бер эшкә тиз керергә,
Авыр йөкне тартып барган кешеләрне,
Ярамас артка таба чигерергә.
Кеше артыннан иярсәң дә белепияр,
Шул вакытта иярүдән файда тияр,
Белмәенчә тәкълит кылып юлга керсәң,
Ахырда янган утка эчең көяр...

Бөтен зал бер булып кул чаба башлады. Фатих Әмирхан тагы аягүрә торып басты. Кемдер залда: «Себер тимер юлы! Себер тимер

юлы!» — дип кычкыра башлады. Ләкин Хөсәенне иптәшләре кулыннан тарталар, тизрәк күздән югалырга чакыралар иде. Хөсәен залның аргы очындагы ишеккә тагы бер тапкыр күз атты да, анда нинди дер хәрәкәт булып алганын күргәч, тиз генә үзе артыннан ишекне япты. Алар караңгы бүлмә аша үтеп, аска төштеләр. Комганнар, кәвешләр тулган госелханәне, аннары әчкелтем-төчкелтем исләр белән ысланып беткән кухня-ашханәне узып, арткы юлдан ишек алдына чыктылар. Капка төбендә якасын күтәргән бер филер йөренә иде. Егетләр койма ярыгы аша берәм-берәм күрше ишек алдына чыктылар. Андагы утын сарайлары артына кергәч, тукталып сөйләштеләр. Хөсәен сорау белән Мостафинга текәлде.

— Я, ничегрәк соң, синең белән сөйләшергә вакыт та булмады,— диде.

— Булды, тараттык,— диде Мостафин, барысын да аңлап.

— Ничегрәк кабул иттеләр?

— Ярый,— диде Габдрахман, елмая төшеп.— Берничәсе белән сөйләштем. Иртәгә эшкә керешәбез.

Әлбәттә, сөйләнгән сүз шәкертләр арасында революцион-большевистик прокламация тарату, төркем туплау һәм аларның түгәрәкләрендә эш алып бару турында иде. Хөсәен Галимҗанга ишарә итте.

— Менә сезгә Галимҗан Сәйфетдинов килеп йөриячәк.

— Әйе, ул миңа әйтте,— диде Мостафин.

— Аяныч,— дип куйды Хөсәен.— Мәҗит Гафури белән бер сөйләшеп утырып булмады. Кайчаннан бирле җыенам...

— Теләсәң, синең теләгеңне аңа җиткерәм мин,— диде Габдрахман.— Әйтимме соң? Сиңа барсынмы?

— Болай итәрбез,— диде Хөсәен,— син аны Габитовларга алып бар. Шунда...

— Менә нинди гәп, Хөсәен туган,— диде Галимҗан Сәйфетдинов,— иртәгә көндезге унда Апанаевларда тегеләрнең җыелышы була. Рәшит казый үзе катнашачак. Син аны беләсеңме?

Хөсәен белгәнлеген әйтте. Рәшит казыйның менә ничә елдан бирле инде, зур тырышлык күрсәтеп, пантюркизм хәрәкәтен җәелдерергә йөргәнлеген ул яхшы белә. Аның «Миръат»ын Хөсәен чыккан саен алып укымый калмый иде. Хәлбуки, бу елдам һәм оста эш йөртүче дин әһеленең татар җәмәгатьчелеген зур хәвефләргә дучар итүе мөмкин. Менә ничә елдан бирле инде ул халыкны Төркиягә китәргә өндәп, миссионерлык кылып йөри. Аның исәбенчә, рус арасында торуга караганда, татарга Төркиядә яшәү мең тапкыр хәерлерәк. Янәсе, төрекләр — безнең кан кардәшләребез, янәсе, шул ук тел, шул ук дин. Нинди зур ахмаклык! Әле Хөсәен, иптәшләреннән аерылып, бер үзе генә Екатеринская буйлап киткәч, шулар турында уйланды.

Гайнулла будкасы янынннан узды. Елмаебрак дәшсәң, ара-тирә акча төрткәләсәң, барысын да сатарга әзер торган бу бәләкәй полицейский белән араны бозмаска кирәк иде. Шул ришвәтче аркасында күп кенә хәлләрдән котылып калды бит Хөсәен. Комитетта хәтта, аның белән ныграк элемтәгә кереп булмас микән, дип тә әйттеләр. Ләкин тиздән Хөсәен бу эшнең мөмкин түгеллеген белде. Унтер абзыйның, тегеләрне саткан кебек, үзе өчен файдалырак булса, сине дә ике тиен көмешкә сатуы бик ихтимал иде. Шуңа күрә Хөсәен аның белән артык ачылмыйча гына танышлыкны дәвам иттерде. Әле ул постында торган Гайнуллага сәлам бирде.

— Ә-ә, Хөсәен икән,— диде унтер.— нихәл, энем, әниең исәнме, җәмәгатең саумы,ниләр бетереп йөрү? Бик алай үзеңне нитмиләрме соң?..

— Юк әле хәзергә, әлхәмделилла.

Яз сулышы кичләрен дә үзен сиздерә, өй кыекларыннан салынып төшкән озын тамчы бозлары язның якынлашуын ачык күрсәтә. Хөсәен, шуларга карап, бозлар озын, яз быел бик озакка тартылыр, ахры, дип уйланды. Әле соң булмавына карамастан, урамнарда халык аз иде. Гөрләп килгән революция җиле мещаннарның котын алган. Сирәкмирәк узган извозчик атлары һәм дөбер-шатыр килеп йөргән трамвайлар гына тын урамны җанландыра иде.

Хөсәен, өенә кайтып җитәрәк, каршы яктагы капкадан чыгучы кешегә игътибар итте. Ул ишек алдында вәисевчеләр мәзһәбенең канцеляриясе урнашкан иде. Таш капка өстендәге яшел тостәге калайга шулай дип язылган да. Өстә гарәп хәрефләре белән: «Мәктәп гыйрфан мәхкәмәи шәргыйяи мөхәммәдия», аста русча: «Всего мира молитвенный дом мяктябгирфан, т. е. мусульманская академия и автономное духовное управление и канцелярия сотрудника всего мира духовного отца сардара староверского о-ва мусульман ваисовского божьяго полка» диелгән. Биредә татар агай-энене әләктерергә чамалап торган күп тозакларның берсе һәм шактый куркынычы урнашкан. Соңгы вакытларда аның капкасы артык киң ачыла башлады. Әле хәзергә сардар Гайнан сөргендә булуына карамастан, аның ярдәмчеләре һич йоклап ятмыйлар.

Хөсәен урам аркылы бу якка чыгып килүче кешене күзәтеп торды. Кеше якынрак килгәч, аның өс-башы, фәкыйрь киемнәре ачык күренде. Хөсәен елмаеп куйды. Бу бит кайчандыр Хөсәеннәрнең керен чәлдереп чыгарга теләгән теге әкәмәт егет. Ул бит әле, җитмәсә, өйгә кереп ашапэчкәч, рәхмәт тә әйтмәстән, чабаталарын күтәреп чыгып сызган да иде. Исеме ничек әле? Әйе, Фәрхетдин.

Хөсәен, бу якка чыккач, югары очка китә башлаган Фәрхетдинне кычкырып туктатты.

Егет аңгармыйча калды. Ул, акылын җыеп, Хөсәенне танып алганчы, «бай» аның янында ук иде инде.

— Нихәл егет? Фәрхетдин бит әле син? — диде Хөсәен.

Фәрхетдин, аптырап, күзләрен зур итеп ачты. Аның чыраенда курку галәмәтләре иде.

— Нәрсә кирәк сиңа, бай абый? Нишләтмәк буласың мине? — диде Фәрхетдин.

— Син теге капкадан чыктың, шулаймы? — дип сорады Хөсәен.

— Тегеннән шул.

— Анда нигә кергән идең?

Фәрхетдин, әйтимме, юкмы дигәндәй, дәшми торды, аннары өметсез рәвештә кул селтәп, авыз эченнән диярлек:

— Әй лә, булмады ла, — дип куйды.

Ул бераз шикләнә төшеп Хөсәенгә карады. «Теге чакны качып китеп эшне бозмадыммы икән?»

Ләкин Хөсәеннең мөгамәләсе һич тәшвишләнергә урын калдырмый иде. Теге чакны да ул яхшылык теләде бит Фәрхетдингә. Фәрхетдин үзе юләр булды.

— Божье полкка язылмакчы булган идеңмени? — диде Хөсәен.

— Акча алып булмасмы дигән идем, — диде Фәрхетдин, мескенләнеп, борынын тарта-тарта.

— Бирмиләрме?

— Бер авылдашны очраткан идем. Шул әйткән ие. Әгәр шунда кереп язу алсаң, син инде бөтен салымнардан азат, сиңа беркем берни әйтә алмый, рәхәтләнеп авылыңа кайтасың да, күпме теләдең, шул чаклы җир чәчеп, рәхәтләнеп гомер сөрәсең, дигән иде. Булмады, үзе акча сорый. Аннан, минем пачпорт та юк... Пачпортыңны калдырып тиешле сумманы бирсәң, сиңа кәгазь бирәбез, ди.

Хөсәен ирексездән көлеп җибәрде.

— Фәрхетдин, — диде ул йомшак кына итеп, — ышанма андый шарлатаннарга!

— Нигә алай? Минем авылдаш Җантимер абый белә, ул бик әйбәт икән, аның язуы. Беркемгә буйсынмыйсың, беркемнән курыкмыйсың, мәчеткә йөрмисең, инде китереп муллага сәдака да бирмисең, ә җирнең дисәтинәсенә сигез тиен көмеш түлисең дә, мин татар түгел, мин крәстиян түгел, мин денсез дә түгел, мин татардан, җир күктән, ут судан ничек аерылса, шулай аерылам, дисең дә тик иркле мөрит булып яши бирәсең.

— Барып чыкмады дисен инде алайса?

— Чыкмады шул, абый җаным. Пачпорт та юк, акча да юк. — Фәрхетдин күңелсезләнеп башын иде. — Әнә төнәген берәү киңәш бирде бирүен, — дип куйды ул бераздан. — Тик никтер күңелем бер дә тартмый. Күңел тартмаса, булмый бит ул. Шулай күңел тартмаган бер җиргә урнашкан идем узган ел, адәм хуры булдым. Чак төрмәгә утыртмадылар үземне.

Хөсәен сагая төште.

— Нинди эш соң ул?

— Юк, әйтүе дә оят инде, бай абый.

— Әйт, әйт, монда бит үзебез генә.

Фәрхетдин Хөсәеннең колагына үрелде дә Суконныйдагы кызыл фонарьлы йортта эшләгәнен әйтте.

— Ә, анысы әйбәт түгел инде! — диде Хөсәен.

Фәрхетдин куркынып китте. Юкса бит ул «бай абый»сыннан үзен кызгандыру өчен генә, и бичара, дип әйттерү өчен генә чишелгән иде.

— Инде мена нишләргә дә аптырыйм, — диде Фәрхетдин еламсырап. — Җирләр кибә башлау белән, алла боерса, чәчүгә авылга кайтырмын дигән идем. Тик бит, абый җаным, кулыңда бераз гына да акчаң булмаса, синең кемгә кирәгең бар. Атлык акча җүнәйтеп булмасмы дигән идем. Юк шул...

— Күпме җитми соң? — дип сорады Хөсәен.

— Бер аягына җыйдым инде... — диде Фәрхетдин. — Шуннан гайри юк. Бусы да һәр көнне ике тиенгә кими.

— Нигә, ул акчаны бит син берәр заводта да эшләп таба аласың.

— Кем алсын мине забутка, бай абый. Анда хәзер эшләр бик кыйтылашты. Анда беркем дә җүнләп эшләми хәзер. Эшчеләрнең үзләрен эштән куалар. Мин бер забастуфка чыккан җиргә кермәкче идем. Теге эш ташлаучылар урнына. Бер урыс эшчесе ат башыдай йодрыгын борын өстендә генә уйнатты. Җаныңны алам, әгәр сатлык җан булып, без эш ташлаганда бай күңелен тапсаң, ди.

— Дөрес әйткән, — диде Хөсәен. Фәрхетдин аптырап Хөсәенгә текәлде.

— Бәй, син үзең дә бай ич, абый җаным! Ничек инде ул алай?

— Ә мин бай түгел, Фәрхетдин.

Фәрхетдиннең коңгырт күзләре тагы зур булып ачылып китте. Ул, ни әйтергә дә белмичә, бераз вакыт сүзсез торды да, сүзне икенчегә борып:

— Төнәген бер иптәш очрап тагы бер акча табу юлын өйрәтте өйрәтүен. Тик никтер ансы да ошамый, — дип тагы сүзен башлады.

— Ниндирәк эш соң ансы? — диде Хөсәен.

— Әнә теге Печән базары чиркәвенә барып чукыну. Үзебезнең деннән язып, урыс дененә күчкән өчен поп уч тутырып акча бирә, ди. Теге кеше миңа сөйләп торды. Мин, ди, чукынып акчаны алып кайтам да, бер атна намаз укып, гөнаһларымнан арынып утырам, ди, аннан, ди, акча беткәч, тагы чукынырга китәм, ди. Поп, ди, карт, бик бәлтерәгән нәмәрсә, ди, мин икенче тапкыр килгәндә ул мине оныткан була инде, ди.

Кәләрлек тә, еларлык та иде. Хөсәен былтыр гына үз күз алдында булып узган куркынычлы вакыйганы хәтерләде. Яшьтән үк алынып тәрбияләнгән ниндидер ятим татар малаен Җылан тавы монастыреннан шул Фәрхетдин әйткән евангелистлар чиркәвенә китерделәр. Көфер почмагындагы абзыйларның берсе баланың чукындырылу өчен кителергәнлеген белеп калган. Бөтен Печән базарын шаулатып мөселман агай-эне кузгалды. Теге баланы монахлар кулыннан йолып алдылар, рәхимсез рәвештә кыйнарга тотындылар. Тәгаен, бала үтереләчәк иде, бары приставның килеп җитүе генә эшне үзгәртте. Мәгәр пристав артыннан үк пәйда булган атлы казаклар, сылтау чыгуыннан файдаланып, камчыларына татар агай-эне канын җитәрлек сеңдерделәр. Хәтәр нәрсә белән шаяра иде бу Фәрхетдин дә.

— Әйдәле, туган, — диде Хөсәен. — Безгә кереп, берәр чынаяк чәй эчик әле булмаса.

— Ә миңа андый-мондый начарлык эшләмәссеңме соң, бай абый?

— Юк, — диде Хөсәен, Фәрхетдиннең терсәгеннән тотып.

Алар кызу-кызу атлап Хөсәеннәр капкасына таба юнәлделәр.

Ә өч көннән соң Фәрхетдин Алафузов мастерскойларының бер тимерчелегенә чүкеч сугып торучы булып эшкә урнашты.

## ГАБИТОВЛАР ӨЕНДӘ

Шушы өйдә булган саен, Хөсәен туйганчы ял итеп, җан рәхәтлекләре алып кайта иде. Берниндн тәкәллеф ваклыклары булмаган урын. Барлык кеше тигез, сөйләнгән сүз әдәпле һәм тапкыр. Ә барыннан да битәр гүзәл музыка рәхәте...

Гафифә ханым, кырык биш яшьләрендәге таза гына гәүдәле мөлаем хатын — семья башлыгы. Ул ире Шәрәфетдин үлгәннән соң ерак Синьцзяннан Казанга кайтты һәм ике улы, ике кызы белән туган-үскән якларда гомер сөрә башлады. Ире зур белемле, Европа культурасын үзләштергән, рус, кытай, уйгур телләрен шәп белә торган кеше иде. Ул соңгы көннәренә кадәр Гулҗәдәге Россия илчелегендә хезмәт итте.

Рус патшасына хезмәт итте, мәгәр җаны-тәне белән туган иленең азатлыгы турында уйланып яшәде. Аның мондый хөр фикерлелеге, әлбәттә, эзсез калмады. Балалары да, хатыны да шул рухта тәрбияләнделәр. Һәм менә шуңа күрә Гафифәләр өе алдынгы карашлы Казан яшьләре арасында абруйлы урыннарның берсе булып санала.

Хөсәен бик яхшы белә: биредә еш кына «Шимбә» түгәрәге утырышлары уздырыла. Бу да алдынгы яшьләр оештырган нәрсә. Ислах хәрәкәтенә башлыча шәкертләр катнашса, шимбәчеләр күбрәк русча укучы татар яшьләреннән тора. Бу түгәрәк утырышларында алар кызыклы бәхәсләр алып баралар. Матур әдәбият, рус һәм көнчыгыш классикасы белән танышалар. Юк, алай гына да түгел, биредә белем арттыруда бер-берсенә ярдәм дә итешәләр. Мәсәлән, Хөсәен Мулланур Вахитовның Гарифҗан Мостафин дигән шәкерт белән үзара ярдәмләшүен белә. Мулланур Гарифҗанга рус телен үзләштерүдә ярдәм күрсәтә, ә соңгысы исә Вахитовны татарча укыта.

Хәер, ул гынамы соң...

Бүгенге чәй мәҗлесе күп нәрсәләр вәгъдә итә иде. Шуңа күрә Хөсәен Гафифә апаларга барабыз дигәч, биредә узган ел бер тапкыр булган Хәдичә, иртәдән театрга баруны планлаштырган булса да, бу ниятне шатланып үзгәртте.

Зур аш бүлмәсенең буеннан-буена сузылып киткән өстәлдә табын. Теге баштә Гафифә ханым үзе утыра. Зур оркестрның оста дирижеры кебек, ул әңгәмәнең барышы белән үзе идарә итә. Кунаклар табын янынан кузгалганнан соң гына, ул яшьләрнең үзләрен ялгыз калды-

рачак. Шул вакыт инде кунаклар төрле бәхәс, әңгәмәләргә, уеннарга керешәчәкләр.

Уң якта Фатих Әмирхан, аның белән рәттән Галиәсгар Камал, өстәл тирәсендә тагы ветеринария институты студенты Сөләйман Чанышев, Әминә Терегулова, Шакир Мөхәммәдьяров, Әбүбәкер Терегулов, Гафур Коләхметов, Габдрахман Мостафин, Гыймад Нугайбек, Солтан Рахманкулов һәм тагы Хөсәен танымаган яшьләр, урта мәктәп укучылары, гимназист, гимназисткалар. Юк, биредә бөтенләй башка дөнья, башка мөхит иде. Монда, гадәттәге татар өйләрендәгедәй, хатын-кыз ирләрдән аерым утырмый, йөзен яшерми. Күпчелек хатын-кыз ялан баш, ак кофта, кара юбкадан, вакытның модасы буенча ефәк бантлы. Ирләрнең күбесе европача киенгән, күбесе житү чәчле. Хөсәеннең каршысында гына реальный училище формасыннан Мулланур Вахитов утыра. Аның дулкынланып торган кызгылт-сары чәче, матур чиста зәңгәр күзләре, йөзенең аклыгы күпләрнең игътибарын үзенә тарта. Күрәсең, Мәжит Гафури исәнләшкәндә Мулланурның исемен хәтерендә калдырмагандыр, Хөсәен аңа бу чибәр реалист турында сөйләп утырды. Мулланур янәшәсендә аның туганнан туганы Нәби Вахитов, художество училищесы укучысы.

Чәй эчү ахырына якынлашып килә иде инде. Чынаяклар чыңлавы сирәгрәк ишетелә башлады, көлкеле сүзләр дә кимегән кебек булды. кайберәүләр «рәхмәт» әйтеп, чокыр каплый да башлады инде. Моны сизенеп һәм күреп торган Галиәсгар Камал аякка басты. Аның матур чем-кара күзләре нурланып, көлемсерәп тора. Хөсәен эченнән хәзер берәр кызык сүз әйтә инде, дип өметләнде. Ләкин Хөсәеннең атаклы күршесе бары белдерү генә ясады:

— Табынны жыештырырга тиешле кешеләрнең чәйдән соң монда калуы үтенелә, — диде.

— Без андый өмәгә катнашырга барыбыз да риза, — диде Фатих Әмирхан.

Галиәсгар, хәйләкәр генә елмаеп, мыегының сул як чылгыен бөтереп куйды.

— Юк. Бу эшнең махсус билгеләнгән кешеләре бар. Монда да призвание кирәк.

— Алайса, аңлашыла инде, — диде Фатих Әмирхан, — тик минем бер үтенечем бар: бу өмәдән Рабига туташны азат итегез.

Галиәсгар ни өчендер Гыймад Нугайбекка карап алды:

— Нишләтәбез?

— Минемчә, ярый. Аның роле...

Шул сүз аркасында бөтен сер чишелде. Калырга тиешле кешеләрнең театр уйнаячакларын аңлап, шунда ук мәжлес гөр килеп көлешергә тотынды. Мәжит Гафури Хөсәеннең күзләренә сорау белән текәлде.

— Хикмәт шунда, — диде Ямашев аңлатып, — алар, гадәттә, спектакльләрне күрше залда куялар. Ә андагы сәхнәгә ишек шушы бүлмәдән.

Мәжит тагы кызыксынды:

— Ә Рабига туташ кем соң ул һәм ул нигә азат ителергә тиеш?

— Ә ул Гафифә ханымның кече кызы, — Хөсәен ак тешләрен жемелдәтеп елмайды да: — Ә калганын бераздан үзегез күрерсез, — диде. Күрәсең, аның шагыйрьгә барысын да әйтеп бетерәсе килми, ниндидер күңелле бер сюрприз ясыйсы килә иде.

Чыннан да, тиздән кунаклар күршедәге зур, иркен залга чыктылар. Анда зәңгәр чаршау корылган сәхнәдән тыш, ул заманнарда татар өйләрендә бөтенләй сирәк күренгән зур купшы рояль да ялтырап тора иде. Яшьләр залга чыгу белән төркем-төркем булып стена буендагы утыргыч һәм канәфиләргә урнаштылар. Бераздан Рабига туташның му-

зыка уйнавын үтенә башладылар. Кыз, артык ялындырмастан, инструмент янына килде. Рояль капкачын ачып ноталарын барлады. Мулланур нота битләрен ачып тору өчен кыз янына ашыкты. Тиздән иркен зал эчен Чайковский музыкасының гүзәл авазлары күмеп китте. Барлык кеше тынып калды. Җайлы урнашкан кунаклар авазлар тудырган рәхәттә коена башладылар. Рабига туташ композиторның «Ел фасыллары» дигән пьесасын уйный иде. Хөсәеннең күз алдында табигатьнең уянган чагы җанланды. Яз җыры. Яз сулышы. Кояшта күзләрне чагылдырып аккан гөрләвекләр, кошлар сайравы...

Хөсәеннең йөзенә җиңелчә елмаю кунып калды. Һәм бу елмаю пьеса тәмамланганчы югалмады. Аның күзләрендәге төсмерләрнең үзгәрүе генә күңелендә музыка тудырган вакыйга-хәлләрне кичереп ләззәтләнүен белдереп тора иде.

Рабига уеннан туктагач, зал эчендә байтак вакыт серле тынлык хөкем сөрде. Кешеләр күңелләрне тутырган рәхәтлекне чайпалдырып җибәрүдән куркалар иде, ахры.

Ниһаять, Рабиганың олы абыйсы Мөхәммәтгариф тынлыкны бозды. Ул сеңелесе янына килде дә хәзер Моцартның «Бишек җыры» уйналачагын белдерде.

— Соң бит, абый, аны җырларга кирәк, — диде Рабига уңайсызланудан кызара төшеп.

Мөхәммәтгариф:

— Борчылма, сеңелем, монда җырлаучысы да табылыр, — диде. Ул читтә ялгызы гына утырган кара тутлы, реалист формасындагы яшь егеткә мөрәҗәгать итте:

— Яле, Солтан, кунакларга үзеңнең һөнәреңне бер күрсәт әле!

Оялчан егет каушавыннан нишләргә белмичә куырылып килде. Мөхәммәтгариф исә аның саен:

— Хәзер, кунаклар, безгә Солтан Рахманколый җырлап күрсәтә, — диде.

Рабига тагы телгә килде.

— Ничек инде, абый, бернинди репетициясез, нисез?.. Син кунакны уңайсыз хәлгә куясың!

— Сеңелем, хафа булма, зинһар. Әгәр син ул егетнең гармунда, мандолинада ничек шәп уйнаганын белсә идең! Ул инде бу көйне миңа үзе уйнап бер тапкыр гына җырламады!

Бу сүзләрдән соң, әлбәттә, яшь җырчыга бөтен залның игътибары юнәлде һәм барлык кеше кул чабарга кереште. Егеткә халык алдына чыгып басудан башка юл калмады.

Ул, чыннан да, моңлы, матур җырлый иде. Тавышы артык көчле булмаса да, тигез һәм күңелгә үтеп керә торган бер тавыш икән.

Җыр башкарылгач, Мәҗит Гафури түзмәде:

— Менә сез, туган, башкорт көйләренә әйбәт җырлар идегез, — диде. — «Буранбай»ны белми торгансыздыр?

Кинәт чаршау калтыранып, барлык залдагы халыкны үзенә таба каратты. Сәхнә алдына Галиәсгар Камал чыгып басты. Солтан җавап бирергә өлгерми калды.

— Хөрмәтле кунаклар, — диде Галиәсгар, — без бүген сезгә шушы сәхнәдән беренче мәртәбә үзебезчә театр уйнап күрсәтмәкче булабыз.

Зал тынып калды. Йөзләргә шатлык шәүләсе йөгерде. Ул да булмады, барысы бердән кубып кул чабарга тотындылар.

— Сабыр, сабыр, — диде Галиәсгар. Ул, елмая төшеп, уң кулын өскә күтәрде, — әле кул чабарга иртәрәк. Ни нәрсә килеп чыккандыр бит. Анысын тамашадан соң әйтербез.

Хөсәеннең яшьләр куйган берничә спектакльне караганы бар иде. Ләкин алар рус телендә иде. Бүген исә һәвәскәр яшьләрнең үз ана телләрендә уйнарга батырчылык итүе чын мәгънәсендә шатлыклы бер

вакыйга. Галиәсгар әсәрнең авторы төрек язучысы икәнлеген, тәрҗемәчесе исә үзе булуын әйтеп баш иде дә пәрдә артына кереп юк булды. Залдагы лампаларны сүндерделәр. Түземсезлек белән кунаклар пәрдәнең ачылуын көттеләр.

Мондагы күпчелек әле беренче тапкыр үз ана телендәге уенны карый иде.

Әйе, бу әле һәвәскәрләр уены. Барысы да моңарчы күп тапкырлар караган һәм күп тапкырлар сокланган рус театры түгел иде бу. Шулай да сәхнәгә чыккан егет һәм кызларның уеннары ни дәрәҗәдә беркатлы һәм ясалма чыкмасын, кунаклар барысын да гафу итәргә әзер тордылар. Һәрбер катнашучы никадәр грим астына яшеренмәсен, бер сүз әйтү белән үк үзенең кем булуын сиздерә иде. Кунаклар һәр яңа артистны танып үзара елмаешалар һәм ана уңыш телиләр. Хәлбуки, бер «артист» ролен житәрлек ятламаган иде, күрәсең, сәхнәгә чыккач, ул, таптанып, ни әйтергә белмичә, ык-мык килеп тора башлады. Сәхнә артыннан суфлер Гыймад Нугайбекнең пышылдап текстны укуы ишетелде. Юк, барып житми иде мескенгә. Суфлер тагы кабатлады. Бу юлы инде нинди сүз әйтелергә тиешлеген барлык тамашачы ишетте. Барысы да «бата башлаган» артистны коткару өчен суфлерлык итәргә керештe. Өнгә килә алмыйча азап чиккән егетне, ниһаять, мең бәла белән уятып, роленә кертеп жибәрделәр.

Уен мавыктыргыч иде. Беркемнең дә моңарчы артистлар өчен бу дәрәҗәдә үк янып-көеп спектакль караганы юк иде әле. Инде пәрдә төшәргә якынлашканда, Хөсәен, янтыгына орынып, хатынының үзенә нидер әйтергә теләвен тойды. Борылып караса, артта өй хуҗасы Гафифә ханым тора иде. Ул Хөсәеннең колагына иелде, хуш исләр аңкытып пышылдады:

— Сезне ниндидер бер ир кеше чакыра, Хөсәен әфәнде.

— Мине? — диде Хөсәен хәйран калып. Күңелне сызып төрле шикле уйлар узды. Бәлки, өйдә тентү-мазардыр? Бәлки, иптәшләр белән берәр бәхетсезлек килеп чыккандыр?

— Нинди кеше соң ул? — дип сорады Хөсәен.

— Эшче булса кирәк, шундый гади кеше, — диде Гафифә ханым. Хөсәеннең күз алдына шул ук секундта Гыйльфан килеп басты. Мөгаен, шулдыр. Бер-бер хәл булгандыр. Хөсәен ашыгып алгы якка чыкты һәм чыннан да гади эшче киемендәге кешене, ләкин Гыйльфанны түгел, ә Җәгъфәрне күреп аптырап калды. Хөсәен аның Казанга кире кайтуын һәм сабын заводына эшкә урнашканлыгын ишеткән иде. Ләкин ничек, ни сәбәптән ул биредә? Хөсәен гаҗәпсенә төшеп, Җәгъфәрнең кулын кысты. Шунда егетнең бераз кызмача булуын аңлап йөзенә карады.

— Мин синең Казанга кайтып урнашуыңны ишеттем. Ләкин монда очрашырбыз, дип уйламаган идем, — диде ул.

— Гафу ит, Хөсәен дус, гафу ит, — диде Җәгъфәр. Ул ничектер авызын чалышайтып, исерек бер кыяфәт белән текәлеп торды.

— Берәр ашыгыч эш килеп чыктымы әллә? — диде Хөсәен. — Сине монда кем жибәрде. Син бездә булгансыңдыр, ахры.

— Мин синең монда булуыңны бөтенләй белмәдем дә, — диде Җәгъфәр, — әгәр беләсең килсә, син миңа бөтенләй кирәк тә түгел.

— Ничек инде алай, син бит атап мине чакырткансың? Димәк, минем монда икәнлегемне белгәнсең?

Җәгъфәр Хөсәенне кочаклап алды.

— Хөсәен, Хөсәен, — диде ул еламсырап. Башын Хөсәеннең жилкәсенә куеп мышкылдарга керешге. Юк, бу исерек белән хәзер рәтләп сөйләшү мөмкин түгел, аны тизрәк озатырга кирәк иде.

— Туктале, туктале, ничек син үзең белмәгән чит кешеләргә сәрхүш килеш керергә оялмадың? — диде Хөсәен. Ул арттан үзләрен күзәтеп торган Гафифә ханымга: «Хәзер без...» — диде дә киенә башлады.

Бераздан Җәгъфәр белән Хөсәен өй янында тротуарда басып торалар иде инде.

— Менә монда рәхәтләнеп теленә ни килде шуны сөйли аласың инде, — диде Хөсәен корырак тон белән. — Я ничек урнаштың? Кара эштән курыкмыйча, заводка керүең өчен мактаудан гайри бер сүзем юк...

— Шулай дисең син, ә мине — рабочине — байлар өеннән үзең фьют, ә? Киемнәрдән сасы ис киләмени?

— Киемнәреңне гаепләмим, ләкин үзеңнән чыннан да сасы ис килә. Бу урынга исереп килмиләр.

— Ха-ха, әйтерсең лә, мин белмим. Мин сине, Хөсәен, болай гына, бәлки ярдәм итәрсең дип кенә чакырттым.

— Нинди ярдәм?

— Хәзер әйтүдә файда юк.

Хөсәеннең чын-чынлап хәтере калды.

— Бу нинди хәл инде, Җәгъфәр, син нинди дер сәер табышмакка әйләндең.

— Әйдәле, утырыйк әле шушында, — диде Җәгъфәр күрше өй капкасы янындагы эскәмиягә таба атлап. Утырышкач, Җәгъфәр бирегә бары Гафифә ханымның кече кызы Рабиганы күрү өчен генә килгәнлеген әйтте. Ул күптән белә икән аны. Ул аңа гашыйк икән. Ләкин моңарчы килә алмаган. Ә бүген исә Җәгъфәр Рабига белән турыдантуры сөйләшергә тиеш. Хәтта ул менә шуның өчен генә хәмер эчкән дә. Җәгъфәр юри үзенең рабочий киемнәреннән килгән. Күрсен. Гади эшче икәнлеген белсен. Аннан үзенең карарын чыгарсын. Сөяме ул Җәгъфәрне, юкмы?

— Мин аңа үзең өзелеп яратуымны изһар итмәкче идем, — диде Җәгъфәр.

— Соң Гөлҗиһан ничек инде болай булгач? — диде Хөсәен, хәйләкәр көлемсерәп.

— Мин Гөлҗиһанны беркайчан да сөймәдем, — диде Җәгъфәр житдиләнеп. Ул Рабига турындагы сүзен дәвам иттерде. Әле Җәгъфәр бик батырланып Габитовларга килеп керә, ләкин каршысына кызның анасы чыккач, тәмам каушап, өнсез кала. Моңарчы корган планнары шундук җимерелеп, Гафифә ханымның нурлы ак йөзен, аның кешене үтәли күрердәй итеп каравын аңлагач, егет коелып төшә. Шунда ничектер хәтеренә Хөсәен килә һәм ул, үзе дә сизмәстән, шуны эзләп килгән идем мин, ди.

— Менә нәрсә, — диде Хөсәен, урыныннан торып, — синең ахмаклыгың аркасында мин бик ләззәтле бер нәрсәдән коры калдым. Бар син өеңә кайт, иртәгә сөйләшербез. Кил. Ләкин исерек булма.

— Нәрсә, син мине куасыңмыни шулай?

— Мин сине кумыйм. Яраткан кызың янына исереп керергә ярамый икәнлеген әйтәм.

— Менә күрдеңме ничек? — диде Җәгъфәр ачынып. — Мин бай чакны мине якын күрә идең, ә хәзер кара эшчегә әверелгәч, миннән чирканасың!

— Ахмак сүз сөйләмә. Иртәгә барысын да сөйләшербез. Бар.

Хөсәен кулын да бирмәде, ашыгып парадный ишегенә таба китте. Тоткага үрелер алдыннан Җәгъфәргә күз салды. Бу вакыт Җәгъфәр чайкала-чайкала таудан төшеп бара иде. «Тинтәк, — дип уйлады Хөсәен, — әгәр син ул Гөлҗиһаныңнан котылып, саф мәхәббәт артыннан йөрисен икән, сиңа хөрмәт һәм мактау. Тик нигә исерергә?!. Тинтәк!»

Ул бераз вакыт Җәгъфәрне карап торды. Егет тау астына китеп күздән югалгач, тиз генә ишекне ачты. Аның Мәҗит Гафури белән сөйләшәсе бар, аннары Фатих Әмирханга да әйтәсе сүзе калган иде. Теге көнне Галиәсгар Камал белән бәхәсе дә тәгәлләнмәгән иде. Татар телендә куелган беренче спектакльне дә карап бетерергә кирәк бит.

*(Дәвамы бар.)*



*Ленин!*
*Ленин!*
*Ленин!*
*Баррикадаларда,*
*Сарайларны җимергәндә,*
*Бомбалар,*
*Утлар эчендә,*
*Төрмәләрдә,*
*Шахталарда*
*Син идең безнең белән.*
*Канлы кырларда сугышканда,*
*Синең шәүләң һаман*
*Безгә ак юллар сызып торды*
*Азатлыкка табан!*

*ҺАДИ ТАКТАШ*

*Ибраһим Гази*

# КЫЗЫЛ ТОМАННАР АРТЫНДА...

## Хикәя

Тау өстеннән Иделгә карап тора торган борынгы шәһәр урамында бер карт йөри. Ул эшләпәсен басып кигән (шәһәрдә җил!), таякка таянган, уң аягын өстерәбрәк атлый. Бара-бара да туктый, карап тора, аннары янә кузгалып китә... Ул инде картайган, ашыгыр җире юк. Туктаган чагында нидер үз алдына сөйләнеп тә куя бугай...

Аның янында тагын берәү бар. Бусы яшь. Бусы малай гына. Күп булса унбишләрдәдер. Ябык. Какча. Иңендә винтовка. Шомарып беткән иске винтовка. Уставча әйтсәк, винтовка образца восемьсот девяносто первого года. Өч кырлы үткен штык, малайның башындагы кепкасын узып китеп, зәңгәр күккә барып кадалган. Кадалып ук җитмәсә дә, кадалырга нияте юк түгел. Егетнең (ул үзен, әлбәттә, егет саный!) каты адымнары астында иске шәһәрнең такта тротуарлары шак-шок итеп

калалар. Картның өстерәлә торган уң аягы тротуарны сыдырып-сыдырып куя. Икесе дә сөйләшми генә атлыйлар.

Болар кемнәр дисезме? Болар картлык белән яшьлек. Үзенең яшьлеген иярткән карт борынгы шәһәр урамыннан бара. Штык очы белән зәңгәр күкне тырнап, урамнан җил-җил атлаучы какча малай аның яшьлеге ул. Аның комсомол чагы... «Әтчәйни башка» чагы... Искә төшерү рәхәтенә бирелеп, абзагыз кайчандыр үзе яшәгән, үзе бандитлар белән түбәләшкән, кызлар сөйгән шәһәрдә йөри...

...Яңа урамнар... Яңа биналар... Шәһәр үзенең элекке урынына сыеша алмый башлаган. Яңа киң мәйдан эзләп, кырга таба чыгып киткән... Абзагыз янага исе китеп, яңага куанып, яңа арасыннан искене табарга тырышып йөри. Үзенең моннан күп еллар элек «төшеп калган» яшьлек эзләрен табарга йөри ул. Шәһәрне ул таный алмый. Шәһәр дә аны таный алмады. Ә бит кайчандыр аны монда белмәгән кеше юк иде. Җыелышларда аның ялкынлы сүзләрен йотлыгып тыңлыйлар иде. Стеналарны дер селкетеп кул чабалар иде. Ә бүген бер төркем яшь-җилкенчәк, тротуарга сыеша алмыйча, абзагызны этеп узып китте. Үпкәләми. Һич. Яшьлек шулай игътибарсыз була инде ул. Нининдер аксак карт синең юл өстеңдә комачаулап басып торсын, имеш тә, син төртеп тә узма, имеш. Үпкәләми генә түгел, куана әле абыегыз, шәһәрне тутырып йөри торган матур яшьлекне күреп куана. Әнә бит алар ни рәвешле очынып, атлыгып, җилкенеп баралар... Бара бирсеннәр, замана аларныкы. Килер бер көн, аларны да төртеп узып китәрләр. Бүгенге көн аларныкы. Яшьлек, матурлык алар кулында...

Менә картыбыз болай да акрын адымнарын тагын да акрынайта төште. Басып кигән эшләпәсен күтәребрәк җибәреп (әйдә, җил алса алсын! — дөньяда бер иске эшләпә кимрәк булыр), ике катлы таш йортның тоник пыялалы зур тәрәзәләренә карап тора башлады. Гүя бу тоник тәрәзәләр, тәрәзә булмыйча, абзагыз өчен бик кадерле матур күзләр! Гүя бу күзләр аңа әллә нинди серләр сөйлиләр... Менә агайның иреннәре кыймыл-кыймыл итеп тордылар да сизелер-сизелмәс кенә елмайдылар. Таш йортның серле карашына ул гүя шулай серле елмаю белән җавап бирде.

Чү! Кемнең ул анда күз төпләрендә яшь тамчысы елтырап китте? Күрмәгез, елтырый бирсен. Абыегыз эшләпәсен күзенә үк төшереп киде дә капка төбендәге иске эскәмиягә авыр гына килеп утырды.

Заманында бу йорт бик мәшһүр иде. Шушы йортның бит инде залларында ялкынлы ораторлар, йодрыкларын чөя-чөя, төнлә дә, көндез дә митингларда кайнадылар. Шушы йортның юнылмаган такталардан корыштырган сәхнәсендә бит инде, кызыл сугышчылар файдасына «Галиябану»ны уйнаганда, абзагызны ничәмә тапкыр атып үтерделәр. Һәм, ниһаять, шушы йортның кайнап торган залыннан бит инде, Колчак явына каршы «Тимер батальон» сугышчылары язгы таңда сугышка чыгып китте. Ә бит аларның күбесе үз өйләренә кире борылып кайта алмады (эшләпәбезне салып, ул изге җаннарны искә алыйк!). Һәм, ниһаять, җәйге аҗаган ялкынылай ялтырап, бер Кешенең, безгә бик таныш Кешенең, беренче шашкын мәхәббәте шушы йортның тыңгысыз залларында кабынды бит...

Абыкаем, таш йорт... Картайгансың, җаным. Син дә картайгансың. Баскыч такталарыңны агач корты ашаган. Тәрәзә пыялаларың яшел чәчәк аткан...

Агагыз, җиңелчә көрсенеп куеп, эскәмиядән күтәрелде. Бу баскыч басмалары кайчандыр ямь-яшь иде. Аларны көн саен сап-сары итеп юып чыгаралар иде. Шушы сап-сары, чип-чиста баскыч басмаларыннан ул, кулына корал тоткан килеш, бер матур җәйге иртәдә чыгып киткән иде.

Әнә күрәсезме, штык очы белән иртәнге салкын томаннарны ертып, унбиш яшьлек бер кеше бара... Кепкасын баш чүмеченә генә элеп куйган. Аяк атлаулары ут. Кыяфәтендә бераз гына яшь әтәчлек тә бар бугай. Янәсе, диңгез безгә тубыктан!.. Әнә ул, иңбашын сикертеп куеп, винтовкасын уңайлабрак җибәрде дә адымнарын кызулый төште.

Кояш Идел аръягындагы кызыл томаннар артыннан яңа гына күтәрелеп килә, ә егетнең иңендә винтовка... Юк, ул Колчак явына каршы сугышка китми. Аны «Тимер батальон»га алмадылар. Янәсе, бик яшь. (Нишләп соң ул бер ике-өч елга алданрак туасы итмәгән?) Ярый ла аңа уналты тулганчы Колчакны бетереп куймасалар.

Алмадылар. Колчакка каршы бару насыйп булмады. Ул бүген бандит тотарга бара...

Урманда бандитлар күп. Алар анда хуҗалык корып, сыерлар, кәҗәләр асрап яшиләр. Крестьяннарның көтүдән аерылган терлекләрен тотып суялар, үсеп утырган бәрәңгеләрен казып алып китәләр. Хәтта шәһәр пекарнясының яңа пешкән бер мич икмәген талап качтылар. Менә шул талаудан соң инде шәһәрдә комсомоллардан кораллы отряд оештырылды.

Абзагыз үзенең картлыгын да онытты бугай. Эшләпәсен салып, чал чәчләрен җил ихтыярына бирде. Ирен почмакларында елмаю нуры тетри... Аның тәҗрибәсез Яшьлеге, винтовка асып, җәйге таңда бандит тотарга китте бит.

...Кызыл томаннар куеныннан чыгып килә торган кояш артта калды. Ак чәчәктә утырган алма бакчалары да артта... Шәһәр йортлары өелешеп шулай ук артта калдылар, алда серле урман. Серле һәм бандитлы... Бандитлы һәм шомлы... Кесәдә биш патрон...

Янында иптәше Салих. Салих инде олы кеше — быел унҗидене тутырды. Буйга да аллага шөкер генә. Тәне мускул да сөяк, сөяк тә мускул. Спектакль уйнаганда аңа эшчеләр ролен бирәләр. Бу роль гадәттә сүзсез була. Салих үпкәләми. Җиңнәрен сызганып торып җибәрә дә (ходаем, биргәнсең кешегә мускулларны!), чыраена җитди төсләр чыгарып, сәхнәдә арлы-бирле узгалап йөри.

Салих белән аларның икесен комсомолга бер үк кичне алдылар. Җыелыш ябылгач ук, ячейка секретаре Ногманов (мәрхүм, Ватан сугышы кырларында ятып калды) «табадан гына кубып төшкән» бу ике комсомол кисәген кораллы отряд исемлегенә теркәп куйды да әйтте:

— Озакламый сынау үтәрсез!

Менә бүген алар сынауга бара. Яннарында тагын ике кеше... Болары өлкәнрәк, хәтта бик өлкән инде: егермедән узып киткәннәр. «Яшел» комсомолларга башлык булып баралар. Берсе боларга бөтенләй дә таныш түгел. Икенчесе таныш. Комсомолның өяз комитетында эшли. Фамилиясе Кояшов. Ләкин үзе бер дә кояшка охшамаган. Кигән киеме кара күн пинжәк, кара күн итек. Пинжәгенең уң кесәсен авыр наган басып ерткан. Кояшов аның үз фамилиясе түгел, комсомол биргән фамилия. Исем-фамилия алыштыру чиргә әйләнеп бара. Салих, мәсәлән, комсомолга керүе булды, исемен Спартак дип үзгәртте. Хәтәррәк исем табылса, безнең егетнең дә алыштырырга нияте юк түгел. Кепканы бу тикле «әтчәйни» итеп кырын сала белгәч, күкне күк хәтле штык белән тырнатып йөри алгач, бандит тикле бандитны ауларга йөрәге җиткәч, нишләп ул Габделмәҗит дигән, мулла кушкан иске заман исемен тагып йөрсен? Нишләп аңа, әйтик, Марат дигән, француз буржуйларының йөрәген тетрәткән атаклы исемне алмаска да үзенә дә атаклы булмаска? Жан-Поль Марат! Янсә Робеспьер! Ярый, анысы соңыннан. Бандит тотып кайткач...

Габделмәҗит күргән саен аптырый: ни чуртыма дип Кояшов күн итек өстеннән тагын резин калош та киеп йөри икән? Күн итек үзе бит

инде пычрак ярыр өчен киелә... Илдә аяк киеме житмәгән бер заманда... Бер үзе ике аяк киеме туздырып йөри. Ә муенында Кояшовның ефәк шарф! Җәй көне ефәк шарф!?

Абзыкай шушы урында тагын көлемсерәде. Эшләпәсен учы белән басып куйды (жил тәмам тилерде!). Ул вакытта кем уйлаган бит аны... Кояшов шушы ак ефәк шарфы белән үзенең якасын каплап йөридер дип кемнең башына килгән...

Башлыкларның икенчесен Габделмәжит танымый. Анысы да баштанаяк карага киенгән. Тик чалбары гына кызыл. Кызыл галифе! Аны барлык кеше дә кия алмый. Үлем белән бер котелоктан тары бүткәсы ашаган батыр сугышчының гына кызыл галифе киярга хакы бар. Чырайлары яман да кырыс. Күз карашлары яңа кайралган пәке очы! Кара-каршы очрашып, күзгә-күз карашканда, бу караштан сискәнеп куясың... Ул, бер сүз дәшмичә, шым гына атлый. Ә болар, ике пешеп житмәгән, сынау узмаган комсомол валчыгы, бу «пәке күздән» читкәрәк тайпылып, кояш кебек үк якты булмаса да, шактый үк якты чырайлы Кояшовка сыеныбрак баралар.

Артта арба тәгәрмәче зурлыгы кызыл кояш... Чәчәк аткан дымлы бакчалар... Баш өстендә иртәнге тургай җыры... Алда урман. Бандитлы, шомлы...

Урман түгел — яшел стена. Килеп туктадылар. Атлы милиционер каршы алды. Яшь кенә милиционер. Елмаеп кына сөйләшә торган матур милиционер.

«Бандитны да ул елмаеп кына тотамы икән?» дип гаҗәпләнде бүгенге Габделмәҗит, иртәгеге Робеспьер.

— Шушылармыни? — диде милиционер, ак кяген комсомолларга таба сузды. Аннары Кояшов белән нидер сөйләште дә сикереп яңадан атына атланды. Чаптырып китеп барганда, артына әйләнеп карап, тагын елмайды...

— Сигналны онытма! — дип кычкырды.

Ул заманнардан бирле илле елга якын вакыт үтеп китте. Илле ел... Абзагызның күз алдында әле бүген дә яшь милиционер елмаеп басып тора. Гомерлеккә ул шулай елмаеп күңелгә кереп калды. Аннары тагы атына камчы орып чаптырып китеп баруы күз алдында...

Яшь милиционерның шул бәрелештә үтерелүен Мәҗит соңыннан гына ишетте, чөнки үзе дә больницада озак ятты. Тәненнән ярып бандит пулясын алдылар. Аягыннан түгел, аяк өстерәлү анысы Ватан сугышыннан калды. Ул полк комиссары иде. Мина шартлап, Висла елгасы буендагы плацдармда аягын яралады.

Милиционер чаптырып китеп барганнан соң, урманның зур яшел авызы боларны әкрен генә йота башлады. Кошлар сайрый-сайрый озата бардылар. Биш патрон... Биш патронда биш пуля... Биш үлем... Биш гомер... Габделмәжит әле кайчан гына бу серле урманда җиләк җыеп чабып йөргән иде. Ул вакытта урман бу тикле серле дә, шомлы да түгел иде. Кайчан гына әле ул юеш борынлы бер малай иде. Бүген бандит тотарга бара...

«Пәке күз», ауга чыккан ерткыч җанвар кебек, сак һәм йомшак атлый. Юеш үләндә Кояшовның резин калошлары чыланды, ялтырады... Салих җиңнәрен сызганып җибәргән — гадәт! Габделмәҗитнең аяк астында коры чыбык шырт-шырт сына...

Винтовкалар корулы... Көпшә «төкертергә» әзер тора... Яфраклар чатырын үтеп, беренче җылы нур урманга керде — иртәнге кояш нуры... Урман эче баягы кебек караңгы түгел. Урман эче күнелле яшел. Агач очлары арасында кул аулыгы хәтле генә күк бите, зәңгәр күк бите... «Моннан ерак түгел чишмә булырга тиеш», — дип, Мәҗит үткән җәй су эчкән чишмәне исенә төшерде.

— Син, — диде Кояшов. Аның наган көпшәсе Габделмәҗиткә таба сузылган иде. — Син...

Аның сүзен бүлеп, Салих:

— Юк, мин барам, — дип алга килеп чыкты.

— Син, — дип дәвам итте Кояшов, Салихның бүрткән мускулларына тамчы да игътибар итмәстән, Габделмәҗиткә карап: — Син югалган сыерыгызны эзләп йөрисең. Безнең алда чишмә юлы. Бандитлар шул чишмәдән су эчәләр. Аңладыңмы?

Калганын «Пәке күз» аңлатып бетерде. Алар икәү чишмәгә килеп җиттеләр. Чишмәнең салкын сулышы битләренә бәрелде.

— Винтовкаңны бир, — дип боерды кинәт кенә «Пәке күз». — Сал ботинкаңны. Кепкаңны да... Сукмак сине туп-туры землянкалар эченә алып чыгар. Онытма — син сыер эзләп йөрүче авыл малае. Я, уңыш телим!

Ул Габделмәҗитнең чат сөяк аркасыннан кочты: хикмәт... күзләрендәге «пәке очлары» юкка чыктылар.

— Эләксәң, дөньяда юкны ялганла. Эләкмәскә тырыш! Син артистмы?

— Клубта уйныйм.

— Эләгә калсаң, сыер эзләүче авыл малаен уйна. Мин сине чишмә янында көтәм. Хәерле!.. Тукта!.. — дип, ул Мәҗитне кинәт янадан туктатты. — Билетыңны калдыр.

Габделмәҗит комсомол билетын кесәсеннән чыгарып бирде дә тизтиз үргә таба менеп китте. Сукмак туп-туры гына землянкалар өстенә алып чыкмады. Сукмак чәбәләнде, боргаланды, урады... Тирән чокырлар эчләп чапты... «Дөньяда юкны ялганла»... Ялганла, ялганла...

Каеннар Мәҗитне ышыклап алып бардылар. Тирән чокырлар яшереп алып барды. Агач очлары арасындагы «зәңгәр тәрәзәләр» табигый матур дөнья белән бәйләп торды...

Габделмәҗитнең беренче күргән нәрсәсе сыер башы булды: агачлар арасында ак маңгайлы зур баш. Сыерның корсак астында сакаллы түти сөт савып утыра иде.

Мәҗит, тын алырга да куркып, абага үләннәре өстенә ятты... Йөрәге дөп! дөп! тибә. Гүя күкрәк эчендә чүкеч белән бәреп торалар... Землянка моржаларында ак төтен. Өч землянка. Өч төтен. Сыер койрыгын селти, кигәвеннәрне куа... Сакаллы түти савa да сава... Мәҗитнең сулышы күкрәгенә сыймый...

Землянкадан тагын бер Сакал килеп чыкты. Чыкты да, нигезгә утырып, тәмәке кабызды... Чакмадан очкын очырып кабызды. Бандитның авызыннан гөтен чыга, землянкалар моржасыннан да төтен чыга... Сыер койрыгын селти...

Мәҗит бандитларны саный. Сыер белән бишне санады. Ике мөгез, дүрт сакал... Бер Сакал винтовка тоткан. Ары-бире йөреп тора... Сыер савучы, савытын тотып, землянкаларга таба китте. Бер бандит тегенең кулыннан савытны алды да күтәреп эчте. Икенчесе дә эчте. Савыт кулдан-кулга китте... Иң ахырдан сакаллы түти үзе эчте.

Сөяп куйган винтовкалар... Сакаллар бер керә, бер чыга... Мәҗит буталды. Берсенең билендә граната...

Карт кешенең үткәнгә хәтере бик яхшы. Абзагызның бүгенге кебек күз алдында: винтовкалы бандит Мәҗит поскан якка карап торды-торды да әкрен генә килә башлады. Килә...

Кояшка җылынырга чыккан яшькелт кәлтә еланы елт-елт яфраклар арасына кереп югалды. Мәҗит елт-елт чокыр эченә шуышып төшеп китте. Чүкечләр дүрт куллап күкрәкне кыйный башладылар. Бандит әллә күргәндер дә... Атып калучы булмады.

Сукмактан ун адым алга сикерергә дә өлгермәде, каршысына... Мәҗит кычкырып җибәрә язды. Каршысына наган тоткан «Пәке күз»

килеп басты. Габделмәҗит тыны бетеп, лып туктады: «Ышанмаган, артымнан килгән...» Мәҗитнең үз күзләрендә дә хәнҗәр очы ялтырап куйды.

— Ышанмаган дип уйлама, — диде «Пәке күз», Мәҗитнең уйларын күңеленнән укыган кебек. — Сине саклап килдем...

... Чуалып беткән чал чәчләрен җил иркенә ташлап, тротуарда басып торучы сәер картка яшьләр карап узалар. Әллә теле кешеме? Күзләре бик аларган!

Картның күзләре чынлап та иләс-миләс... Үтеп баручы яшь җилкенчәкләрне әллә ул бөтенләй дә күрмидер... Аның уйлары еракта.

...Бәрелеш вакытында беренче Мәҗит яраланды бугай. Яраланганнан соң да ул әле берара йөгереп барды, аннары гына егылды. Мәҗит тагы шуны хәтерли: агач очлары сәер генә мәтәлделәр дә җиргә кадалдылар, үләннәр аның битенә сикерде...

Аңына килгәндә ул яфраклы агач носилкада тирбәлеп каядыр бара иде. Дөресрәге, кемнәрдер аны алып баралар... Янында «Пәке күз» атлый. Карт милиционерлар атлыйлар. Аннан соң больница, ак халатлы кешеләр... Дару исе...

Хәл белергә Кояшов та килде. Бу юлы ефәк шарфын бәйләмәгән иде. «Пәке күз» килеп бер шакмак шикәр биреп китте. Зур шакмак. Зәңгәр шакмак...

— Икесе төрмәдә, берсе күрше палатада ята, — диде ул.

Мәҗит сүзнең бандитлар хакында барганын аңлады.

Салихка тагын эшчеләр роле биргәннәр. Бу юлы бер-ике сүзе дә бар. Салих аларны инде күңелдән бикләп тә өлгергән. Мәҗиткә сөйләп күрсәтте.

— Мин хәзер, беләсеңме, өч потлы гер белән менә болай гына уйныйм, — дип мактанды.

... Аксак агайны бүген Идел баскычыннан пароходка төшеп барган чагында күрделәр. Кулында эшләпәсеннән, таягыннан гайре бер нәрсәсе юк иде. Баскыч тоткасына сыенып, ул шау-шулы яшьләрне уздырып җибәрә, яшьләр йөгерә-йөгерә төшәләр, ул аларга сокланып карап кала... Аннары ул зәңгәр күккә таба менеп киткән текә баскычка әйләнеп карый, текә тауларга карый. Күрсенә. Полковник Баязитовның («Пәке күз») Ржев янындагы каты сугышларда һәлак булганын ул белә иде, ә менә Кояшовның исәнлеген тик бүген генә ишетте. Кояшовны ул соңгы тапкыр утыз җиденче елны Казанда очраткан иде. Аны: «Ник кеше фамилиясе белән йөрисең?» дип гаепләгәннәр. Чөнки метрикасында Кояшов түгел, Әбсәлямов. Партиядән чыгарганнар иде. Ә Салихның үзен ул инде күптән югалтты. Агрономлыкка укыган дип ишеткән иде, дөрес булгандырмы? Ул хәтле каты мускуллар белән агроном кеше нишләде икән?

Менә шундый хәлләр.

Июль, 1967.

— — □ — —

*Мәҗит Гафури*

## Кызыл байрак

(Кыскартып алынды)

Кара син алга!
Күрәмсең анда
Кызыл байракны,
Буялган канга.

Көчле эшчеләр
Күтәргән аны,
Буялган аңа
Шәһитләр каны.

Хөрлек, тигезлек —
Аның шигаре,
Һәммә байрактан
Тора югары.

Шунда хакыйкать,
Шунда чын иман.
Кузгал, эшчеләр!
Таң калсын җиһан.

1917.

*Ибраһим Йосфи*

## Байларга

Тукта, буржуй, юкка авызыңны ерып көлмәле,
Бик ерак ул, чын сөекле Колчагың, тиз көтмәле.

Көтмә юкка ул килер дип, ул киләлмый мәңге дә,
Тиз аны безнең кылыч җирдән озатыр мәңгегә.

Без юк иттек: Корнилов, Дутов, Каледин... барчасын,
Без тараттык индәен көчле немецның патшасын.

Без көтәбез тик бераз форсат, моны без эшлибез,
Колчагын һәм башкасын без чүпкә дә соң күрмибез.

Без корырбыз киң фронтларга чуеннан стена,
Газраилдәй без барырбыз Колчагыңның өстенә.

Без көтәбез тик бераз форсат, моны без эшлибез,
Бар җиһанны коткарырлык чын куәтле, көчлебез.

Ел йөрербез, кайтмабыз ташлап фронтны үлмичә,
Я Себергә дә кызыл байракны илтеп элмичә.

1919.

——□——



*Сафа Сабиров*

# ДУЛКЫННАР НИ СӨЙЛИ...

*Очерк*

Кама буйларына да көз килеп җитте.

Хәер, көз инде күптән үз эшенә керешкән: яшел тугайларны саргайтып, тал-тирәкләрнең яфракларын коеп йөри ул. Су читләрендә, тәбәнәк атауларда әрәмәләр сирәгәеп, ялангачланып калганнар. Биек яр өсләрендә мачтадай төз кәүсәле наратлар гына, көзнең салкын сулышына бирешмичә, яшел киемле сакчылар кебек, горур торалар.

Һәркайда сугыш галәмәте күзгә ташлана. Кызыл Армия һәм хәрби флотилия басымына каршы тора алмыйча, ашыгып чигенүче дошман гаскәре, революция яклы кешеләрне кырып, шәһәр-авылларны җимереп бара. Пристаньнар, тау итәгендәге авыллар кара көеп утыра. Имин елларда әледән-әле пароходлар, кәрваннар, балыкчы көймәләре үтеп торган су өстендә дә хәрәкәт юк. Тик фарватердан читкәрәк китеп, сул як ярга ышыкланган хәрби флотилия кораблары гына, ялга туктаган кыр казлары кебек, тезелешеп якорьда торалар.

Иң алда, әрәмәле атаудан бераз түбәндәрәк — «Ваня — коммунист» корабы. Аны шартлы рәвештә генә хәрби кораб дип атарга мөмкин. Чынында ул баржалар һәм саллар тартып йөртә торган бер гади буксир пароходы гына. Хәзер аның палубасында — туплар, мостигында — пулеметлар. Кешеләргә дошман пулясы тимәсен, дип рубканың тышкы ягына ком тулы капчыклар әрдәнәләп өелгән.

Флотилиянең хәрби комиссары һәм командующий урынбасары Николай Маркин үзе дә «Ваня — коммунист»та. Әнә ул каютасыннан чыгып килә. Өстендә — җиз төймәле кыска бушлат, башында — кара бескозырка. Әле егерме алты яшьтә генә булса да, сакал-мыегы аны бераз олыгайтып күрсәтә. Әмма яшьләрчә җиңел хәрәкәтләре, җаенке

кашлары астыннан төбәлеп караучы зур коңгырт күзләре аңарда бетмәс-төкәнмәс энергия сакланганын әйтеп торалар.

Маркин, җиңел ядымнар белән мостикка менде дә, бинокль алып, әйләнә-тирәне күздән кичерә башлады. Томан таралган. Шактый югары күтәрелгән көзге кояш әйләнә-тирәне бик ачык күрсәтә. «Ваня — коммунист»тан түбәндәрәк, сул як ярга сыена төшеп, кораблар тора. Николай Григорьевич һәр корабка тукталып, игътибар белән карап торды, аларның һәркайсы үткән авыр юлны, Югары Ослан, Казан, Чистай, Чаллыны азат итү өчен барган сугышларны, һәлак булган сугышчан дусларын хәтерләде. Ленин фәрманы белән бу флотилияне ул үзе төзеде. Һәр кораб аңа үз баласы кебек якын. Ул аларны Сормово һәм Паратск эшчеләре белән бергә кораллапдырды, командирларын, тупчыларын, пулеметчыларын җыйды, өйрәтте, алар белән бергә үзе дә үсте, чыныкты...

... Елганың уң як яры дошман кулында әле. Анда сары камыллы, сарутлы киң кырлар буйлап Казаннан бәреп чыгарылган дошман солдатлары чигенә. Кичә разведчиклар Пьяный Бор атавы артында аклар флотилиясе тупланган булуын, һәм аларның Колчак гаскәрләрен елга аша күчерергә әзерләнүен кайтып әйттеләр. Маркин, дошманның мәкерле планын өзү максаты белән, таң алдыннан елганың сул як ярына десант җибәргән иде. Ике туп, бер пулемет белән коралланган десантның командиры Карташевка ул саубуллашкан чакта болай диде:

— Дошман кораблары торган урынга сиздертми килергә тырышыгыз, туплардан, пулеметлардан кинәт ут ачыгыз. Алар паникага төшсен, көтелмәгән атакадан куркып калсыннар. Ә шул чакны без үзебезнең кораблар белән бу яктан китереп бәрербез.

Исәп буенча десант инде барып житәргә һәм дошман корабларына ут ача башларга тиеш. «Ваня — коммунист» мостигында торучыларның күз карашы энә шул якка төбәлгән. Барысы да атау артыннан разведчикларның һөҗүм башлаганын көтәләр. Сигнал гына булсын — флотилия дәррәү һөҗүмгә кузгалачак.

Николай Карташев отрядын озатканнан соң, разведкага тагын тиз йөрешле ике бронекатер җибәрелгән иде. Дошман аларны күреп алды ахрысы — атау артыннан кораблар чыга башлады. Менә беренче снаряд Кама өстенә төшеп, биек су баганасы күтәрде. Шундый ук баганаларның тагын ике-өч төштә күтәрелүен күрде Маркин. «Нәрсә бу? Карташев отряды нигә атмый?» — дип борчылып уйлап алды. Нәкъ шул минутта агачлар арасыннан дошман өстенә ут ява башлады.

Дошманны туктаусыз әзәрлекләргә өйрәнгән кайнар йөрәкле Маркин бу бәрелешне бер мәл тын да алмыйча күзәтеп торды һәм бронекатерларга кыен килә башлагач, түзмәде:

— Корабларга якордан кузгалырга! Минем арттан полный ход! — дип команда бирде. — Туплар белән пулеметлар ут ачарга әзер торсыннар!

Кораблар, дәррәү кузгалып, дошманга каршы ташландылар.

Иң алдан үткен борыны белән елганы ерып «Ваня — коммунист» бара. Биек мачтасында кызыл флаг җилферди, моржасыннан бөркеп чыккан куе кара төтен су өстенә тарала, яр буендагы нaратларга эленеп кала. Корылган туплар алга, безнең бронекатерларны әзәрлекләп килүче дошман корабларына төзәлгән. Комендор Овсейчук, Палланго һәм пулеметчылар, приказ булу белән шундук дәррәү ут ачарга әзер торалар.

Маркин әледән-әле елганың уң ягына, куе нарат урманы белән капланган текә яр өстенә карый. Ул сигналчыларга да шуннан күз алмаска, игътибар белән күзәтеп барырга кушты...

Комиссарның шикләнүе юкка булмаган икән. Тиздән, Малиновка авылына житәрәк, сигналчылар яр өстендәге утын әрдәнәләре арасында

дошман тубы һәм солдатлар яшеренгән булуын күрделәр. Маркин моның серен шундук сизде. «Әһә, шунда посып калып, безгә арттан бәрмәкче буласызмы... Барып чыкмас, кабахәт җаннар!» Ул башка корабларга дошман отрядына каршы бара торырга сигнал бирде, ә үзе «Ваня — коммунист» белән сул як ярга таба борылды. Аннары алгы палубадагы тупчы Овсейчукка:

— Наратлыкка яшеренгән дошманга ат! — дип приказ бирде.

Яр өстендә гөрселдәп беренче снаряд шартлауга, утын агачлары һавага оча башлады, дошман тубы ата алмый калды, тончыкты бугай.

Күзәтүчеләр җентекләбрәк карагач, нарат агачлары арасында бер генә туп түгел, дошманның зур батареясы яшеренгәнлеген аңладылар. Эш болайга киткәч, комиссар машинист Михаил Куликка бер төркем матрослардан тиз генә десант җыярга кушты. Ләкин десант төшерергә туры килмәде. Тугайда су сай булганлыктан, кораблар ярга якын килә алмады, ә көймә белән маташырга мөмкин түгел: вакыт аз иде.

Хәзер бу мәкерле тозактан тизрәк котылырга кирәк. Маркин кире борылырга команда бирде. Ләкин «Ваня — коммунист» тугайдан чыгып китәргә өлгерә алмады, аклар бөтен батареялары белән тиз атышлы туптан ут яудыра башладылар. Беренче снаряд корабның морҗасын җимереп үтте, икенчесе — урта бер урында сул як бортны тишеп, корпус эченә бәреп керде һәм, машина бүлегендә шартлап, механизмнарны сафтан чыгарды. Ярылган трубадан ыжгырып чыккан кайнар пар бөтен корабка тарала башлады.

Ә өске палубада команда бар көченә каршылык күрсәтә иде. Пулеметчылар белән комендор Степан Овсейчук дошман батареясын тупка тота. Арткы палубадагы комендор Паллангоның сул кулы яраланган, тик ул бер генә секундка да туктамый. Пьяный Бор ягыннан килүче дошман корабларына өзлексез атып тора, аларны якын җибәрмәскә тырыша. Кызу бәрелеш арасында комиссарның мостиктан:

— Молодцы, комендорлар!.. Шул кирәк аларга!.. — дип кычкырган мактау сүзләре яңгырап үтте.

Якында гына урнашкан батареядан һәм кораблардан котырынып атып торган дошманга каршылык күрсәтү отыры кыенлаша барды. Снарядлар шартлаудан якында гына биек-биек булып ком катыш су баганалары күтәрелә дә бөтен корабны гөрселдәтеп палубага коела. Әле анда, әле монда кешеләр яраланып егыла. Арткы палубада бөтен группасы белән комендор Палланго һәлак булды, аның тубы нигезеннән куптарып ташланды. Лоцман Овчинников белән рулевой бер-бер артлы каты яраланып егылды, алар урынына штурвал янына Маркин үзе басты.

Шунда аңа ундүрт яшьлек юнга Чурков булыша башлады. Үсмер егетнең яңа бескозыркасы чак кына сул якка кыңгыр төшкән, калку маңгаена, сипкелле йөзенә бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан. Комиссарның аптыраулы карашын күреп, ул каушап калды, акланырга теләгәндәй:


— Штурвалда үзем торам, сез командовать итегез, — диде. — Сез шикләнмәгез, аңа гына көчем җитәрлек минем...

Маркин аны харап итәргә теләмичә:

— Югал моннан... Хәзер үк трюмга төшеп бикләнә, югыйсә башың бетәчәк, — дип куып төшермәкче булса да, юнга үзенекен итә бирде, сөекле комиссарын ялгыз гына калдырып төшеп китәргә теләмәде.

Кинәт штуртрос өзелеп, штурвал сафтан чыкты. Рубка һәм каюталар яна башлады. Рубка түбәсендәге ераклык үлчәгеч прибор авып төште һәм бер очы белән гудок бавына эләгеп, өзлексез гудок кычкыртырга тотынды.

Шул чак Минзәлә пристане ягыннан кызыл флотилиянең башка кораблары ашыгып килгәне күренде. Әнә командующий Раскольников



*И. Язынин линогравюралары.*

урнашкан миноносец «Прыткий» ерак та түгел инде, кыен хәлгә эләккән «Ваня — коммунист»ны буксирга алмакчы. Әмма ул өзлексез явып торган дошман уты аша үтеп, яраланган корабка ярдәм итә алмады. Үзе чак кына һәлак булмыйча, кире чигенде.

Дөрләп янган рубкада түзәр хәл калмагач, Маркин алгы палубага төшеп, комендор Овсейчукка булыша башлады. Аның артыннан Чурков та төшеп житте, аларга снаряд бирергә кереште. Шул мәлне дошман снаряды якында гына коточкыч шартлап, тагын бер тупның көпшәсен каерып ыргытты.

Рульсез һәм коралсыз диярлек калган, двигательләре сафтан чыккан яралы кораб агым уңаена яңы белән борыла торгач, уң як ярдагы сай жиргә килеп терәлде һәм бераз сулга кыйшайган хәлдә комга утырды. Каюталар дөрләп яна, атылган снаряд гильзалары белән тулган палубада ялкын телләре бии. Башка чара калмагач, комиссар әле һаман батырларча каршы торган командага:

— Барыгыз да суга сикерегез! Сул як ярга таба йөзегез, анда — безнекеләр коткарыр! — дип приказ бирде.

Инде чынлап та корабта калу бөтенләй мөмкин түгел иде. Кешеләр, жандай газиз кораблары белән соңгы кабат саубуллашып, бер-бер артлы боздай салкын суга сикерә башладылар. Юнга Чурков сикерергә икеләнеңбрәк тора иде, комиссар аны суга үзе төртеп төшерде. Палубадан үзләре ташлаган такталарга, снаряд ящикларына, балык мичкәләренә тотынгалап, бата-чума, аргы якка таба йөзгәндә, алар ут эчендә калган корабтан комиссарның: «Туганкайлар, сау булыгыз-з...» — дип кычкырган соңгы сүзләрен ишеттеләр.

Котырынган дошман судагы матрослар өстенә туплардан, пулеметлардан өзлексез ут яудыра, снарядлар шартлаудан су өсте туктаусыз кайнап тора иде. Бик күпләр, һәлак булып, елга төбенә китте. Исән калучылар, корабка каерылып караган минутларда, комиссарның әле һаман пулеметтан атканын һәм дошман корабын су өстендәге халык өстенә жибәрмичә тоткарлап торганын күрделәр. Менә аның уты да хәлсезләнде һәм тиздән бөтенләй басылды...

Хәзер инде дошман корабы якын ук килде дә, «Ваня — коммунист»ны пленга төшермәкче булып, буксирга алырга маташа башлады. Әмма шул минутта палубага тагын каяндыр комиссар Маркин килеп чыкты. Ул каты яраланган, көч-хәл белән аяк өстендә тора, дары корымыннан каралып беткән, уң кулына граната тоткан иде. Дошман корабы

«Ваня — коммунист»ны буксирга ала башлавын күргәч, ул кыенлык белән генә снаряд базы янына килде, авыр тимер капкачны ачып кулындагы гранатасын түбәнгә ташлады һәм шундук, әйләнә-тирәне гөрселдәтеп, корал склады шартлады, түбәннән янартаудай куәтле ут бәреп чыкты...

Куе кара төтен таралганда, палубада инде беркем дә юк иде. Бортлары, каюталары актарып ташланган «Ваня — коммунист» яртылаш суга баткан хәлдә, сул якка кыйшаеп калган һәм аның тирәсендә тынгысыз дулкыннар гына чайкала иде. Ә гудогы, кызыл дингезчеләрне дошманнан үч алырга чакыргандай, йөрәк өзгеч ачы тавыш белән әле һаман кычкырта иде...

* * *

Дошман җиңү шатлыгын озак бәйрәм итә алмады. Тиздән килеп житкән кызыл флотилия кораблары исән калганнарны судан җыеп алдылар, санитарлар яралыларга беренче ярдәмне күрсәтә башладылар. Дошманның бер корабы минага эләгеп шартлады һәм, корпусы урталай сынып, «Ваня — коммунист»тан ерак түгел генә су төбенә тончыкты. Дошманның башка кораблары да, кызыл флотилия басымына түзә алмыйча, чигенергә мәҗбүр булдылар.

Әмма Маркин табылмады. Сугыш авырлыкларын бергә кичергән, җиңү шатлыкларын уртаклашып, зур юллар үткән сугышчан дуслары өч тәүлек көтсәләр дә, ул кайтмады. Кайнар йөрәкле комиссар һәм гади матростан күтәрелгән командующий урынбасары Николай Григорьевич Маркинның һәлакәте бөтен флотилия өчен зур югалту булды, аны бөтен Кызыл Армия, бөтен ил авыр кичерде.

Флотилия командующие Раскольников шул уңай белән Ык тамагы рейдыннан Мәскәүгә В. И. Ленинга һәм Я. М. Свердловка җибәргән телеграммасында түбәндәгеләрне язды:

«Беренче октябрьда Пьяный Бор янында безнең флотилия дошман кораблары һәм яр буе батареялары белән каты сугышкан вакытта кораллы пароход «Ваня — коммунист» батты, аның белән бергә Идел хәрби флотилия командующие урынбасары, партиябезнең турылыклы улы, Иделдә һәм Камада яшь флотилиябезнең нигезен салучыларның берсе һәм энергияле төзүчесе иптәш Николай Григорьевич Маркин вакытсыз һәлак булды. Аның үлеме флотилия һәм бөтен Совет республикасы өчен бик авыр һәм чиксез югалту.

Батыр революционер истәлеге күңелләрдә мәңге сакланыр».

...Үз гомерендә күпне күргән борынгы Идел һәм Кама елгалары, бер генә минутка да туктамыйча, гел агып, үз юлларыннан гел баралар. Җир йөзендә тормыш дәвам итә, азатлык юлына баскан совет халкы якты киләчәккә атлый.

Кайнар йөрәкле комиссар Николай Григорьевич Маркин, революция каһарманнары белән бергә, совет кешеләре күңелендә кадерләп саклана, аның легендар исемен зур-зур пароходлар йөртә, тере образы җырларда буыннан-буынга күчеп яши һәм яңа тормыш төзүчеләр сафында бергә атлый...

— — □ — —

*Рамазан Һидиятуллин*

# ЯЛКЫНЛЫ ЕЛЛАРДА

*Рамазан ага хәзер пенсиядә. Шулай да тынгысыз ул, картлык көнемне ял итеп, тыныч кына үткәрим дими. «Социалистик Татарстан» газетасының штаттан тыш хәбәрчесе буларак, авылларга чыгып йөри, фельетоннар, репортажлар яза. «Советская Татария» һәм «Социалистик Татарстан» редакцияләре каршындагы җәмәгатьчелек кабул итү пункты советы члены буларак, төрле йомыш белән килгән хезмәт ияләренә эшлекле киңәшләр бирә, Вахитов исемендәге шәһәр китапханәсендә китапханә советы председателе буларак, күп санлы укучылар белән аралаша, Татарстан дәүләт музее каршындагы фәнни совет члены буларак, тарихи үткәнебезне өйрәнү буенча тикшеренүләр алып бара, революция һәм гражданнар сугышына катнашкан батыр якташларыбыз белән яшь буынны таныштыру эшенә актив катнаша, мәктәпләрдә, китапханәләрдә, авыл клубларында ветераннар белән очрашулар оештыра.*

*Рамазан ага үзе гражданнар сугышы ветераны. Октябрь революциясен авылда батрак булганы хәлендә каршылый. 55 нче дивизия сафында Колчак бандаларына каршы сугышларда катнаша. Аннары Икенче аерым Идел буе укчы татар бригадасы составында Төркстан фронтында акларга каршы сугыша, башта 68 нче бригада, соңыннан 15 нче Инза дивизиясе составында барон Врангель гаскәрләрен тар-мар итү сугышларында атлы разведчик була.*

*1923 елда, Казанда хәрби мәктәпне тәмамлаганнан соң, 24 нче Самара һәм Сембер тимер дивизиясенә рота командиры итеп җибәрелә.*

*Пенсиягә чыкканчы, Рамазан ага озак еллар дәвамында төрле партия, хуҗалык профсоюз эшләрендә эшли.*

## Ленин чакыруы белән

1920 елның җәе.

Без хезмәт иткән хәрби часть вакытлы рәвештә 2 нче революцион хезмәт армиясе составына кертелде. Сугышлар вакытында җимерелгән тимер юлларны тәзәтү өчен приказ алдык. Безне — барлыгы кырык кешене — продотряд итеп билгеләделәр.

1920 елның июль ае үтеп бара иде. «Петроград, Мәскәү, Иваново эшчеләре чирек кадак икмәк белән яшиләр, семьялары аннан да кимрәк ала», дигән хәбәр безнең йөрәкләргә хәнҗәр кадалгандай тәэсир итте.

Хезмәт һәм оборона Советы (СТО) кушуы һәм турыдан-туры иптәш Ленин чакыруы буенча, безнең продотряд икмәкле районнарга юнәлде. Идел аръягында — Камышин шәһәреннән 50—60 чакрымнар ераклыкта урнашкан авылларда — икмәк күп иде. Ләкин ул кулаклар кулында, нык яшерелгән. Кулак аны хөкүмәт амбарына илтүдән баш тарта. Икмәк алу өчен бер генә юл: яшергән җиреннән эзләп табарга һәм мәҗбүри рәвештә алырга кирәк.

В. И. Ленин азык-төлек диктатурасы турындагы хезмәтендә кулакларга каршы рәхимсез көрәш ачарга чакырды:

«Артык икмәге булган һәм аны станцияләргә, җыю һәм тапшыру урыннарына илтмәүче икмәк хуҗалары халык дошманнары дип игълан ителәләр һәм кимендә 10 елга төрмәгә ябылалар, аларның бөтен мөлкәтләре конфискацияләнә һәм алар үз общиналарыннан бөтенләйгә куылалар, дип тәгәл әйтергә».

*(Ленин, Әсәрләр, 27 том, 349 бит.)*

Саратовтан Астраханьга илтә торган тимер юл белән барып, Глининск разъездында поездлан төштек тә Иске Палтовка волостена бару өчен юлга чыктык.

Көн бик кызу иде. Юл буенда авыллар сирәк очрады. Ул якларда бездәге кебек хуш исле болыннар һәм урманнар юк. Ат тоягы астыннан тузгып күтәрелгән тузан борыннарга тула, күзләрне каплый. Атлар да, үзебез дә суга тәмам сусадык. Шулай азапланып райпродкомга килеп җиткәндә, кич тә булды. Квартираларга керергә уйламадык. Чөнки без әле бу тирәдәге хәлләр белән таныш түгел идек. Ул төнне, мылтыкларны кочаклап утырган килеш, райпродком ишек алдында гына йокладык. Отряд начальнигы элекке офицер, сугышларда күп катнашкан, бик сабыр, тыйнак кеше иде.

— Сак булыгыз, егетләр! Без монда кунакка килмәдек, кулак безне сагынып көтеп алмады, — дип кисәтеп куйды ул безне.

Киләсебезне алдан ук белеп торган райпродком председателе дә, күңелләргә шик салып:

— Безнең районда сезгә һәрвакыт мылтык кочаклап йокларга туры килер, — диде.

Кыска гына әйтелгән бу сүзләрдә коточкыч хәвефле хәлләр яшеренгән булуын без соңыннан үз җилкәбездә татыдык.

Соңыннан безгә Петроград эшчеләреннән төзелгән 6 кешелек тагын бер отряд килеп кушылды.

Корал ясаучы эшчеләргә икмәк, ә фронт өчен корал кирәк иде. Ул көннәрдә әле Украинада ак паннар хакимлек итә, Кырым ярымутравыннан чыгып, барон Врангель яшь Совет хөкүмәтенә каршы каты сугышлар алып бара иде. Илдә шундый хәлләр хөкем сөргәндә, икмәк өчен көрәш үзе бер фронт булып әверелде.

Саратов һәм Царицын губерналарына кергән далаларда, чиксез киң тигезлекләрдә бодай бик уңган булып, ул елны басуда — кая карама, шунда — салам эскертләре торды. Авыл активлары биргән сигналлар эзеннән барып, шул эскертләрнең асларын тикшереп йөрибез һәм, һәр көн саен, кулаклар яшергән икмәкне табып алабыз. Көннәрнең берендә, безнең отрядның бер төркем егетләре басуда эзләнеп йөргәндә, кинәт мылтык шартлый. Бераздан тагын бер ату тавышы яңгырап китә һәм бер кызылармеецның аты гөрселдәп җиргә ава. Пуля атның маңгаена тия. Кызылармеецлар каушап калмыйлар: якындагы салам өеменә төбәп бер тапкыр залп бирәләр. Шуннан соң аннан, кулларын күтәреп, ике бандит чыга. Аларны, коралсызландырып, Иске Палтовка волостена илтеп тапшыралар.

Бервакыт Иделдән 15 километрлар ераклыктагы Валуевка авылында кулакларның бик күп икмәк яшерүләре беленде. Идән астына, махсус салган мич юллыгына, тирес һәм салам астына яшерелгән меңнәрчә пот бодай табып, хөкүмәт амбарларына салдык. Валуевка авылында эшне бетереп, Яңа Палтовка авылына китәргә җыенганда, авылда фетнә күтәрелә башлады. Кулаклар үз кешеләрен котырткannар һәм халыкны авыл Советы каршындагы мәйданга җыйганнар. Кешеләр бер-берсе белән сөйләшмиләр, бар да караңгы чырайлы. Җыйналган кешеләрнең күбесе армиядә хезмәт итүчеләр яшендә булу бездә шик тудырды.

Отряд начальнигы иптәш Тимофеев бу серле хәлне бик тиз аңлап алды. Көчләрне саклап калу өчен бик тиз генә авылдан чыгып китәргә кирәк иде. Ул көчле тавыш белән команда бирде:

— Отряд! По коням!

Без, чаптырып, мәйданнан чыгып киттек. Фетнәчеләр безнең арттан куа башладылар. Берничә тапкыр атып карадылар, ләкин алар җәяү иде, атлы кызылармеецларга зыян итә алмадылар.

Петроград (путиловчылар) эшчеләренең вәкилләре, икмәк әзерләү эше белән, бирегә безгә кадәр дә килгәннәр. Эшчеләрнең бөтен семьяларына чирек кадак икмәк белән тукланып яшәүләре һәм шулай булса да, фронт өчен корал җитештерүләре турында авыл халкына сөйләгәннәр. Ләкин кулаклар халыкны кирегә котыртканнар.

Дезертирлар һәм бандитлар, кулаклар белән бергә, эшчеләрне ерткычларча кыйнаганнар, үтергәннәр, суга батырганнар.

Райпродком председателенең безне каршы алганда әйткән сүзләре артыгы белән дөрескә чыкты: без мунча кергән вакытыбызда да ишек төбендә берберебезне мылтык тотып саклый идек. Кайвакытта үзең торган квартир хуҗасының кем икәнлеген белү дә кыен булды.



*Рамазан Һидиятуллин гражданнар сугышы чорында.*

Бер авылда кич кунарга квартирага кергәч, хуҗа хатыны безгә үзенең ирен Кызыл Армиядә дип әйтте. Ләкин төн уртасында бүлмәдә ир кеше тавышы ишетелде. Сүз безне — өч кызылармеецны үтерү турында барганын белгәч, тревога белән отрядны аякка бастырдык. Бүлмәдәге кеше хуҗа хатынның ире — бандит булып чыкты...

Без Яңа Палтовка авылына җиткәндә, сәгать төнге 12 ләр булгандыр, отряд начальнигы яңа алынган приказ турында белдерде. Приказда болай диелгән иде: «Продотряд өстенә дезертирлар белән көрәшү бурычы да йөкләнә».

Әйе, дезертирлар белән көрәшү — ул фактта илгә хыянәт итүчеләр белән көрәшү иде. Ул вакытта кулаклар совет кешеләрен дезертирлар кулы белән үтертәләр иде. Бу төнне без өйләргә таралмыйча, авыл читендә кундык. Төн тыныч үтте дияргә була. Тик кайбер усал этләр генә, үз хуҗаларының тынычлыкларын бозып, шомлы тавыш белән улап өрә башладылар. Авыл йокыдан иртәнге сәгать дүртләрдә уянды. Кулларына таяк-чыбык тоткан хатын-кызлар, сыер эзләгән булып, авылдан чыгып китәли башладылар. Аларның үз-үзен тотулары бездә шик уятты. Тикшереп карасак, хатын-кыз дигәнебез киемен алыштырган ирләр булып чыкты. Ул иртәне без унбер дезертирны тотып, шуларның икесеннән көбәге киселгән мылтык һәм наган табып алдык, үзләрен Иске Палтовка волостена илтеп тапшырдык.

Кулакларның һәм дезертирларның төп таянычлары — Новоузенск өязендә берничә мең кешелек атлы банда оештырып, гарнизон складларын талаган, совет кешеләрен үтереп йөргән элеккеге поручик сул эсер Сапожков иде. Без икмәк әзерләгән районнан 100 километр чамасы гына ераклыкта Сапожков бандасының хәрәкәт итүе бу тирәдәге Совет дошманнарын канатландыра һәм алар бик зур өмет белән банда килүен көтәләр иде...

Менә шундый авыр, дәһшәтле көннәрдә Татарстан егетләреннән торган 40 кешелек продотряд ил ышанычын, бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин ышанычын аклады. Меңнәрчә пот икмәк әзерләп Мәскәү, Петроград һәм Иваново эшчеләренә озатты.

# Герой кабере өстендә кызыл чәчәкләр

1920 елның көзе бик озак килде, көннәр җәй уртасы кебек кызу иде. Без төньяк Таврияда Врангель армиясенә каршы сугышлар алып барабыз. Кызылармеецлар су эчәргә тилмереп: «Их, үз авылыбның чишмәсеннән бер генә тапкыр рәхәтләнеп ятып су эчәсе иде», — дип, туган якларын искә төшерәләр. Бронепоезд килеп тукта-

са, безнең өчен бу бик зур шатлык була. Паровоз астындагы су багыннан флягаларга агызып алып, саз исе килеп торган болганчык суны да йотлыгып эчәбез.

Шундый кызу көннәрнең берендә мин разведкадан кайтып килә идем. Акимовка авылы кырында ялгыз кабер өстендәге тактага күзем төште. Гарәп хәрефләре белән: «Рота командиры иптәш Әхмәди Үтәшев», дип язылган иде анда. Таныш фамилия булмагач, озак тұктап тормыйча, штабка кайтырга ашыктым.

Әйе, сугыш үткән җирләрдә андый каберләр күп очрый торган иде. Туфрак астында кем ятканын белмисең бит, башыңны түбән иеп, үтәсең дә китәсең. Ләкин миңа уйламаганда гына ул фамилия турында кабат ишетергә туры килде.

Врангель армиясен Кырымга таба куганда, безнең бригада Акимовка авылында торды. Квартир хуҗабыз болгар карты иде. Ничектер, шулай бервакыт, татарлар турында сүз чыккач, башка вакытта бик аз сүзле бу карт үзе сөйли башлады.

— Моннан ике ай элек бездә татарлар торды, — диде ул. — Командирлары бик яхшы кеше, үзе Казанныкы иде. Гаҗәеп батыр, куркуны белми торган халык икән ул татарлар. Үзләре күп тә түгелләр иде. Бервакыт шулай Григорьевка ягыннан, кара болыт кебек булып, акларның атлы гаскәре килеп чыкты. Бик каты сугыш башланып китте. Кырым ягыннан килгән аэропланнар авыл өстендә очып йөрделәр. Аклар, бик күп булсалар да, әллә никадәр кешеләрен һәм атларын калдырып, кире чигенделәр. Аннан соң да якын-тирәдә сугышлар күп булды: туп, пулемет, мылтык тавышлары төннәр буе ишетелеп тора иде...

Мин, авыл читендәге ялгыз каберне искә төшереп, карттан:

— Үзегездә торган командирның фамилиясен хәтерләмисеңме? — дип сорадым.

— Әйе, беләм. Үтәшев Алексей иде ул, — диде хуҗа.

— Ул командирның язмышын белмисезме? — дип сорашуымны дәвам иттем.

Картның больницада эшли торган 22—23 яшьләрендәге кызы бар иде. Ул Үтәшев һәм башка командирларның, югарыдан килгән приказ нигезендә, Мелитополь шәһәренә таба чигенүләрен әйтте. Мин бераз уйга калып тордым булса кирәк, сизгер йөрәкле кыз:

— Әллә сез аны беләсезме?! — дип, зур коңгырт күзләрен төбәп, миңа карады.

Мин якында гына Үтәшев фамилияле командирның каберен күргәнлегемне әйттем. Күңелсез хәбәр бу өч кешедән торган болгар семьясына әйтеп бетергесез кайгы китерде. Кыз сулкылдап еларга кереште, карт белән карчыкның да күзләрендә яшьләр күренде. Аларның ни өчен бу татар командирын җылы хис белән хөрмәт итүләре минем өчен ачылмаган сер булып калды. Артык сорашырга базмадым.

Берничә көннән соң миңа Үтәшев кабере яныннан кабат үтәргә туры килде. Кабер өстенә кызыл чәчәкләр бәйләме куелган иде. Күңелем белән чәчәк салучыга рәхмәт әйтеп, кабер белән актык мәртәбә саубуллаштым да Кырымга юл тоткан иптәшләремә кушылдым. Бүтән бу авылга килергә туры килмәде...

Аннан соң күп еллар үтте. Картайгач, хәтер дә кими төште. Мин ул ялгыз кабер турында оныткан да идем инде.

Гражданнар сугышыннан соң 46 ел узгач, шул тарихи елларны искә төшереп, Өлкә партия архивында утырырга туры килде. Шунда, очраклы рәвештә, 1920 елны басылган «Эшче» газетасының 36 санында күземә Үтәшев фамилиясе чалынды.

«Кырымга татар кызыл яулары китте. Кичә, 21 апрель көнне, аерым Идел буе татар бригадасының запастагы батальоны Кырымга иптәш Үтәшев командалыгында мәркәз хәрби һәйәтенең аерым ротасын озатты», — диелгән иде ул газетада.

Әйе, минем өчен көтелмәгән хәбәр иде бу. Аны уку белән Акимовка белән Мелитополь арасында бормаланып киткән тимер юл буендагы ялгыз каберне, кызыл чәчәкләр бәйләмен күз алдыма китердем... Эзләнә торгач, «Кызыл Армия» газетасында, шул ук 1920 елның 332 санында басылган бер хәбәрне таптым. Анда кызыл командир Үтәшевның сугышта һәлак булуы һәм Мелитополь өязе Акимовка янында күмелүе турында хәбәр ителгән иде. Ярты гасырга якын вакыт үтеп киткәч, мин күргән ялгыз кабердә яткан геройның тарихи көрәш юлларының бер өзеге генә булса да ачыкланды. Бу каһарман командир үзенең ротасы белән украиналы кардәшләребезгә ярдәмгә барган, яшь Совет власте өчен гомерен биргән татар халкы вәкилләренең берсе булып чыкты.

Дошман мәкерле иде. Безнең илебезнең төп көчләре ак поляклар фронтында булуыннан файдаланып, барон Врангель, танк, бронемашина, аэропланнар һәм авыр туплар белән коралланган йөз меңнән артык армиясен Кырымнан чыгарып, көньяк Украина даласы буйлап, 13 нче армиягә каршы һөҗүмгә күчте. Иптәш Убаревич командалыгындагы 13 нче армия үзеннән дүрт мәртәбә артык санлы дошманга каршы тору өчен кеше көченнән килердәйләрнең барын да эшләде. Көчләр тигез булмау сәбәпле, күп корбаннар биреп, Синильниково станциясенә кадәр чигенергә мәҗбүр булдык. Безнең якташыбыз кызыл командир Үтәшев әнә шул канлы зур сугышларда каһарманнарча сугышып һәлак булган иде.

## Ике очрашу

Шул ук 1920 елның октябре.

15 нче Инза дивизиясе Каховкадан алып Сиваш ярына кадәр булган җирне бик авыр шартларда сугышып үтте. Дошман көчле иде. Нык коралланган, күп өлеше офицерлардан торган дивизияләргә каршы сугышларда җиңү белән рухланган кызылармеецлар, үлем белән хисаплашмый, алга ыргылдылар. Инза дивизиясендә, бигрәк тә ике полкта, Казаннан килгән яңа көчләр бар иде. Безнең якташларыбыз да инзалылар сафында көчләрен аямыйча арсландай сугыштылар. Кызыл Армия, бөтен фронт буйлап, Геническ шәһәреннән алып Кара диңгезгә кадәр булган җирне врангельчеләрдән чистартып, ноябрьның өчесендә Кырым капкасына килеп җитте.

Кырымга коры җирдән бәреп керү күп югалтулар таләп итә: Перекоп бугазының киңлеге унбер километр, Чоңгар бугазы — өч километр һәм Арбат стрелкасы бер километр чамасы. Ләкин бу соңгы икесе дошманның Азов флотилиясе тарафыннан өзлексез утка тотылып тора. Димәк, йөз километр фронтның 15 километры гына коры җир булып, калган 85 километры су белән бүленгән иде.

Командарм М. В. Фрунзе, коры җирдән Кырымга керү мөмкинлеге бик аз булуын искә алып, дивизияләрне Перекоп ныгытмасы артына Сиваш аша чыгару планын төзеде, һәм үзе, урынга килеп, шул тарихи операция белән җитәкчелек итте.

Безнең 15 нче дивизия штабы Сиваш яры буендагы Страгановка авылында иде. Бервакыт шулай ачык һавада урнашкан роталар кинәт җанланды, һәр кызылармеец, дала ягына таба борылып, еракта күренгән җиңел автомашинаны күзәтә башлады. Машина бик тиз килеп җитте.

Командарм М. В. Фрунзе һәм главком С. С. Каменев автомобильдән чыктылар. Кызылармеецлар белән бик җылы исәнләшкәннән соң, алар дивизия штабы урнашкан авылга керделәр. М. В. Фрунзены минем беренче тапкыр күрүем иде бу. Шул ук көнне кичкә таба алар дивизия начальникларыннан И. И. Раудмец, В. К. Блюхер һ. б. лар белән Сиваш яры буена килделәр һәм кичү урынын карап йөрделәр. Баш өсләреннән бертуктаусыз сызгырып үтеп торган снарядларга карата булса кирәк: «Дошман ягы сак тора», — диде командарм. Кулына бинокль алып, аргы якны карамакчы булды. Ләкин су өстендәге томан аша дошман ягы күренми иде.

Врангельчеләр Кырымга кереп бикләнгән, безгә — атлы разведчикларга — эш булмаганлыктан, дивизияләр, бригадалар, һәм кайвакытта 6 нчы армия штабына ук приказлар йөртә башладык.

7 ноябрь көнне, яшь Совет иле үзенең өч еллыгын бәйрәм иткәндә, Кызыл Армия халкыбыз хәтереннән мәңге җуелмаслык каһарманлык күрсәтергә әзер тора иде.

Без һәрберебез 6—7 километр киңлегендәге Сивашны кичеп чыгарга, дошманның Марков, Дроздов һәм Корнилов дивизияләрен тар-мар итәргә омтыла идек. Шул ук көнне, караңгылыктан һәм томаннан файдаланып, 15 нче дивизиянең 45 нче бригадасы һәм кавалерия полкы, коточкыч упкынлы, Черек диңгез дип йөртелә торган Сивашка кереп, күздән югалдылар. Дошман прожекторлары берөзлексез Сиваш өстен һәм яр буен капшап тордылар. Чыгып җитәргә берникадәр ара калгач, врангельчеләр давыллы ут ачтылар. Югалтулар булды булуын, әмма дошман кулындагы яр буен штурмлаучылар, бернәрсә белән дә хисаплашмыйча, алга үрмәләделәр. Кулларына ике кило чамасы авырлыктагы Новицк граматаларын тотып, бер группа кызыл-

армеецлар чәнечкеле тимер чыбык рәтләренә таба шудылар һәм чыбыкларны шартлатып өзеп, роталарга керер өчен юл ачтылар.

7 ноябрьдән 8 енә каршы төнне 15 нче дивизия, Сивашны кичеп чыгып, яр буенда дошманга каршы һөҗүм башлады. Элемтәчеләр дә, сугышчылардан калышмыйча, Сиваш аша телефон чыбыгы сузып, дивизия белән М. В. Фрунзе штабы арасында элемтә урнаштырдылар. Кызганычка каршы, кыр телефоны ике сәгать чамасы гына эшләде. Фронт белән командарм арасында элемтә өзелде. Командарм өчен иң киеренке минутларда телефонсыз калу фронтның язмышын үз ихтыярына кую дигән сүз иде. Командарм — ул фронтның йөрәге, ә телефон чыбыклары кан тамырлары дисәк ялгыш булмас.

Телефонның эшләүдән туктау сәбәбен элемтәчеләр бик тиз аңлап, тиешле чара күрделәр. Сивашның тозлы суы телефон чыбыгын ашаган һәм күгәрткән булып чыкты. Шуннан соң элемтәчеләр, үз командаларындагы кызылармеецларны Сиваш аша тезеп чыктылар; алар, телефон чыбыкларын икешәр сәгать буена кулларында тотып торып, командармга фронт белән җитәкчелек итәргә мөмкинлек тудырдылар. Ул арада фронттан командармга хәбәр килде: данлы начдив В. К. Блюхерның 51 нче дивизиясе Төрек валын алган! Шуннан соң озак та үтмәде, Кырымга атлы гаскәр керту мөмкинлеге ачылды. Кырым тигезлегендә бөтен фронт буйлап Симферопольгә таба һөҗүм башланды. Антанта инженерларының ел буена корган тимер-бетон ныгытмалары дошманга файда бирмәде. Барон Врангель, армиясен ташлап, корабльгә утырып качты.

Кырымда Совет власте урнашкач, кызылармеецларның күбесе өйләренә, сугыш нәтиҗәсендә җимерелгән хуҗалыкны төзекләндерергә киттеләр. Без, бер группа иптәшләр, хәрби мәктәпләрдә укырга теләдек. Уналтынчы җәяүле командирлар мәктәбенә Казанга укырга кайттык. Ләкин Совет власте дошманнары анда да тынычлап укырга ирек бирмәделәр. 1921 елда безне Төмән һәм Тоболь тирәсендәге фетнәне бастыру өчен җибәрделәр. 1922 елның эссе җәендә Төркмәнстанга барып, басмачыларга каршы көрәштек, октябрь аенда гына кайтып укый башладык. Әле хәзер дә хәтеремдә, актык курста укыганда тактика укытучысы патша генералы Грузинский (үзе әйтүенә караганда патша адъютанты), курсантлар белән бәхәскә кереп, М. В. Фрунзеның Сивашны кичеп чыгуын дөрес тактика түгел дип бәяләде. Без аңа каршы отпор бирдек. Кырым өчен барган сугышларда М. В. Фрунзеның бөек Ленин күрсәткән тактика белән җиңүгә ирешкәнен без белә идек.

«...Исегездә тотыгыз, ничек кенә булмасын, дошманның үкчәсенә басып Кырымга керергә кирәк. Җентекләп хәзерләнегез, Кырымны алу өчен су ерып чыга торган урыннарның барысы да өйрәнелгәнме — тикшерегез»[1].

В. И. Ленин зур һөҗүм башланганга кадәр үк, 1920 елның 16 октябрендә бу телеграмманы М. В. Фрунзе исеменә бирә.

Әйе, Кызыл Армиянең акларга тын алырга да бирмичә, үкчәләренә басып барып, Кырымга керүе карт генерал Грузинскийга ошамаган иде...

Кызыл командир булып чыккач, миңа Винница шәһәрендә 24 нче Самара-Сембер тимер дивизиясендә хезмәт итәргә туры килде. Гражданнар сугышы чорында бу дивизия легендар начдив Гай командалыгында В. И. Ленинның туган шәһәре Семберне аклардан азат иткән иде.

Бервакыт шулай полк буенча дежур торганда: «Винницага Фрунзе килә», дигән хәбәрне әйттеләр. Ул көнне безнең полк ату күнекмәләре ясарга басуга киткән иде. Башта бераз каушап калдым. Аннары тиз генә полкка хәбәр иттем дә казармаларны йөреп чыктым.

М. В. Фрунзе безнең полкка төшке аш вакытында килде. Аның машинасы полк штабы алдына килеп туктаганда, роталар урам яңгыратып җырлап кайтып киләләр иде. М. В. Фрунзе штабка килеп керү белән, мин аңа рапорт бирдем. Үземнең фамилиямне әйткәч, Михаил Васильевич: «Сәлам!» дип, үзе кулын сузды. Бу сөекле командармны минем икенче тапкыр күрүем булды...

---

[1] Әсәрләр, 35 том. Дүртенче басмадан тәрҗемә. 425 бит.

— — □ — —

*С. Данильченко,*

Чапаев дивизиясенең элеккеге
полк командиры, хәзер гвардия
генерал-майоры

# ЧАПАЕВ КАЗАНДА

Революциягә кадәрге Россиядә частьларының, командаларның составы буенча да, саны буенча да Казан хәрби округы тылдагы иң зур округ иде. 1917 елның алты-җиде ае эчендә генә дә округтагы запас частьлардан фронтка 1200 марш роталары (300 меңнән артык кеше) җибәрелде.

1917 елда фронттан яраланып кайтканнан соң, гражданнар сугышының булачак легендар герое Василий Иванович Чапаев Саратов госпиталендә дәвалана һәм савыккач, Казан округына кергән Николаевск (хәзер Пугачев шәһәре) шәһәренә урнашкан 138 полкка күчерелә. Ул анда рота фельдфебеле булып хезмәт итә.

1917 елның көзендә, хәтерем ялгышмаса, сентябрь аенда, Николаевск гарнизоны солдат депутатлары Советы карары нигезендә, Чапаевны Казанга икенче округ съездына делегат итеп җибәрәләр. Казанга килгәч, Василий Иванович үзенең туганы Михаил Чапаев квартирасында яши. Ә Михаилның хатыны, Агафья Ивановна, Татарстаннан, хәзерге Югары Ослан районының Клянчино авылыннан була. Алар ул вакытта үзләренең балалары белән Бишбалтада Зур урамда торганнар.

Михаилның квартирасы кечкенә булганга, Василий Иванович бик күп көннәрне Агафья Ивановнаның туганнарына кунарга йөри. Ә алар Кувалдина урамында (хәзерге Заречная урамы) торганнар.

Миңа да Саратов губернасының Балашов шәһәре гарнизоны солдат депутатлары Советы делегаты буларак, икенче Казан округы съездына катнашырга туры килде. Мин шунда Василий Иванович Чапаев белән беренче тапкыр очраштым. Аннан соң инде ярты гасырдан артык вакыт үтеп китте, ләкин Казанда булып үткән бу съезд, Чапаевның андагы чыгышы минем һаман да хәтеремдә яхшы саклана.

Ул көннәрдә Казанда һавалар бик начар иде, көннәр гел җилле булды, әле яңгыр, әле юеш кар яуды. Әмма шәһәр кешеләренең һәм Казан гарнизоны солдатларының иске тормышка каршы давыллы көрәше тагы да көчлерәк иде. Вакытлы хөкүмәткә каршы көрәш, Казан большевиклары җитәкчелегендә, көннән-көн кискенрәк төс ала бара иде.

Мин Татарстанда Октябрь революциясенең ничек итеп тантана итүенә киңрәк тукталырга теләмим — бу турыда революция ветераннары да, тарихчылар да күп яздылар инде һәм язачаклар да — бары тик, ул вакыйгаларга катнашучы буларак, шуны әйтәсе килә: Казанда Совет властен урнаштыру өчен көрәш бик кискен булды. Корaллы бәрелешләр биредә Октябрь революциясенә кадәр үк башланды. Питердан һәм Мәскәүдән килгән хәбәрләр шәһәрдә халык властен урнаштыру өчен көрәшкә дәрт бирде. 1917 елның 25 октябренда Казан хәрби революцион комитеты җитәкчелегендә Кызыл Гвардия отрядлары, татар хезмәт ияләреннән оешкан отрядлар, Казан гарнизонының большевиклар яклы частьлары Вакытлы хөкүмәт яклы юнкерларга каршы каты сугышлар алып бардылар.

26 октябрь төнендә контрреволюцион көчләрнең каршылыгы сындырылган иде инде. Ә кичен эшче, солдат, крестьян депутатлары Советының фабрика-завод һәм хәрби комитетлары вәкилләре белән берләштерелгән утырышы үткәрелде. Бу утырышта Совет властеның беренче җитәкче органы — Вакытлы революцион комитет («Казан революцион штабы») оештырылды.

Хәрби округ съездына кадәр округтагы гаскәрләрнең командующие итеп прапорщик Ершов, ә Казан гарнизоны начальнигы итеп штабс-капитан Масальский сайланган иде.

Менә шул вакыйгалардан соң инде икенче Казан хәрби округ съезды булып үтте. Съезд Сулъяк Болак урамында элеккеге Икенче гимназия бинасында үткәрелде. Ул вакытта бу бина «Солдат Йорты» дип йөртелә иде.

Бу съездга округтагы ярты миллионга якын гаскәрдән ике йөздән артык делегат килгән иде. Алар арасында большевиклар да, эсерлар да, меньшевиклар да бар иде. Залның сул ягындагы скамьяларга большевиклар, уң ягындагыларга калганнары урнаштылар.

Съездда большевиклар белән эсерлар һәм меньшевиклар арасында бик кызу дискуссияләр булды. Эсерлар һәм меньшевиклар солдат массаларын Совет властена каршы котыртырга маташтылар. Аларны элеккеге офицерлардан торган, составында башлыча уң эсер һәм меньшевиклар булган Хәрби округ комитеты да яклады. Алар Николай Ершовны һәм большевиклар яклы делегатларны «властьтан явыз файдалану»да гаепләделәр һәм гаскәрләр белән командалык итү өчен үз кандидатларын тәкъдим иттеләр.

Съезд яңа Хәрби округ комитетын сайларга, округ белән идарә итү өчен яңа органнар оештырырга, округ гаскәрләре белән шәхси житәкчелекне биш кешедән торган комиссарлар Советы белән алыштырырга тиеш иде. Шулай ук округтагы һәм Казандагы хәрби гарнизоннар Совет властеның ныклы нигезе булсын өчен армиядә демократизация үткәрү дә аның көн тәртибендә иде. Аннары иске армия частьларын планлы рәвештә демобилизацияләү мәсьәләләрен дә ул хәл итәргә тиеш иде. Чөнки ул вакытта фронтта да, тылда да солдат массалары стихияле төстә авылларга, туган семьялары янына омтылалар иде.

Делегатлар берсе артыннан икенчесе чыгып сөйли тордылар. Берләре — андыйлар купчелек иде — яңа реформаларны якладылар, ә бүтәннәр большевикларны гаепләделәр — алар бу реформага каршы сөйләделәр.

Ниһаять, съезд председателе большевик Алексей Евлампиев:

— Саратов губернасының Николаевск гарнизоны фельдфебеле Василий Чапаевка сүз бирелә,— дип игълан итте.

Залдагы сул якка куелган скамьяларның берсеннән бер хәрби кеше трибунага узды.

— Кыскарак сөйләвегезне үтенәм,— диде председатель. Чөнки элеккеге ораторлар бик озак буш сүз сөйләп күп вакытны алганнар иде.— Күбрәк эш турында әйтегез!..

— Ә мин монда комнан бау ишәргә менмәдем,— дип башлады сүзен Чапаев.— Ни турында сөйләрмен — анысын ишетерсез. Мин сүз боткасына күнекмәгән.

Зал тынып калды. Безнең алда уртачадан тәбәнәгрәк буйлы, ябык гәүдәле, нечкә иреннәре өстендә кечкенә генә мыеклар тырпаеп торган, чиста кырынган, кыю карашлы кеше басып тора иде. Күкрәге Георгий тәреләре, медальләр белән тулы һәм бер ягына кызыл лентадан зур бант тегелгән иде.

Чапаев уң якта утыручыларга төбәп сөйләргә кереште.

— Мин фронтта 326 Белгорай полкында хезмәт иттем,— диде ул.— Ә хәзер 138 запас полктан бирегә делегат булып килдем. Ничә көн инде ораторларның речьләрен тыңлыйм. Нинди мәгънә бар аларда? Безне, сул якта утыручыларны, анархиядә, башбаштаклыкта гаепләгән булалар, үзләре бик грамотный да сөйлиләр. Әгәр чынлап торып алар сүзенә колак салсаң, шул аңлашыла: бу кешеләр искегә кайтмакчылар, яңадан иске тәртипләрне кертмәкчеләр бит. Алар хәтта сугышны дәвам иттерүне дә яклыйлар...

Председатель, башын селкеп, Чапаев сүзләрен хуплап торды. Ләкин уң як скамьяларда утыручылар шау-шу куптардылар, аңа сүзен дәвам иттерергә ирек бирмәскә тырыштылар.

Чапаев сүзен дәвам итте:

— Андый сүзләрне сөйләргә кем вәкаләт бирде сезгә? — диде ул, тавышын күтәреп.— Сезне вәкил итеп җибәргән солдатлар моны теләми. Солдат мандатлары астына яшеренеп, сез аларны алдыйсыз!

Тагын уң якта утыручылар шау-шу куптардылар, берсе берсеннән уздырып, кычкырына, сызгырына башладылар. Ләкин Василий Иванович трибуна янында китмәде, тавышын тагын да күтәреп сөйләвендә булды:

— Әһә, минем сүзләр сезгә ошамыймы? Димәк, мәче кем чоланында, кем маен ашаганын яхшы беләү. Мин шундый карарны яклыйм: округның комиссарлар Советын сайларга кирәк, һәм ул иптәшләр, шундук эшкә башлап, солдатларны демобилизациялауне тәртипкә китерсеннәр. Ә анда халыкка чын күңелдән бирелгән командирлар сайланырга тиеш, — диде дә ул, кызу-кызу атлап, трибунадан төште һәм үз урынына барып утырды. Аның чыгышыннан соң күпчелек делегатлар озаклап кул чаптылар.

Чапаевның Белгорай полкында хезмәт итүе мине кызыксындырды. Мин 1917 елның язында аларның күршесендә Брянск полкында сугышкан идем. Тәнәфес вакытында мин аның янына килдем. Чыгышы вакытындагы дулкынлануы бетмәгән иде әле. Без, съезд турындагы тәэсирләрне уртаклашып, сөйләшеп киттек. Аннары сүз фронт тормышы вакыйгаларына күчте. Бер үк сугышларга катнашкан булып чыктык. Чапаев Георгий тәреләрен һәм медальләрне ни өчен алуы турында сөйләп китте. Беренче карашка ук аның батыр кеше булуы күренеп тора иде.

— Миллионлаган солдатлар кебек үк, патша өчен, алпавытлар өчен сугышырга туры килсә дә, куркаклык күрсәтмәдем, — диде ул. — Табигатем белән тәвәккәл кеше инде мин. Революция булганчы хаклыкның нәрсәдә икәнен бик аңлап та житкермәдем. Безнең рота солдатлары мине яраталар иде, мин алар арасында үз кеше булдым. Җырларга ярата идем. Холкымны яхшы белгән югары начальство күрәалмый иде үземне. Хәтта бер мәртәбә хәрби кыр судына эләгә яздым. Рота командиры поручик Прихожаев кына коткарып калды. Яхшы кеше иде, әлеккеге укытучы. Георгий тәреләре дә ярдәм итте. Бу болай булды. Дивизия штабыннан ротага югары чиндагы бер офицер килде. Ул бер солдатка кул күтәрде. Ә мин аны якладым, әлеге офицерны атасы-анасы белән сүктем. Ул команда буенча рапорт бирде, мине кыр судында хөкем итәргә таләп итте. Хөкем итсәләр, я атарлар, я каторга хезмәтенә җибәргән булырлар иде...

Съезд барышында мин Чапаевның берничә мәртәбә күренекле Казан большевигы Николай Ершов белән сөйләшеп торганын күрдем. Н. Ершов бу вакытта Казан Советының хәрби секциясен җитәкли һәм шул ук вакытта Казан Хәрби округының беренче революцион командующие иде.

Чапаевның Николай Ершов һәм башка Казан большевиклары белән аралашуы, минем уемча, аңа революцион вакыйгаларга тирәнтенрәк төшенергә ярдәм иткәндер, Идел аръягында тиздән башланып киткән гражданнар сугышындагы эшчәнлегенә зур йогынты ясагандыр.

Съезд барган көннәрдә Василий Иванович, башка делегатлар белән бергә, контрреволюцион элементларның Казан кешеләре һәм гарнизон солдатлары арасында провокацион чыгышларын тар-мар итүгә дә катнашты. Моның өчен делегатлардан берничә дружина оештырылды. Һәм алар шәһәрдә революцион тәртип урнаштыруда зур роль уйнадылар.

Василий Иванович бу турыда 1918 елда эшче-крестьян Кызыл Армиясе Академиясенә укырга кергәндә тутырган анкетасында да әйтә. «Сезнең съезд, конференция делегаты булганыгыз бармы? Булса, кайчан һәм кайда?» дигән сорауга ул болай дип җавап яза: «Николаевск шәһәреннән делегат булып хәрби-Казан съездына катнаштым». Ә «Октябрь коралды күтәрелешендә катнаштыгызмы һәм нидән гыйбарәт?» дигән сорауга кыска гына итеп: «Казанда. Җиңү белән тәмамланды», — дип язып куя[1].

Ул көннәрдә Казанда гына түгел, илебезнең бүтән районнарында — Идел буенда, Уралда, Донда, Себердә һ. б. якларда да хәл катлаулы иде. Оренбургта атаман Дутов, Донда генерал Каледин бандалары Совет властена каршы күтәрелделәр.

Съезд тәмамланырдан берничә көн элек (1917 елның 6 декабрендә) Чапаевны бик ашыгыч рәвештә Николаевскига чакыртып алдылар.

— Монда күп кенә яхшы кешеләр белән очраштым, — диде ул миңа. — Кызганыч, иртәгә Николаевскига китәм, ашыгыч телеграмма белән чакыралар. Ни эшлисең: революция шуны таләп итә...

---

[1] СССР кораллы көчләренең Үзәк музее. № 15/36. В. И. Чапаевның шәхси эше.

Чапаев белән Казанда очрашу соңгысы булмады. Бу очрашудан соң ярты ел үткәч, Уралдагы ак казакларга һәм ак чехлар корпусына каршы сугышларда күп мәртәбәләр очраштык без. 1918 елның сентябреннән Чапаев дивизиясендә мин полк белән командалык иттем. Мин командалык иткән полк составында милли отрядлар да бар иде. Имаметдин Хубиев (хәзер Саратов өлкәсенең Пугачев шәһәрендә яши) һәм Заһидулла Краснов (хәзер Азнакайда тора) җитәкчелек иткән татар роталары бөтен дивизиягә данлыклы булды.

Волчанский хуторы янындагы сугышлар яхшы хәтердә. Дошман безгә өзлексез һөҗүм итеп торды. Хәлнең иң кискен моментында Чапаев миңа:

— Бу участокка Хубиев белән Краснов роталарын җибәр. Алар усал сугышалар, үлсәләр үләләр — ләкин дошманны үткәрмиләр,— дип боерык бирде.

Чыннан да, татарлар сынатмадылар...

Тагын икенче бер вакыйга.

Безнең полк урнашкан урынга төнлә Чапаев килеп төшә. Хубиев ротасыннан сакта торган часовой: «Кем килә»,— дип кычкыра. «Чапаев»,— дип җавап бирәләр аңа. «Пропускың бармы?» «Оныттыңмыни Чапаевны,— ди начдив — мин чыннан да Чапаев». «Пропускысыз беркемне дә җибәрергә кушмадылар. Хәзер төн, якында гына казаклар»,— ди аңа каршы каравыл начальнигы Низам Тәминов (хәзер Пугачев шәһәрендә яши) һәм часовойларга Чапаев белән аның ординарецын полк штабына илтергә куша.

— Менә, ичмасам, егетләр,— дип соклана Чапаев, полк штабына кергәч. — Гел шулай эшләргә кирәк!

— Ә син мине белдеңме? — дип сорый соңыннан начдив, Тәминовны чакырып.

— Эш белүдә, белмәүдә түгел,— ди каравыл начальнигы, русчаны ватып-сындырып.— Төнлә һәркем Чапай. Ә казаклар хәйләкәр...

Шул ук көнне полкка Чапаев кул куйган приказ килеп җитте. Анда Хубиев ротасы сугышчыларына фронтта батыр һәм үрнәк хезмәт итүләре өчен рәхмәт белдерелгән иде...

Мәскәү.

——□——



*Без барасы юллар озын әле,*
*Без җитәсе кырлар бик ерак;*
*Барган саен юллар күңеллерәк,*
*Барган саен еллар яктырак.*

*Х. ТУФАН.*

# ҮТКӘН ЕЛЛАР СӘХИФӘСЕ

1930 ел. КПССның (ВКП(б)ның) XVI съезды карарлары белән рухланган бөтен совет халкы белән берлектә Татарстан хезмәт ияләре дә беренче бишьеллык планны вакытыннан элек үтәү, республикабызның ун еллыгын лаеклы каршы алу, халкыбызның экономикасын һәм культурасын үстерү өчен җиң сызганып көрәшәләр.

Халкыбызның утызынчы еллардагы ялкынлы көрәше, социализмның җиңеп чыгуы өчен дәртле омтылышы безнең журналыбызда да (ул вакыттагы исеме — «Атака») якты чагылыш тапкан.

«Без барабыз тигез сафлар белән
Партиянең корыч юлыннан
Шат көннәрне җыйнап, хезмәт аша.
Авырлыкка чыдам булынган.
Авырлыкны күреп тезләнмибез,
Авырлыкка балта чабабыз.
Без һавадан тормыш эзләнмибез,
Без тормышны эштән табабыз», —

дип яза ул елларның популяр шагыйрьләреннән берсе Мансур Крыймов. Авырлыклар белән фидакарь көрәш, якты киләчәккә көчле омтылыш журналның бу елларда чыккан һәр санында, аңа урнаштырылган һәр материалда үзәк урынны алып тора. Менә аларның кайберләре:

*Һади Такташ*

## Тыңла, ТАПП![1]

Һавада җилсез генә яңгыр тамчылары оча. Җирдән күтәрелгән төтеннәр, соры болытларга тоташып, домналарның морҗалары яңгырлы төтен атып торган болыт фонтаннарына охшыйлар.

Фонда:

Шахталардан чыгарылып ташланган порода таулары, рудниклар, яңа төзелеп килгән гигант шахталар.

[1] Кыскартылып бирелә.

Башта:

Бүгенге бөек төзелешнең язучы алдына куелган бөек бурычлары:

— Көрәш булмаган җирдә әдәбиятның кирәге юк.

— Әдәбият ул безнең идеалларыбызның омтылышы.

— Язучы ул үзенең сыйнфый идеалларының я һәлакәтен, я җиңүен тасвир итә.

Пролетариат язучысы әле төзелеп өлгермәгән, ләкин җиңелмәслек бер омтылыш белән төзелеп килгән бөек тормыш күренешләрен күрсәтү нигезендә, безнең бүгенге идеалларыбызның җиңүләренең иртәсе белән мәңнәрне кызыктыра алырга, аларны шул җиңүләр өчен булган көрәшләргә чакыра белергә тиешле.

— Моның өчен ул бүгенге социалистик экономиканың иртәсе алып килгән җиңүләрне айнык рәвештә алдан күрергә, мәңнәрнең кул хәрәкәтләрен, уй-омтылышларын өйрәнергә, тормыштагы бөтен күтәрелешләрне, бөтен тайпылышларны аңлап, бөек төзелешнең һәрбер винтын карап, күреп үтәргә, һәрбер тәгәрмәченең хәрәкәте китергән энергиянең күләмен үлчәп үтәргә тиешле.

Пролетариат язучыларының кыйммәте, аларның кирәклеге сыйнфый көрәш һәм бүгенге социализм экономикасы тудырган яңа хисләрне, яңа уйларны оештыра, бер формага кертә белүе белән, шул теләкләрне массаның йөрәгенә сеңдерә алуы белән үлчәнергә тиешле...

Татар пролетариатының 40 процентын үзенең эченә алган Донбасс шахталарына килү белән бурычлар тагын да ачыграк, тагын да ялангачрак күз алдына килеп басалар.

Донбасста хәзерге көндә 35 мең татар пролетариаты бар. Алар үзләре өстенә бурыч итеп куелган бишьеллык планны башка милләт эшчеләре белән беррәттән өч елда үтәргә омтылалар һәм кызыл такталарга языльп барган процент цифрлары бу планның өч елда үтәлүенә безне бик нык ышандыралар...

Донбасс шахтерлары партия тарафыннан үзләре алдына куелган бурычларны үтәүдә хәзерге көндә алдынгы рәттә баралар...

Бу бурычларның никадәр зур икәнен шахтерлар массасы белән күзгә-күз очрашкан чакта бигрәк тә нык сизәсең. Аларның бүгенге көрәш әдәбиятына сусаулары, бүгенге әдәбиятның бу сусауны канәгатьләндерер дәрәҗәдә үти алмавы тагын да ныграк күзгә бәрелә...

Оешкан шахтерлар белән ясалган кичәләрдә, зал тулы шахтерларның әдәбият турында булган сүзләрне, докладларны тавыш-тынсыз сәгатьләр буенча тыңлаулары — бу аларның әдәбият аркылы сыйнфый тәрбия алыр дәрәҗәгә хәзерләнеп җитүләрен күрсәтә...

Тавыш-тынсыз залда иптәш Шиһабетдинов авызыннан шатланып Татарстан пролетариат язучыларына үзләренең уңышлыклары турында бирелгән рапортны тыңлыйлар; шуннан аның авызы белән үзләренең кирәкле теләкләрен тезәләр. Шиһабетдинов иптәшне Овязов, Чубаев, Яхиннар алмаштыра. Болар бар да забойдан югары урынга күтәрелгән иптәшләр. Алар артыннан буяусыз, ләкин кирәкле теләкләр күтәреп забойщиклар чыга.

Тын рәвештә шигырь тыңларга хәзерләнгән зал алдына килеп чыгу йөрәктә тагын авыртулы, газаплы уйларны кабатлый.

— Шахтерларга нинди шигырь укырга соң? Аптырап каласың. Бу укучылар алдында тәүбә итү түгел. Бу — ачы, йөрәкне кискәли торган факт белән күзгә-күз очрашу.

Шигырьләр укыганда күз алдында тын һәм һәрбер сүзне аңлап калырга омтылган сүзсез залны күрәсең. Бу укылган шигырьләрнең эчке хисләре шахтерларга артык кирәкле булуларыннан түгел, бу шахтерларның бүгенге әдәбиятка бик нык сусауларыннан, аларның бүгенге әдәбиятны артык кирәксенүләреннән.

Без менә шушы безне кирәксенгән, белемгә, культурага сусаган киң массаның әдипләре, шагыйрьләре булырга, иҗатларыбызны аларның теләкләре нигезенә корырга тиешлебез. Донбасс шахтерлары бездән үзләренә кирәкле әдәбиятны сорыйлар. Шәриф аганың «Козгыннар оясында»гы шахтерлар юк хәзер. Алар инде 14 ел эчендә партиянең Донбасстагы көчле кадры булып тәрбияләнгәннәр.

Алар хәзерге көндә бишьеллык планны өч елда үтәргә омтылучы яңа шахтерлар кадры, белем, мәдәниятка сусаган забойщиклар кадры булып җитешкәннәр.

Шахтерларның тимер йөрәге,
Корычтан каты аның беләге,
Шахтерларның бүген йөрәгендә
Промфинплан тутыру теләге[1]...

*Г. Кадыйров*

# Машиналар гөрләгәндә

Тракторлар килә, колхозларга тракторлар...

Аларның саннары дистәләп-йөзләп кенә санарлык. Киң диңгезгә чумган балыклар кебек авылларга алар чумалар. Төнбоеклы күл өстенә кояш нурын сипкәч, сикереп уйнаган балыклар кебек басуларга алар чыгарлар. Карт авылның тирән тынлыкларын тракторлар гөрләп бозалар. Киң дә, зур да, таркау да бу карт авыл. Бертуктаусыз кайтып торган машиналар күз урман арасына кереп таралган арсланнар кебек «күренмиләр», «югалалар». Кызу көннәрдә сибелеп явып үткән яңгыр кебек тиз сеңәләр. Машинага сусаган авыл «Тагын» дип авызын ача.

Машиналар гөрләвен мин колхозларда байтак тыңлап йөрдем. Машиналар турында анда миңа бик күп сөйләделәр дә. Менә, колхозда бригадир булып эшләүче Сәлимнең сөйләгән сүзләре:

— Ашлык суга торган машиналарның чыңлаган тавышларын ишеткәнең бардыр, шул тавышларны йотылып тыңлаганың бармы? Сугу машинасының кызу әйләнгән барабаны чыгарган тавышлар тын авылның саф һавасын калтыратып тирә-якка яңгырыйлар. Атлар куучы малайларның сузып, сузып кычкырган тавышлары машина чалтыравы ашалый өзек-өзек булып ишетеләләр. Симез көзне каршылаган авылның шатлы җырын җырлаган музыкасы булган машина тавышлары авылга ямь китерәләр.

Безнең йортыбыз Вәли байның ындыры янында — авылның читендә иде. Инеш аркылы салынган такта күпергә, безнең өй чатыннан башланган тыкрык белән туры ук төшәргә. Йөкчеләрнең арбалары шагырдавы, атлар пошкыруы, бушлыларның ат йөгертеп аша чыккан вакытта күпер такталарының дөбердәве — бар да, бар да безнең өйгә ишетелеп тора. Кайбер вакытларда, әллә күк күкриме, яңгыр яварга телиме, дип алданып тыңлап карасак та, шул күпер тавышы булып чыга. Җәй көннәрендә күпернең тавышы тагын да ачыграк ишетелүчән, аркылы чыгучыларның ничә арбалы булуларына кадәр санап белергә мөмкин. Юлчылар үтмәгән чакта, иртә-кичләрен авыл тыныч йоклый, аргы очтан гармонь белән килүче егетләрнең нинди җыр җырлауларына кадәр ачык ишетелеп тора. Менә шушындый тавышсыз авылның тынлыгын бозып яңгыраган бер генә тавыш — тимер тавышы бар, ул да елның бер генә вакытында була торган машина тавышлары. Вәли байның ындыры башкаларга караганда ике-өч өлеш зур, аның кибәннәре күрше авылдагы «тиле байлар» ашлыкларына охшатып эскертләп өелгән була, ындырында һәр елны машина чалтырый, безнең әниләр аңар булышырга чыгалар, машинада атлар куарга кызыксам да, мине алып бармыйлар, балалар янында өйдә калдыралар иде. «Ябык атны йон баса, ярлы кешене бала баса», дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр. Безнең әнинең биш баласы, арада апам иң зурысы, миннән кечкенә тагы икәү — кечкенәсе малай, аңар «төпчек» дибез. «Ул йортта калыр, сез башка чыгарсыз», ди торганнар иде. «Зур үскәч өйләнеп башка чыгарсың, безне кунакка чакырырсың...» — дип сөйли башласалар, хурланып елыйсыларым килә, үпкәләп аска карап утыра идем. Иртән, кояш кызара башлау белән, мине уяталар. Башта, торасым килмичә, мышкылдап күзләрне уам, машина тавышлары чалтырап инеш буйларын яңгырата башлагач, йокыларым ачылып китә. «Төпчекне» күтәрәм дә йортка чыгам, әгәр еламаса — чөметеп булса да елатам да әниләр янына алып барам, «мәмәй сорап елый» дим. Әни аны имезгән арада, машинаны карыйм. Апамның урак белән көлтә бауларын кисүен, зур кара күзлекләр кигән кешенең көлтәләрне барабанга тыгып торуын, машинадан чыккан саламнарны

[1] Бу юллар шахтерларның йөрәк тибүләрен еллар буе тыңлаган, апар белән беррәттән забой чабып иске тормышның иң кабахәт авырлыкларын татыган татар шахтеры Субай шигыреннән. (*һ. Такташ искәрмәсе.*)

ике япьле агач сәнәк белән очыртуларны, озын агачлар белән күтәреп салам чүмәләләрен ташучыларны, орлыкларны ташучыларны, орлыкларны җилдерергә әзерләүчеләрне — барын да, барын да карыйм. Тикшерәм. Атлар куучы малайларга кызыгам, алардан көнләшәм. Хәйбушның чыбыркысы да минем чыбыркыдан начар, тавышы да чырылдап кына чыга, сугышкан вакытта мин аны елатмыйча калмыйм. Әнә шул Хәйбуш ат куа бит. Җитмәсә тагын ачуланышкан чакта: «Гомереңдә ат күрмәгән нәрсә, син ат йөретә дә белмисең... хәерче...» — дип мыскыл итә. Мин малай башым белән бала күтәреп йөрүне бер дә яратмыйм. Шул арада әни чакырып алып «төпчекне» күтәртә дә: «Бар, өйгә кайт, ут-күз белән шаярмагыз, ишетсен колагың, муеныңны борырмын, балаларны яхшы кара, елатма», — дип кала. Машинаның чалтыравы ерагайган саен шәбрәк яңгырый. Атларның пошкырулары, малайларның ай-һай салулары, кешеләрнең кычкырып сөйләшүләре тимер чыңнарын куерталар, матурлаталар, шул вакыт бер дә кайтасым килми. Йортка кайткач, тыңлап утырам, нигәдер, мин ул тавышларны бик якын күрә идем.

Зур үскәч тә ул тавышлар башымнан чыкмады, заводлардагы машиналарның коточкыч каты үкерүләре, шахта клитларына утырып чумгач, ишетелгән гигант машиналарның гөрләүләре шушы кечкенә вакытымда сакланып калган якын тавышларны хәтерләтәләр. Мин үзем гармонь-музыка авазларын бик яратам. Бәлкем, шуңа күрә дә ул тавышлар бер дә онытылмыйлар, бәлкем, минем бала вакытымнан сакланып килгән тирән истәлек булган машина тавышлары гомеремдә онытылмаслар. Бәлкем...

Бригадир Сәлим сүзен әйтеп бетерә алмады. Кояш нурларында тирбәлгән, сары диңгез кебек дулкынланып торган басу кырыннан килүче Галәви абзыйның:

— Балалар, бу ел авызыгыз икмәккә тиеште, тирә-як басуларда сезнекенә чагыштырырлык ашлык юк, башлары камчы кебек, бер-бер башакта сиксәншәр бөртек бар... — дип эндәшүе безнең сүзне бүлде. Трактор артына тагылган арбада бригадир Сәлим белән янәшә утырып баручы колхоз председателе:

— Галәви абзый, рәхим ит, арышны бергәләп чәчәрбез, әле соң түгел, гариза яз... — дип җавап бирде.

Галәви абзый Шәмсия апага таба карап үпкәләгән сыман нидер әйтсә дә, трактор тавышы аны Сәлимнәргә ишеттермәде. Ялпыланган басуны каплап җәелгән арышлар талып искән җил белән куян куалар, иске ызаннар өстенә камыш кебек куерып үскән, тоташ җәелгән басу яныннан Галәви абзый белән Шәмсия апаның китәселәре килми. Галәви абзый колхозга керүгә аягы-кулы белән каршы торуы өчен Шәмсия апага үпкәли. «Колхозга кермәсәгез, җирләрегезне үз атларым белән башкалардан элек сөрдерермен», — дип алдавы өчен Вәли кулакны тирги. Арыш чәчелгән җирләрен ары-бире генә тырнатып үтүе, рәтләп эшләмәве өчен Борһан малаен каргый.

Шәмсия апа карты белән булган вакытта кайгырып йөрергә яратмый: «Я, карт, үз атың, үз туның булмагач, шулай инде, кеше безнең өчен рәтләп эшләүдән бигрәк акчасын гына алырга ярата. Илдә чыпчык үлми, дигән, үлмәбез әле, агай-эне белән киңәш-уңыш итеп карарбыз, әле эш узмаган бит. Колхоз булсак та кешедән ким булмабыз, кайгырмыйк...» дип ул сүзне икенчегә борырга теләде. Икесе дә сүзсез калдылар. Шәмсия апа трактор артыннан карады да уйга чумды. Бригадир Сәлимнең нинди заводтан килүе, колхоз председателенең сабыр егет булуы турында уйланды, арбадагы мичкә эчендәге керосинны үзләренә бирсәләр, анда ничә лампылык керосин булуын эзләп табарга тырышты. Шәмсия апа ул һәрбер нәрсәне үз бизмәне белән үлчәп карарга яратучан. Авылга килгән һәрбер яңалыкны үзе күргән-ишеткән нәрсәләре белән чагыштырып аңлый. Аның өчен беренче яңалык булган аэропланны ул тавык чебиләрен урлый торган тилгәнгә охшатты. Канатлары да, койрыгы да, башы да бар, тәмам-тәмам тилгәнгә охшаган, дип күңеленә беркетеп куйды. Аэропланның гөрләвен күк күкрәгән тавышка охшатты. Соңгы елларда күк күкрәсә дә, аэроплан киләме, дип югары карый, аэроплан тавышы ишетелсә дә, күк күкри — яңгыр явар, дип салават әйтеп куя башлаган иде. Атсыз йөри торган ут арбасы турында да ишеткәне бар, үз күзе белән күрмәгәч, колагы белән тавышын ишетмәгәч, аны нигә охшатырга да белми тора. Авылларына трактор кайткач, Шәмсия апа үзе барып тирәли әйләнеп карады — үзе күргән нәрсәләрдән охшатыр әйбер тапмаса да, тракторның төсе, тавышы, йөреше бары да, бары да аның күз алдында бөтен бер картина булып калды. Хәзер ул башка яңалыкларны тракторга охшатып аңлый алырлык. Хәзер инде

күк күкриме, аэроплан үтәме, трактор киләме — менә шушы өч гөрләүне ишетү белән аерып белү Шәмсия апа өчен читен бер мәсьәлә булып калды.

Трактор көпчәкләрендәге тырнаклар каерып үткән юлны ашалый чыккан вакытта Шәмсия апа авыз эченнән генә ниндидер дога укып иренен кыймылдатты. Тракторга керосин ягып тору турында ишетсә дә, тракторның артыннан «перт-перт-перт» итеп чыккан зәңгәр төтеннең җиргә таралуын үз күзе белән күрсә дә, аның эчендә ниндидер шайтаның көч булуы турындагы шикләнүе бетеп җитмәгән әле.

Ызаннары актарылган тоташ басулардагы котырып үскән колхоз арышлары, колхозчыларның бертуганнар күк тату эшләүләре, бригадир Сәлим белән колхоз председателенең азыклар төяп басуга эшкә китүе, курсларда укып кайткан комсомолның трактор өстенә атланып йөрүе Галәви абзый белән Шәмсия апаның күңелләрен кытыкладьы.

Басу капкасыннан кергән вакытта Галәви абзый:

— Алдандык, карчык, Вәлиләр колхоз турында безгә алдап сөйләгәннәр икән... — диде.

*Июль, 1930.*

*Шәриф Камал*

# Тын таулар җилкәсендә

*Очерк*

Борылып-борылып ага торган матур Кама елгасының уң як кырыенда Чаллыдан егерме биш чакрымнар югары якта Тын таулар (Тихие горы) дигән җирне күпләр белмиләр.

Тын таулардан егерме чакрымнар түбән якта «Татарстан Швейцариясе» — Тарловка санаторийсы, шул ук Тын таулардан егерме биш чакрымнар югары якта Татарстанның «Баден-баден»ы — Иж чишмәсе санаторийсы ялтырап яталар. Боларның шөһрәте шактый зур. Якты җәй көннәрендә Кама һәм Агыйдел пароходларында сәяхәт итүче туристлар һәм турист булмаган «простой юлчылар» да боларны күздән югалтканчы карап калалар, пароход палубаларыннан ак киемле хәл җыйнаучылар һәм ап-ак алъяпкычлы чибәр (ерактан отыры чибәр) хадимәләр күренә. Ераклашалар. Тукта әле, бинокль бар ич... Менә шунда Кама буенда ямь-яшел нарат урманнары арасында берәр ай гына ял итеп ятсаң!

Ә Тын таулар?

Ниндидер бәләкәй генә пристань...

Тегеләй үзе гадәти бәләкәй пристаньнар төсле түгел түгелен. Бер чакрымга якын җирне әллә нәрсәләр белән тутырганнар... Калай мичкәләр, зур пыяла баллоннар, тау-тау өелгән тоз, тагын әллә ниткән ташлар, мәгъдәннәр, кыр буенда дистәгә якын баржалар. Кырмыска төсле кешеләр хәрәкәтләнеп, баржаларны бушаталар, өем тауларны тагын өяләр, зурайталар. Монда кырый буйлап киткән тар сызыклар — тимер юл, Тын таулар башына менеп киткән «Брусвайр» да бар. Бәләкәй вагоннар туктаусыз тәгәриләр...

— Нәрсә, монда якында берәр завод бармы икән әллә?

— Шулай булырга кирәк. Бондюг заводы шунда бугай.

— Неужели? Әлеге газетларда язылган мәшһүр заводны әйтәсеңме?

— Яхшылап белмим белүен, ләкин Кама буенда дигәннәр иде... Алай дисәң, морҗасы, фәләне, бер әйбере дә күренми...

— Тау артында навирны...

— Минем каютэссерәк, чорт возьми. Кухня морҗасы якын булырга кирәк.

— Минем зарарсыз... Кереп йоклап алырга кирәк.

Ә без Тын таулар җилкәсенә менеп китик.

Тын таулар җилкәсенә менгәч, без киң тигезлеккә чыгабыз. Бер чакрым ярым чамасы үткәч, җилкә чокырына барып җитәбез, әмма Тын тауларның җилкә чокыры һич тә тын түгел.

Бер бәләкәй генә тарих:

Моннан сиксән еллар элек — ул чагында да ерткыч, мәкерле булган капиталист

Ушковлар җилек суырып яту өчен элекке Вятка губернасының «тын» гына бер почмагын сайлап алганнар. Ялгышмаганнар. Промышленность үзәкләреннән ерак, ни җитте «кирәкмәгән» тәэсирләрдән имин булган шушы «дәррахәт» тә ялчы колларның кан тиреләре хисабына йөз меңнәр өстенә миллионнар өелә торган. Ләкин завод хуҗаларының тирән кеенечләренә каршы, 1905 елгы революция дулкыннары шушы тын почмакны да читтә тын гына калдырмый, 1905 нче, бигрәк тә 1906 нчы елларда Бондюг һәм Какшан заводы (Бондюгтан 18 чакрым җирдә шул ук хуҗаларныкы) эшчеләре арасында бик нык революция хәрәкәте кайнап китә. Заводның үзеннән ныклы революция җитәкчеләре чыга. Кашиваров, Жубров, Савинов, Шахматов, Красильников, Французов, Мартынов, татарлардан — Дәүләтшин, Гыймат Шәмсетдинов, Әхмәтгали Вәлиев, ике агай-эне Кашшаф һәм Әгъләм Сәхәветдинов иптәшләр революция хәрәкәтенә җитәкчелек итәләр. Урманда ясала торган маевкалар, эшчеләр арасына таратыла торган листовка, прокламацияләр аркылы 8 сәгатьлек эш вакыты, эшчеләр контроле һәм башка таләпләр куярга эшчеләрне кузгаталар. Татар эшчеләре арасында агитация-пропаганда эшләрен башлыча учитель Кашшаф Сәхәветдинов алып бара.

Эшчеләрнең гомуми дулкынланулары нәтиҗәсендә завод идарәсе, куркуга төшеп, 1907 нче елда 12 сәгатьлек эш вакытын ярты сәгать киметергә, $11^1/_2$ гә калдырырга мәҗбүр була.

Моннан соң, билгеле, реакция баскынлыгы, жандарм, урядниклар кысрыклыгы башлана. Ләкин шулай да кара көчләр революция утын бөтенләйгә сүндерә алмыйлар. Ул астыртын булса да, һаман дөрләп тора, акрынлап булса да, һаман көчәя бара. 1909 нчы елда завод идарәсе эш вакытын 10 сәгатькә калдырырга мәҗбүр була.

Империализм сугышы вакытында завод «сугышчанландырылу» сәбәпле, монда эксплуатация тагын да ныграк көчәя. 1916 нчы елның башында эшчеләр арасында ризасызлык дулкыннары баш күтәрә. Эшчеләр арасында юлбашчылык итүчеләрне учеттан алып фронтка җибәрәләр.

Шушы вакытта сәяси сөрген сыйфаты белән Бондюгта торучы С. Н. Гассар Бондюг эшчеләре арасында астыртын сәяси аң-белем эшләрен алып бара. Ул алдынгы татар яшьләрен дә үз тирәсенә оештыра. Татарлардан Баһаветдинов, Саттаров, Алимбиков, Гыйлаҗ һәм Шәйхи Фәсхетдиновлар, Рәхимҗан һәм башка иптәшләр шушы түгәрәктә башлангыч сәяси аң-белем алалар. Шулай итеп монда февраль революциясен каршы алырлык һәм аның беренче көннәреннән үк изү бауларын чишеп «митингавать» итәрлек беркадәр хәзерлек ясалган була.

Керенщина вакытында бер яктан Гассар юлбашчылыгы астында большевиклар группасы белән икенче яктан эсер Зварский һәм кадет Ситников группалары арасындагы көрәшләрнең мондагы эшчеләр массасына Октябрьны аңлы рәвештә каршы алырга ярдәм иткәнлекне дә әйтеп үтәргә кирәк.

Шуның белән бергә большевиклар ячейкасы җитәкчелегендә татар социалист яшьләре түгәрәге оешып (президиум членнары Әгъләм Сәхәветдинов, Саттаров, Баһаветдинов, Фәсхетдинов, Алимбиков, Хәмитов), башлыча татар эшчеләре массасы арасында нигытып эшлиләр.

---

Октябрь. Яңача оешу. Тын таулар җилкәсендәге киң чокыр яңача кайный. Дистәгә якын завод морҗаларыннан яңа хуҗалар куе төтен чыгаралар. Кама буйлап яңгыраган гайрәтле гудок тавышлары яңа хуҗаларны бөек җиңү шатлыгы белән котлыйлар.

Авыр гражданнар сугышы, егерме беренче кытлык ел. Чех-словак, Колчак фетнәләре. Гигант морҗаларның төтеннәре сыеклана. Гайрәтле гудок тавышларында моңсу авазлар ишетелә... Ләкин биек заводның батыр эшчеләр коллективы партия җитәкчелегендә корыч бердәмлек белән бу читенлекләрне бөтенесен ерып чыга. Көрәш арзанга төшми. Дошман бандалары кысрыклавы белән заводны ике тапкыр ташлап чыгарга туры килә. Эшчеләрнең күп өлеше винтовкага ябышып партизан сугышчыларга әвереләләр. Чиксез батырлыклар күрсәтәләр һәм байтак кына кыйммәтле корбаннар бирәләр. Ләкин җиңәләр. Кызыл Армия ярдәмгә җитешә.

Завод төтенләре яңадан куера. Гудок тавышлары яңа көч белән яңгырый башлыйлар. Тын таулар җилкәсендә мылтык, пулемет тавышлары урынына эш симфониясе гөрли башлый. Ныгытып винтовка тоткан корыч куллар завод цехларына кереп яңа көч, чиксез энтузиазм белән эшли, заводны аякка бастыралар.

Завод көннән-көн ныгый, елдан-ел эшен яхшырта бара. Ләкин... контрреволюцион корткычлык монда да үзенең ерткыч тырнагын батырырга омтыла. «Спец» битлеге белән химия промышленностеның югары оешмалары тирәсенә тыкшынган бу кабахәт җанварлар Бондюг заводының «сырье базасыннан ерак, искергән, файдасыз икәнлеген» «доказать» итәләр.

Корткычлар заводны бетерү юлында беркадәр эшләп тә өлгерәләр. Мәсәлән, күкерт әчесе эшли торган ике камераның берсен бетереп, аның урынына өч елеш ким продукция чыгара торган контакт цехы төзиләр.

Бу эш заводның бөтен цехларында диярлек эшләп чыгаруны киметүгә китереп тери. Чөнки мондагы завод цехлары технология процессы ягыннан бер-берсенә бик нык бәйләнгәннәр. Бу бер. Икенчедән, нинди дә булса берәр сәбәп (бозылу ягыннан шикелле) белән бердәнбер калган күкерт камерасы сафтан чыкса, заводның бөтен цехларын эштән туктату куркынычы туа.

Эшчеләр дошманның заводка, заводның йөрәгенә бик нык китереп сукканын аңлап алалар.

Көрәш башлана. Эшчеләр, инженер-техника хезмәтчеләре, завод директоры һәм партия оешмасы заводны саклап калырга тырышалар.

Ләкин дошман шактый көчле була. Бирешми. Һаман үзенекен эшләп тора. Заводның әһәмиятле кирәк-яраклары күчерелә башлый. Платиналы масса, паровоз, гирризгов миче һәм башка күп кенә әйберләр төрлесе төрле җиргә күчереләләр. Хлороформ цехының әсбабы Мәскәүгә күчерелә. Заводны бөтенләй туктатып архивка ташлауның актык срогы 1929 нчы елның 1 нче апреленә билгеләнә. Шуңа каратып кына сырье, ягу әйберләре һәм башкалар хәзерләнә.

Ләкин завод бетү чорында булуга карамастан, дошманның явыз ниятен сизеп алган эшчеләр коллективы, завод администрациясе һәм завод оешмалары аптырап калмыйлар. Бәлки заводның яшәргә тиешле икәнен, СССР химия промышленностенда аның әһәмияте нихәтле зур булганын эш белән исбат итәләр.

Сиксән еллык тарихка малик булып өч буын квалификацияле эшчеләр җитештергән (иске Россиядә беренче химия заводы) Бондюг социализм ярышына чыга. 1928—29 нчы хуҗалык елында дистәгә якын химия заводларын — Чернореченский, Березняковский, Кинишимский, Урал һәм Пермь заводларын — социализм ярышына чакыра.

Ярыш нәтиҗәсеннән:

1. Эшләп чыгару программасын 105% итеп үти.
2. Продукциянең үзенә төшкән бәясен 16% киметә.
3. Хезмәт чыгарышын 26% күтәрә.
4. Прогулларны 0,06% ка киметә.

Шулай итеп, һәрбер өлкәдә беренчелекне ал. Эшләп чыгарган продукциянең сыйфат ягын иң югары дәрәҗәгә күтәр.

Шуның белән бергә контрреволюцион корткычларның явыз планнары ачыла. Пролетариат хөкүмәте тарафыннан алар тиешле җәзаларын алалар.

Заводны туктатуга, корткычлыкка каршы көрәшүдә һәм социализм ярышы, ударчылык эшләрендә, партия оешмасы белән берлектә, алда торган җитәкчелек итүче кешеләрдән завод директоры Мектион иптәш, партиец инженер Тремба иптәш, кырык җиде ел хезмәт стажлы карт партиец Сәлах абзый Гыймадеттинов, техник Лебедов иптәш, кырык алты ел хезмәт стажлы карт эшче Мотыйгулла абзый Гобәйдуллин, кырык еллык хезмәт стажлы Җиһан Хөснетдинов, Скорихин, Белянин, Тимербаев иптәшләрне әйтеп үтәргә кирәк. Болар Кызыл Байрак ордены алган шанлы заводның иң алдынгы хезмәт батырлары, алар хәзерге көндә дә Татарстан гиганты — карт заводны яшәртү, Советлар иленең социализм промышленносте сафларында аны иң алдынгы урыннарның берсенә куеп алып бару эшендә меңләгән хезмәт коллективына үрнәк булып, җиң сызганып армый-талмый эшлиләр.

Шулай итеп Тын таулар җилкәсендә хезмәт симфониясе гөрли.

———□———

## *Хәсән Туфан*[1]

* * *

Кояш...
Үксеп үстем кояш итәгендә,
Мин идем, мин — аның баласы.
Ә ул әнә, үги иткәнедер,
Ник бер генә күлеп карасын.

Үсмер ерларыңны,
Шефсыз ерларыңны абынып ватсаң,
Исе китәр инде бик аның...
Эх, шулай да
Җимерек йортлы арык урамнардан
Калкыр әле заман ерлары!

Бездән качкан яшерен белемнәрне
Таладык без соры төннәрдән!
Әле инде аккумулятор күк,
Өләшербез безгә беленгәнне
Яңа көннәргә.

1925.

## Уралда

Быел да мин
Кайттым әле сиңа,
Сагындымдыр синдә чагымны...
Әйләндереп җибәр әле әйдә,
Тыңлыйм әле җырын валыңның.

...Күрәм, сизәм, кызлар-хәчтерүшләр,
Уегызны... күзегез аша да:
«Рәтле генә малай иде, имеш,
Шигырь моның... башын ашаган...»

Анда да шул
Җүнсезләр бар, бәгырем,
Анда да бар булмыш «мастер»лар.
Маташалар ап-астыртын гына,
Җаныбызга хәнҗәр салырга.

---

[1] Журналыбызның бу бүлегендә олы шагыйребез Хәсән Туфанның соңгы җыентыкларына кермәгән һәм әлегәчә матбугатта чыкмаган кайбер шигырьләре бирелә.

һадигә дә шулар, Нәҗмигә дә үчле.
Алар калды чарпыш эчендә,
Ә мин менә — сезгә кайттым әле
Нығыр өчен бераз, эшчеләр.

Кара йөрәк, ала җүнсезләргә
Ташландык без өйрәнчек килеш.
Яраланыр хисләр, канар бәлки,
Ә чыгарбыз барыбер җиңеп!

1927.

## Завод ябылгач[1]

*(Өзек)*

Башым яна, башым...
Нишләтим бу утлы уйларны!
Йокламакчы идем, булмады:
Бер йокыда җиде уяндым,
Бер йокыда...

Исән дуслар! Кайсы чанада сез!
Нинди җырны көйләп йөрисез!
Син, медичка, кая югалдың соң,
Нигә килеп, хәлне белмисең!

Доктор!
Минем абый рәтле һөнәр белми,
Урман кисеп гомер үткәрә.
Ул күтәргән юан бүрәнәнең
Авыр башы — минем йөрәктә...

Синең тунны, Кутуй, иңгә салып,
Җилгә бастым һава сулыйм дип.
Утлы башым кышны җылытты,
Нишләсәм дә эссем суынмый.

Эрегән бакыр кебек кайнап кояш
Тәрәзәгә чәчри офыктан.
Карап тора торба: бикле цехлар
Пәрәвезгә төренеп йоклыйлар...

Көн башлана. Кошлар уяналар.
Ябык цехта оя коралар.
Бетончылар бара пычкы сөйрәп
Казанкада утын турарга...

Ә «сул»лар да «уң»нар — чәкәләшә,
Шуннан да шәп «хезмәт» юк сыман...
Урал, Урал!
Сине юксынам мин,
Суга тилмерүче кош сыман.

1928.

[1] Татар пролетарлары күбрәк эшли торган Какшан заводы белән байтак күн заводлары ябылды. («Кызыл Татарстан», № 141, 1927.)

* * *

Каспий яры... Кырый урамнар...
Таныш җырлар агыла барактан:
Җим эзләгән кыр казлары кебек
Кыйгылдаша «ала канат»лар...

Көнкүрешең
Күчмә холык биргән,
Офтанмыйлар ил-су кала дип.
Мин дә шундый:
Кысан кырларыңда
Офык эзләп үскән балаң ич.

Әрәм итә гомерен брамат... дип,
Такташ мине көн дә тиргидер.
Нишлим!
Паровозлар керә алмый торган
Почмаклары күп шул илемнең...

Таулар... кырлар... Кайнар сукмаклар...
Таныш тавыш калка каналдан:
Кара кошлар кебек гаңгылдашып
Җир казыйлар «ала канат»лар...

1928.

## Уйланулардан

Тонна-тонна булып өелгән
тема рудасын
Эретәсе иде дә,
Ничек эретәсең домнасыз!

Укучы да үсте,
Таләпләр дә инде
үстеләр. —
Үз «мартенын», үз «домнасын» сорый
Шигырь дигән индустрия.

Төзелешләрдә инде элеккедән
Ничә тапкыр алда барабыз...
Менә шуңа тигезлисе иде
Тукай белән бүген арасын!

Әй син,
Атакага алдан кергән шигырь,
Кайда быргың! Кайда шул көнең!
Лирикасыз, җырсыз әдәбият
Оркестрсыз гаскәр түгелме...

1930.

# Татарстан бу

Шат халыклар сафы уртасында
Татарстан дигән ил килә,
Ленин васыять иткән туганлыкка,
Азатлыкка үрнәк ил килә.

Ленинебыз әйткән тапкыр сүзнең
Бер мисалы иде бу халык:
Халыкларга төрмә булган җирнең
Бер ристаны иде бу халык.

Ишекләргә барды — ишек бикле,
Тәрәзәгә килде — тимерле...
Тимер челтәр аша карый-карый
Гасырларча бу ил тилмерде.

Йоклый алмыйм... диде бөек Тукай:
Өй түрендә җил елый иде,
Җил еламый иде, ач үлемнең
Куркуыннан ил елый иде.

Тар кырларда, шахта төпләрендә
Бәхеткә юл эзләп карады...
Тапкан берен ике башлы тиран,
Ике башлы козгын талады.

Аллага да бераз тимичәрәк,
Динлесен дә үзенә нәртеп,
Үз халкының алгы өлешен Тукай
Ямашевлар ягына юнәлтте.

Бунтлар аша, кузгалышлар аша,
Асылулар аша үтте ил,
Берсе ауган җиргә — унау басып,
Ленинчылар белән китте ил.

Ни даны юк иде, ни белеме:
Культурага үги иде ул,
Фән йортына керсә, ишектәге
Каравылчы булып керде ул.

Калды ул чор... Ләкин чын байлыгын
Калдырмады халык берсен дә.
Бәгыренә салып алып килде,
Алып килде барын бу көнгә.

Бу бәгырьдә Ямашевларның
Факел булган йөрәге юкмы! —
Бу бәгырьдә Вахитовларының
Канга баткан күлмәге юкмы!!
Ни малы юк иде, ни даны юк,
Дөньясына үги иде ул.
Бүген менә социализмны
Туган телдә җырлый инде ул!
Кыю хәзер ничек безнең күңел,
Көләч хәзер ничек безнең тел!
Китте бездән барлык томаналык,
Китте бездән бөтен мескенлек!
Табигатьнең яшерен серләренә
Ишек ача безнең Камайлар.
Терекләкнең кара көчләренә
Һөҗүм булып үсә малайлар!

1940.

# ТАТАР МӘДӘНИЯТЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН

## 1925 ел [1]

**6—11 январь.** Мәскәүдә пролетар язучыларының 1 нче Бөтенсоюз конференциясе эшләде. Конференциядә Татарстан язучылары исеменнән Г. Гали, М. Максуд, Г. Кутуй һ. б. катнашты.

**11 январь.** Татар театры М. Җәлилнең «Бибкәй кыз» исемле музыкаль драмасын сәхнәгә куйды.

**23 январь.** «Сулф», «Октябрь» кумәге һәм студентлар әдәби түгәрәгенең берләштерелгән җыелышы булды.

**28 январь.** «Кызыл Татарстан» газетасында С. Сәетгалиевнең «Татарстан җөмһүрияте һәм иптәш Ленин» исемле истәлеге басылды.

**4 февраль.** Татарстан Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе җыелышында Гыйльми үзәк янындагы татар коллегиясенең составы расланды. Председатель Г. Ибраһимов, әгъзалар: Ш. Әхмәдиев, И. Рәхмәтуллин, Ф. Сәйфи-Казанлы, Л. Гомәр, М. Парсин, Г. Толымбайский, М. Корбангалиев, Г. Рәхим һ. б.

**15 февраль.** Татар театры бинасында Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулуга багышланган гыйльми җыелыш уздырылды. Күренекле галимнең тормыш һәм иҗат юлы турында докладлар белән Г. Ибраһимов, М. Парсин, М. Корбангалиев, Г. Рәхим чыкты.

**6 март.** «Красная Татария» газетасында профессор В. Смолинның Идел буе болгарларына багышланган «Описание местного края, сделанное 1000 лет тому назад» исемле мәкаләсе басылды.

**8 март.** «Кызыл Татарстан» газетасында түбәндәге игълан басылды:

«Татар әдәбияты көтепханәсен булдыру өчен, әдипләрнең, шагыйрьләрнең 150—200 табак чамасы күләмендә әсәрләре басылачак. Шуның өчен соңгылар үзләренең биографияләрен, рәсемнәрен, әсәрләренең исемлекләрен Гыйльми үзәккә җибәрергә тиешләр».

**1 апрель.** Шәрыкне өйрәнү институтының (Мәскәү) гыйльми совет утырышында Г. Гобәйдуллин Каюм Насыйриның моңарчы билгесез әсәрләре турында доклад белән чыкты.

**5—15 май.** Матбугат көненә багышлап, Комклуб бинасында рус һәм татар матбугаты күргәзмәсе ачылды.

**25 май.** Казанда Татарстан хәбәрчеләренең беренче съезды эшли башлады.

**18 июнь.** РКП(б) Үзәк Комитеты «Матур әдәбият өлкәсендә партия политикасы» исемле резолюция кабул итте. Резолюциянең татарча тексты «Безнең юл» журналының 1926 елгы 5—6 саннарында басылды.

**25 июнь.** Беренче татар операсы «Сания»нең премьерасы булды.

**8 июль.** «Эшче» газетасында Ш. Усмановның «Памирдан радио» исемле фантастик хикәясе басыла башлады.

**15 июль.** «Коммунист» газетасында А. Әхмәтнең «Аклар вәхшәте онытылмас» исемле хикәясе басылды.

**Июль.** Казанда әдәби, сәяси, фәнни «Авыл яшьләре» журналы чыга башлады. Редакторы Фәхретдинов.

---

[1] Журналыбызның бу саныннан татар әдәбияты һәм сәнгате хроникасының филология фәннәре кандидаты З. Усманова әзерләгән өлешен урнаштыра башлыйбыз.

*Редакция.*

**2 август.** «Кызыл яшьләр» газетасында Х. Госманның «Эш көнендә авыл балалары» һәм Н. Баянның «Пароходта» исемле хикәяләре басылды.

**Август.** Татарстан матбугат нәшрияты комбинаты «Кызыл Армия сафында татар-башкортлар» исемле рәсемле альбом бастырып чыгарды.

Мәскәүдә татар телендә «Фән һәм дин» исемле журнал чыга башлады.

**2 сентябрь.** Казанга Мәҗит Гафури килде.

**4 октябрь.** «Красная Татария» газетасында М. Гафуриның «Эшче» поэмасыннан аерым өзекләр басылды. Поэманы русчага П. Радимов тәрҗемә иткән.

**30 октябрь.** «Кызыл яшьләр» газетасында Һ. Такташның «Байрак тегәбез» исемле яңа шигыре басылды.

**4 ноябрь.** К. Тинчуринның «Нәни абый» пьесасы белән татар театрының 1925—26 елгы кышкы сезоны ачылды.

**1 декабрь.** «Кызыл Татарстан» газетасында М. Мутинның «Татар театрының 20 еллык бәйрәме» исемле мәкаләсе басылды.

**4 декабрь.** Татар театры сәхнәсендә Ф. Бурнашның «Камали карт» комедиясе күрсәтелде.

**6 декабрь.** Карт педагог Корбангалиевнең 30 еллык хезмәт бәйрәме үткәрелде.

## 1926 ел

**28 январь.** Театр бинасында татар театрының 20 еллык юбилеена багышланган тантаналы җыелыш уздырылды. Татарстанда театр сәнгатенең торышы һәм бурычлары турындагы доклад белән Галимҗан Ибраһимов чыкты.

**7 февральгә кадәр.** Партиянең Татарстан өлкә комитеты үзенең икенче пленумында татар телен гамәлгә ашыру турында карар кабул итте.

**7 февраль.** Татар театрында К. Әмиринең «Печән базары» исемле яңа әсәре куелды.

**25 февраль — 6 март.** Бакуда тюркологларның беренче съезды эшләде. Съезд эшендә Татарстаннан Г. Ибраһимов, С. Атнагулов, Г. Шәрәф, Г. Максудов, Г. Сәгъди һәм башкалар составындагы зур бригада катнашты.

**9 март.** Атаклы татар язучысы Фатих Әмирхан үлде.

**16 март.** Уфада күренекле татар шагыйре Сәгыйт Рәмиев үлде.

**20 март.** «Кызыл Татарстан» газетасында Г. Ибраһимовның «Тюркология съездында тикшереп үтелгән мәсьәләләр» дигән мәкаләләр циклы басыла башлады.

**28 март.** Мәскәү Үзәк татар эшчеләр клубында Ф. Әмирханны искә алу кичәсе уздырылды.

**Март.** «Безнең юл» журналында А. Шамовның «Шәлле хатын» («Рәүфә») исемле озын хикәясе басылып чыкты.

**11 апрель.** «Кызыл Татарстан» газетасында К. Нәҗминең «Үпкәләштән булмасын, чынын әйтик» исемле мәкаләсе басылды.

**13 май.** «Кызыл Татарстан» газетасында Ә. Еникинең «Балалар әдәбияты кирәк» исемле мәкаләсе басылып чыкты.

**Июнь.** Партиянең Татарстан өлкә комитеты органы — «Җитәкче» исемле айлык журнал чыга башлады. Редакторы Зәки Гыйрманов.

**4 июльгә кадәр.** Шахта эшчеләренең хезмәте һәм тормышы белән танышу өчен Гадел Кутуй Донбасска китте.

**21 июль.** Яшь шагыйрь Исмәгыйл Закири үлде.

**5 август.** «Кызыл Татарстан» газетасында К. Нәҗминең «Үтелгән юл» исемле яңа романыннан өзекләр басыла башлады.

**Август.** «Азат хатын» журналы чыга башлады.

**25 сентябрь.** Казанда яшь язучы Ф. Әсгат үлде.

**20—25 октябрь.** Казанда хәреф киңәшмәсе эшләде. Киңәшмә, 1926—27 елларда татар телендә дәреслекләр чыгаруда кулланыр өчен, гарәп шрифтында 30 хәрефтән торган алфавит кабул итте.

**26 ноябрь.** Татарстан Халык Комиссарлары Советы Китап палатасы ачу турында карар кабул итте.

**Декабрь.** «Азат Себер» газетасында Ш. Маннурның «Ахыр заман» исемле хикәясе басылып чыкты.

**24 декабрь.** «Кызыл яшьләр» газетасы Г. Минскийның «Төнге бураннарда» исемле хикәясен басып чыгарды.

## 1927 ел

**8 январьга кадәр.** Пролетар язучыларының әдәби кичәсе уздырылды. Кичәдә бүгенге әдәбият һәм алдагы агымнар турында доклад тыңланды.

**14 январь.** Татар театрында Р. Ишморатның «Яңача үлем» әсәре буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды.

**17 январь.** «Урал» газетасының чыга башлавына 20 ел тулу уңае белән, театр бинасында тантаналы җыелыш уздырылды.

**20 январь.** Казанга В. В. Маяковский килде. Кичен театр бинасында «Лицо новой литературы» дигән темага доклад сөйләде.

**21 январь.** Маяковскийның Казанга килүе уңае белән, «Кызыл Татарстан» газетасында Гадел Кутуйның «Маяковский» исемле мәкаләсе чыкты.

**21 февраль.** Г. Кутуйның «Казан» исемле яңа пьесасы сәхнәгә куелды. Спектакльдә Мулланур Вахитов ролен артист Шакир Шамильский башкарды.

**28 февраль.** Татар сәхнәсенең өлкән көчләреннән берсе, хезмәт каһарманы Нури Сакаев үлде.

**13 март.** Татар сәхнәсенең танылган артисты Бари Болгарский (Фәйзуллин) үлде.

**19—20 март.** Казанда яңалифчеләрнең беренче конференциясе эшләде. «Яңалиф» җәмгыятенең председателе итеп Ф. Сәйфи-Казанлы сайланды.

**24 апрельгә кадәр.** Шәриф Камалның «Таң атканда» исемле яңа романы басылып чыкты.

**Май.** «Безнең юл» журналының чыга башлавына биш ел тулды.

**14 июнь.** Партиянең Татарстан өлкә комитеты бюросы «Милли культура мәсьәләсе турында» резолюция кабул итте.

**Июнь.** Казанда «Татар дәүләт академия театры» исемле журнал чыга башлады. Соңыннан аның исеме «Тамашачы» дип үзгәртелде.

**4 июль.** Казанда татар мәдәнияты йорты ачылды.

**3 август.** Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы «Татар язуында латин шрифты куллану турында» карар кабул иттеләр.

**15 октябрь.** «Кызыл Татарстан» газетасының 2000 нче саны чыкты.

**4 ноябрь.** Һ. Такташның «Күмелгән кораллар» пьесасы буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды.

——□——

# КАБАТЛАНМАС ДОКУМЕНТ

*«1923 нче елның май урталары. СССР илчесе иптәш Воровскийның Швейцариядә... үтерелгән көннәре. Советлар иленең бөтен шәһәрләрендә дошманның ерткычлыгына каршы протест демонстрацияләре бара. Казан завод-фабрикалары да, уку йортлары да урамнарга агылганнар. Әнә шуларның тыгыз колонналары арасында, газета сатып йөрүче малай кебек, берәү ниндидер кәгазь таратып йөри. Тузган, озын көлсу чәчле, зур зәңгәр күзле, өстенә юка соры пальто кигән бу егет турында безнең ТКУ (татар коммунистлары университеты — ред.) студентлары арасында: «Һади Такташ!» дигән сүзләр таралды. Әле ул чагында 22 генә яшендә булган Тамбов егете, кичен иптәш Воровский үтерелү хәбәрен ишеткән дә, төн буе утырып шигырь язган. Иртә белән «Шәрык» матбагасенә барып, шундагы наборщиклардан җыйдыртып, «американка»да бастырып та өлгергән. Хәзер шул шигырьне бер култык астына кыстырып, икенче кулы белән өләшеп йөри икән».*

*Бу юлларны Такташның замандашы тәнкыйтьче Гомәр Гали язып калдырган. Листовканың үзеннән бер данә дә сакланмаган дип исәп ителә иде. Ләкин, бәхеткә каршы, аның бер данәсе Мәхмүт Максудта сакланган булган икән. Язучының иптәше Гөлсем ханым Максутова-Җиһаншина аны безгә тапшырды. Татар совет әдәбиятының кыйммәтле документы буларак, без аның белән укучыларыбызны да таныштырырга булдык.*


ئالتون سارايلارغا.

Һ. Такташ бастырып чыгарган листовка. Андагы шигырьне 92 нче биттән укы.

*Һади Такташ*

# Алтын сарайларга

Канлы кылыч болгап юлбасарлар
Тагын килә илнең өстенә.
Уяныгыз, илнең батырлары!
Алар килә,
Әнә, ишетәсезме!!
Аяк тавышлары ишетелә.

Уяныгыз, атка атланыгыз!
Әй сез, кемнәр зурлар, көчлеләр!
Үч алырга алтын сарайлардан,
Үч алырга, кемнәр үчлеләр!

Илебезне җимерер, талар өчен,
Комсыз байлар, лордлар, түрәләр
Бүген анда, канлы Европада
Тәре үбеп антлар бирәләр.
Соң сез, мәгърур, көчле ил уллары,
Шуңа карап башыгыз иямсез!!
Мескеннәрчә тагын оялмыйча
Коллык богауларын киямсез!!
Юк, юк,
Күкрәгендә ирек нуры булган
Һичбер кеше моңа баш имәс!
Ышанмыйбыз, юк, юк, ышанмыйбыз,
Ил уллары алай кимсенмәс!

Илебезнең иркен туфракларын
Таптатмаска антлар итәбез!
Әй, сез, лордлар, ерткыч юлбасарлар,
Мәйдан ачык,
Сезне көтәбез!
Без ирекне җанлы коллык белән
Алмаштырып сайлый алмыйбыз!
Күрәсезме,
Сезгә нәфрәт итеп,
Көлә, көлә кылыч сайлыйбыз!
Яки безгә үлем, яки сезгә!
Ишетегез!
Илчебезнең канын даулыйбыз!

Казан, 14 май, 1923 ел.

——□——



*Үлем турында уйлама,*
*Илең турында уйла:*
*Илең турында уйласаң*
*Гомерең озын була.*

ФАТИХ КӘРИМ

Малик Хәмитов

# СОЛДАТ ДАНЫ

*Очерк*

Сөгъдә бүген эштән соңгарак калып кайтты: товар кабул итте, атна буе җыелган акчаны илтеп килде. Бер уңайдан Яльчик тегермәненә дә шалтыратты: авылдашлары белән бергә улы Ренат та ак он тарттыру өчен трактор чанасына төяп өч капчык бодай алып киткән иде — исән-сау барып җиттеләрме икән! Барып җиткәннәр, тарттырганнар, ләкин кайтырга чыкканда гына тракторлары ватылган икән. Үзе генә түгел, өстендә толып, ашарына бар, төн уртасында булса да кайтып җитәрләр әле...

Тәмам караңгы төшкән иде инде. Кече капканың пружиналы бигеп ычкындырды да ишек алдына атлады. Ни күзе белән күрсен, сыер да, сарыклар да шушы вакытка кадәр ишек алдында йөриләр. Алларына да салмаганнар, эчергән кеше дә юк икән — терлекләр аны сырып кына алдылар. Инде караңгы дип тормадылар — болдыр астыннан казлар да каңгылдашып чыкты. Аларга да ашаткан кеше юк. Ул көн саен Исламга караганда да, балаларга караганда да соңгарыбрак кайта, ә мондый хәлнең булганы юк иде. Терлекләр ашатылган, эчертелгән, абзарларга ябып куелган була иде. Әллә Исламга берәр хәл булдымы! Алай дисәң, үзе өйдә булса кирәк. Әнә, түр тәрәзәдә өстәл лампасы яна...

Сөгъдә терлекләргә иркәләп бер-ике сүз әйтте дә тавыш чыгармыйча гына алгы өйгә керде. Самовар үкереп кайный, өстенә пар күтәрелгән: куйган да оныткан, ни гаҗәп хәл булды икән! Суы бетеп эремәсен тагын,— Сөгъдә тиз-тиз генә самоварның

морҗәсын алып, өстен япты. Аннары пальтосын салды да, әкрен генә ишекне ачып, түр өйгә карады. Ислам маңгаен уч төбенә терәп, өстәлдә яткан ниндидер кәгазьләргә күзләрен төбәгән дә уйга калган иде. Берәр җитди, кирәкле эше бардыр инде, я колхоздагы терлекчелек эше буенча отчет әзерлидер, я халыкара хәл буенча лекция укырга кушканнардыр үзенә.

Сәгъдә Исламны эшеннән бүлдереп тормады, өстен-башын алмаштырды да терлекләрне карарга чыгып китте.

* * *

— Ислам, әллә өйдә сугыш музее ачарга булдың инде!

Ислам, сискәнеп, кинәт урыныннан торды, ишеккә карады. Анда аксыл сары чәчләре бәсләнгән, арткарак шуышкан шәленә печән валчыклары кунган хатыны елмаеп басып тора иде. Аннары ул алдына, өстәл өстенә, күз төшерде. Чыннан да өстәл өсте орденнар, медальләр, Башкомандующийның рәхмәт кәгазьләре белән тулы иде.

— Менә ни... Эзтабарлар... — диде дә Ислам, гаепле эш өстендә тотылган бала кебек каушап, тукталып калды.

— Нинди эзтабарлар, — диде хатыны. — Монда утырып нинди эз тапмак буласың!

— Юк ла. Ни... Терлекләрне карарга да оныткәнмын. Хәзер чыгам. — Ул хатыны каршысына юнәлде. Сәгъдә урыныннан кузгалмады, һаман элеккечә елмайган килеш, аңардан күзен алмады. — Тиз генә ашарларына салып керим. Самавыр куйган идем. Сүнмәдеме икән!..

Хатыны һаман урыныннан китмәде.

— Сорагангa җавап бир инде син, — диде. — Нинди эзтабарлар!

— Каяндыр белеп алганнар. Пионерлар аптыраталар: безнең белән очрашу үткәр әле дип. Ә мин ни сөйләргә белми азапланып утырам менә. Кайчаннан бирле.

— Алай гына булса ярый, — диде Сәгъдә һәм, урыныннан кузгалып, эш киемнәрен салды.

— Әйдә, чәй әзерлибез, тамак ялгап алабыз. Рушания кайда!

— Дәресен әзерләде дә җиңгәләренә китте. Хатыннар җыялар икән, сине дә чакырганнар. Чәй эчәргә.

— Барсам барырмын. Әйдә, үзең турында уйла. Көндез дә ашамагансыңдыр әле!..

— Менә ни... Сугыш турында уйлап булмый икән хәзер, Сәгъдә, — дип сөйләп китте Ислам, чәен өреп суыта-суыта. — Башта гел колхоз хәлләре. Ни бит... Көз көне барлык чөгендерне биреп җибәрергә ашыктык. Садыйков әйтмешли, бүгенге көн белән генә яшибез. Терлеккә тамыр азыкны күбрәк калдырган булсак, менә хәзер икеләтә сөт, ит алган булыр идек. Моның өчен колхозга акчасы да икеләтә артыграк булыр иде. Ие, ул вакытта да колхозчыларга түләр өчен акча бик кирәк иде. Ну, ләкин, безнең колхоз сөт буенча да, ит буенча да районда әйбәт бармый бит. Сәбәбе — азык мәсьәләсе. Болын юк, силос аз. Салам белән ерак барып булмый. Үзкыйммәт арта диеп Мөхетдинов өстәмә түләүне дә кыса. Иртәгәге көнгә карый белергә кирәк. Моны бит бер председательдән генә түгел, миннән дә сорыйлар...

— Колхозчылар терлеге турында ни уйлыйсыз! — диде Сәгъдә. — Бөтен кеше зарлана: корма юк, ди.

— Үзең уйлап кара, — диде Ислам, чынаягын самовар янына этәреп, — Вахитов колхозына кергән Чирмешән, Бакырчы, Багыш, Аю Көйдергән, Тәүгилде авылларында меңнән артык хуҗалык. Меңгә якын сыер, биш меңләп сарык дигән сүз бу барысын исәпләгәндә. Колхозның терлекләре дә шуннан әллә ни артык түгел. Барысы өчен дә азык шул ук җиде мең гектардан...

— Сугыш вакытында ул терлекләре белән 25 сотый бәрәңгесе кешеләрне ачлыктан коткарды. Сыер җигеп көлтәсен дә ташыдык, икмәген дә илттек, сөтен дә бирдек, үзебезгә дә кала иде әле... Ярар инде. Моны синең белән мин генә хәл итә

алмыйбыз. — Сөгъдә, торып, савыт-сабаларны җыештырырга керешә. — Бар, эшеңдә бул. Балалар да белсеннәр сугышның ни икәнен.

Әйе, балалар да белсен сугышның ни икәнен. Егерме елга якын сандык төбендә яткан орденнарын, медальләрен, Башкомандующийның рәхмәт кәгазьләрен актарып алды. Ничә еллар буена колхозның партия оешмасы секретаре булып эшләгәндә бу турыда исенә дә кертеп карамаган иде. Колхозның көндәлек эшләренә генә күмелеп калырга тиеш түгел иде бит ул. Партия җитәкчесенә тәрбия мәсьәләсе дә — балаларны гына түгел, олыларны тәрбияләү мәсьәләсе дә — турыдан-туры карый бит. Дөрес, эш барышында бу мәсьәлә Исламның игътибар үзәгеннән төшмәде. Ләкин мәктәп, балалар белән бәйләнеш ничектер сүрән иде. Янәсе, никадәр укытучылар коллективы бар, алар шуның өчен акча алалар.

Ә яшьләрне Ватанга бирелгәнлек рухында тәрбияләүгә партия һәм хөкүмәтебез ничек зур әһәмият бирә икән. Эзтабарларның Мәскәүдә үткәрелгән бөтенсоюз слетында маршаллар, генераллар катнашты. Алар да моңа кадәр халыкка билгеле булмаган сугыш батырларын эзләүче пионерлар белән якын бәйләнештә. Старшина Исламның да фашистларны җиңүгә керткән өлеше аз түгел. Ул бу сугышта чигенү ачысын да татыды, аннары Сталинградтан Эльба елгасына кадәр алгы сызыкта дошманнарны кырды. Батырлыклары өчен аны хөкүмәтебез Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Беренче, Икенче, Өченче дәрәҗә Дан орденнары, Кызыл Йолдыз ордены, ике «Батырлык өчен» медале, ике «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале, «Сталинград оборонасы өчен», «Варшаваны азат итү өчен», «Берлинны алу өчен» медальләре һәм Башкомандующийның бик күп рәхмәт кәгазьләре белән бүләкләде.

Дөрес, ул моңа кадәр сугышта күргәннәре турында искә төшерергә яратмый иде. Газеталардан укып, радио тыңлап, сугышка омтылучыларның планнарына карата аның җен ачулары чыга. Ләкин бу ачудан кемгә файда да кемгә зыян — бүтәннәргә дә сугышның ни икәнен аңлатырга кирәк икән.

Дөрес, сугыш турыдан-туры бу тирәләргә кагылмады. Ләкин аның җиле тиде.

* * *

Сугышның бер елы эчендә ике мәртәбә яраланып, ике мәртәбә госпитальдә ятып чыкты Ислам.

...1939 елда армиягә алынды ул. Башта ездовой булды, аннары аны артиллерия полкына күчерделәр. 122 мм лы гаубицаның наводчигы булган хәлендә, үзенең яшьтәшләре белән бергә, ул бу дәһшәтле ату коралының үзенчәлекләрен өйрәнде, аңардан ничек итеп дошманга тиз ату һөнәрен үзләштерде. Орудие наводчигының хәрби әзерлегенә командирлар аеруча зур игътибар юнәлттеләр, чөнки расчетта аның эше гаять җаваплы. Көн артыннан көн күнегүләр белән үтте. Маршлар, туптан ату күнекмәләре, тактик өйрәнүләр яшь сугышчыларны чыныктырды.

Бу чыныгуның кирәге зур булды. Тиздән алар полкын Ленин шәһәренә куркыныч тудырган ак финнәргә каршы сугышка керттеләр. Атаклы Маннергейм сугыш корылмаларын, ныгытмаларын җимерүгә Исламның да өлеше керде. Алар расчеты дошман өстенә йөзләрчә эре калибрлы снаряд яудырды.

1941 ел. Армиядә кадровой хезмәтнең соңгы елы. Ул да, аның кордашлары да быел запаска чыгарылачак, алар туган якларына кайтып китәчәк. Күз алдында аның туган авылы Багыш, әнисе, туганнары, кайдадыр Чувашстан якларында башланып, Зөя елгасына коя торган Чирмешән суы.

Әлбәттә, фин сугышы батыры, кызылармеец-отличник, җиде класс белемле Ислам Насыйбуллинны бөтен Багыш авылы зурлап, ихтирам белән каршы алыр иде. Хәрби тормыш, хәтта сугыш мәктәбен узган, шул ук вакытта заманына күрә ярыйсы гына грамотный булган яшьләр күп түгел иде әле авылларда. ...Ләкин... ләкин немецфашист бомбалары аның кизләү чыганагы кебек саф хыялларын, төшке кояш кебек якты өметләрен челпәрәмә китереп, җимереп ташлады.

Исламны — тәҗрибәле артиллерист-наводчикны — Мәскәү янында тора торган махсус частька күчерделәр. Аны һәм бик сайланып алынган иптәшләрен моңа кадәр беркемгә дә билгеле булмаган яңа корал белән эш итәргә өйрәтә башладылар. Тырышлыгы белән дә, җитезлеге белән дә Исламның аерылып торганын күреп, — өстәвенә, аның артиллерия буенча тәҗрибәсе дә шактый иде, — машина командиры итеп билгеләделәр. Ә бу машина — гвардия минометы — Бөек Ватан сугышында үзен данга күмгән «Катюша» машинасы иде.

1941 елның 17 сентябре. Өсте яшел брезент белән капланган машиналар илебез башкаласыннан чыгып китте. Алда Украина. Каршыга юлындагы һәр нәрсәне җимереп, яндырып каһәр төшкән фашист үрмәли.

Машиналар ашыга. Ял итәргә дә тәүлеккә ике мәртәбә генә тукталалар — капкалап алу өчен генә. Гвардиячеләр ашкынып фронтка ыргылалар.

Менә фронт якынлаша инде. Моны шуннан белергә мөмкин: ала алган кадәр йорт-җир җиһазларын атлы арбаларга төягән колхозчылар күбәйгәннән-күбәя бара. Алар сугыштан качып көнчыгышка чигенәләр. Исламның боларны күргәндә күңеле тула: алар бит ата-бабадан калган җир-суларын, гомер иткән йорт-җирләрен, — кыскасы, үзләренең күңелләре, җаннары-тәннәре береккән урыннарны ташлап китәргә мәҗбүрләр. Шул муены астына килгере немец аркасында.

Менә машиналар олаулар яныннан узалар. Йөзгә якын булыр. Олауларга балачагалар, карчыклар утырган. Бүтәннәре җәяүләп атлыйлар. Чыр-чу, елашу. Олаучылар артыннан сыер-сарык көтүе — терлекләрне дә калдырмаганнар. Аналарын югалткан яшь бәрәннәр тавышы Исламның йөрәген телеп-телеп ала. Аларның тавышлары шундый ялварулы, шундый үзәк өзгеч — Исламның күзләренә яшь килә...

Сугышлар Полтава шәһәре тирәсендә бара иде.

Аяз төн. Батарея командиры көнбатыш яктагы йолдызларның берсен наводка ноктасы итеп алырга кушты. Кая атасы, миналарның кайда төшәсе командирларга гына билгеле булгандыр — ул вакытта бу машина бик яшертен хәрәкәт итә иде бит.

— Ут!

Батарея бер залп бирде дә тиз генә кузгалды. Урман юллары буйлап алар Харьков шәһәренә таба киттеләр.

Бу залпның нәтиҗәләре ничек булганын Ислам белмәде. Әлбәттә, көчле булгандыр. Күктә фашистларның разведка самолетлары кинәт күбәеп китте.

Төрле урыннан берничә залп биргәннән соң, батарея көннәрнең берсендә Богодуховка шәһәре тирәсенә тукталды. Тукталып, дошман ягына залп бирүе булды, бу урынга фашистларның еракка ата торган орудиеләреннән снарядлар яварга тотынды. Димәк, күзәтүчеләре булган...

Ислам аңына килгәндә, күзләре күрми, колаклары ишетми иде. Тора-бара колак нәрсәдер шәйли башлады: тук-тук, тук-тук, нәрсә соң бу! Пулемет тавышы дисәң, тукылдау сирәк. Тукылдаган саен, гәүдә селкенеп киткәндәй була. Ул кайда! Әйе, ул чалкан ята. Җир өстендә түгел, мендәр өстендә, постельдә ята. Димәк, ул вагонда. Тукылдау тавышы — вагон тәгәрмәчләре тавышы. Колакка сөйләшкән авазлар да ишетелгәндәй булды. Әйе, ул санитарный вагонда. Борынга ниндидер сасы ис керә, укшыта. Ул ыңгырашканга килгән санитар аның йөзен бәйләгән бинтларга ничектер кагылып китте, колактан шуыштырды. Колак яхшырак ишетә башлады.

— Сезгә нәрсә кирәк!

— Битем авырта... яңадан бәйләгез. Косасым килә, — диде Ислам.

— Госпитальгә барып җитмичә ярамый, түзегез, — диде аңа хатын-кыз тавышы.

Колакка ирләр тавышы керде — аның турында сөйләшәләр булса кирәк:

— Башын-йөзен бәйләгәннәр, танк эчендә калып янган, ахры.

— Юк, киеме танкист киеменә охшамаган, пехота да, авиатор да түгел...

Ул тагын һуштан язды...

* * *

Башта Харьков, аннан Сталинград госпитальләре. Ниһаять, ул шәһәрдән ерак түгел Монастырское авылындагы запас пехота полкында. Әлбәттә, элек үзең хезмәт иткән гвардия минометлары полкына кайтыр идең, кайдан һәм кемнән, ничек итеп табасың...

1942 елның мартында тупчы Ислам — хәзер инде укчы дивизия солдаты — Таганрог шәһәре янында тагын сугышка керде. Тагын яраланды. Тагын госпиталь. Бу юлы ул тиз савыкты — ярасы авыр түгел иде.

Госпитальдән чыккач, аны 260 нчы дивизиянең 1030 полкына 76 мм лы орудие командиры итеп җибәрделәр.

Фашистларга каршы сугышка керүенә нәкъ бер ел дигәндә, Исламнар дивизиясе Сталинград янындагы Котлован станциясендә вагоннардан сугыш кораллары бушата иде.

1942 елның 17 сентябре. Алда тип-тигез дала. Иртәдән ук үзенең рәхимсез нурлары белән кыздыра башлаган кояш астында дивизия укчылары алгы сызыкка таба юнәлде. Укчылар артыннан атларга җигелгән 76 мм лы туплар сөйрәлә. Шул тупларның берсенә һәм аңа хезмәт күрсәтүче 6 кешегә Ислам командалык итә иде.

Өч-дүрт километрдагы алгы сызыкка югалтусыз барып җитү өчен төнне көтәргә кирәк булгандыр. Көтәргә ярамый, өстәмә көчләр кирәк. Өстә дошман самолетлары. Алар пулеметлардан сиптерәләр, бомбалар ташлыйлар. Сугышмыйча, дошманга каршы атмыйча, шулай юлда үлсәң, гарьлеге ни тора...

Дивизия төш вакытында билгеләнгән урынга килеп җитте һәм полк артиллериясе дә ут позицияләренә урнашты. Төн буе саклану чаралары күрелде, окоплар, траншеялар, пулемет, миномет һәм туп урыннары казылды. Иртәнгә укчылар да, тупчылар да җир куенына кереп урнашканнар иде инде.

18 сентябрьдә таң белән бергә немецларның артиллериясе дә телгә килде. Исламнар батареясы урнашкан урынга гитлерчыларның ун танкысы һәм йөзләп солдатларыннан, офицерларыннан торган пехотасы һөҗүм итте. Каты сугыш башланып китте.

Батарея туры наводка белән танкларга каршы ут ачты. Сталинград янындагы сугышның беренче көнендә үк Насыйбуллин Ислам командалык иткән орудие фашистларның ике танкысын юк итте. Әйе, Куйбышев шәһәре егете наводчик Николай Краюшкинга ике әйтеп торуның кирәге юк, ул командирның боерыгын күз карашыннан ук аңлап ала иде.

Бу яндырылган танкларның да ярдәме тиде: хәлиткеч һөҗүмгә күчкәнче, алар ориентир булып хезмәт итте.

Бер атна буена 1030 нчы укчы полк дошманның йөзләгән атакасын кире какты, бер метр да артка чигенмәде. Дөрес, югалтулар да күп булды. Исламнар батареясындагы 120 сугышчыдан бары 27 се исән калды. Ләкин һәр солдат ике, өч, биш кеше өчен сугышты, артка чигенү турында да, үлем турында да уйларга вакыт юк иде.

Җитмәсә тагы Сталинград тирәсендә ул елны сентябрь ае бик кызу булды. Эсседән тын кысыла. Тирә-юньдә чокырлар күп, ләкин аларның барысы да коры, су эчәсе килүгә чама юк. Тылдан да җитәрлек итеп китерү мөмкин түгел — безнең позицияләр көнен дә, төнен дә фашистлар күзәтүе астында. Бер йотым суга әллә нәрсә бирер идең.

Көнен-төнен дәвам иткән сугышларда үлгән кешеләрнең мәетләрен җыеп алырга да мөмкинлек юк иде — җир куеныннан чыксаң, үзең мәеткә әвереләсең. Шуңа күрә сугыш кырында пулялар гына түгел, зур яшел чебеннәр дә мыжгып тора. Сугышчылар арасында эчәк авырулары да таралды. Исәннәрнең рухы көчле булды. Күңелләрдә бары шул: үз гомереңне арзан бирмәскә!

Ислам исән калуына өмет багламады. Тик үлгәнче әни карчыкның итәгенә ятып, баштан үткәннәрне елый-елый бер сөйлисе иде — бар теләге шул булды аның. Әни карчык ерак, үзенә хат язарга да вакыт юк. Көтә торгандыр, беренче кат тәпи баскканны искә ала торгандыр...

Тудырып үстергән анаң һәм туган җир. Икесе дә йөрәкләрне сызлатып сагындыра, икесе дә чамасыз якын, кадерле... Никтер бу авыр вакытларда алар берләшеп, бер булып, берегеп күз алдына киләләр иде. Мөгаен, менә шундый авыр чакларда гына аны шулай хиңрәк, ныграк итеп аңлый торгансыңдыр... һәм шулай аңлау сәбәбедер инде: Ислам үз гомеренең иң авыр шушы чорында — һәр минут, һәр сәгать үлем көтеп йөргән бер вакытта — дошманның чираттагы атакасы башланыр алдыннан партиягә керергә гариза бирде...

* * *

...Ул көннәрдән соң менә чирек гасыр вакыт узып китте. Әйе, вакыт уза тора, аның үлгәннәрдә дә, калганнарда да эше юк. Тирән һәм куәтле агым ул вакыт дигән нәрсә, аңа каршы һич йөзә алмыйсың. Ләкин бу куәтле агымның тизлеген арттырырга мөмкин бит. Вакыт агымын тизләтүгә сәләте булган кеше — зур кеше, батыр кеше. Ә сугышның һәр сәгате, һәр көне күп вакытта елларга тиң иде. Шушы елларга тиң сәгатьләр, көннәр, хәтта минутлар ничәмә-ничә кешеләрнең, типсә тимер өзәрлек ирләрнең, сылу хатын-кызларның гомерләрен йотты. Бер Вахитов исемендәге колхозның үзәге булган Чирмешән авылында гына да 150 дән артык кеше һәлак булды. Бакырчыдан, Багыштан, Аю Көйдергәннән тагын күпме кеше кайтмады. Барысы 500 дән ашып китә. Бу бер колхоздан гына. Алар бит барысы да үз гомерләре бәрабәренә йөзләгән кешеләрнең гомерләрен саклап калу, тормышның матур дәвамын тәэмин итү өчен һәлак булдылар.

Әйе, вакыт агымы хәзер инде бу авыр көннәрнең күп хатирәләрен хәтердән юган, ләкин һәр минут саен үлем көтеп, туган җирнең һәр адымын азат итү өчен корбаннар биреп алга омтылу көннәрен, йортсыз-җирсез, атасыз-анасыз калган ятимнәрнең күз яшьләрен онытып буламыни!!

Сугыш беткәнгә дә инде егерме елдан узып китте. Ләкин юеш окопларда дошман снарядлары, миналары яуганда үлем көтеп ятулар Исламның төшенә бик еш керә. Салкын тиргә батып уянгач, янындагы Сөгъдәсен күреп кенә тынычлана ул. Сугышта түгел, үз өендә, хатыны, балалары янында булуына шатланып бетә алмый. Әмма йокы кача. Сугышта күргәннәр бер-бер артлы кабат күз алдыннан уза башлый...

Ике ай буена, җир куенына ышыкланып, Исламнар полкы дошман атакаларын кире какты. Ниһаять, частьларны тулыландырдылар. Төн буе алар батареясы урнашкан тирәгә төрле калибрдагы туплар, гвардия минометлары тупланды. 19 ноябрьга каршы кичтән батарея командиры Сталинград фронтының Хәрби Советы мөрәҗәгатен укыды.

«Сугыш бара. Без фашист тоткынлыгында интегүче туганнарыбызны азат итәр өчен сугышабыз. Бөек совет халкының язмышы безнең кулларда, иптәшләр», — дигән иде анда.

Ниһаять, һөҗүм!

Менә таң беленде. Сирәк-мирәк кенә кар төшкәли. Гадәттәгечә безелдәп дошман ягыннан пулялар оча. Кинәт, дөньяның асты-өскә килгәндәй булып, тирә-якка көчле гөрелте авазы яңгырады. Баш өстеннән, утлы сызыклар калдырып, «Катюша» миналары очты. Артиллерия әзерлеге ике сәгатьтән артыграк дәвам итте. Мондый дәһшәтле көчне күргәне юк иде әле Исламның. Аның расчеты да, ару-талуны белмичә, дошман өстенә бер-бер артлы снарядлар яудырды. Танклар, алар артыннан пехота атакага ташланды...

— Дошманга үлем!..

23 ноябрьда Көньяк-Көнбатыш һәм Сталинград фронты гаскәрләре, Калач шәһәреннән көньяк-көнбатыштарак гитлерчыларның 330 мең кешелек гаскәрләрен — барлыгы 22 дивизиясен, 4 танк армиясен камалышта калдырып, бер-берсе белән кушылдылар.

Ләкин камалышта калган фашистлар теш-тырнаклары белән каршылык күрсәтүләрен дәвам иттерделәр. Аларга каршы каты сугышлар 1943 елның 2 февраленә хәтле дәвам итте. Сталинград сугышы безнең бөек җиңү белән тәмамланды, исән калган фашист солдатлары һәм офицерлары бирелделәр.

Менә әсирләр колоннасы. Башларында пилотка, арык битләрендә җирән сакаллары тырпайган. Аякларына одеал чорнаганнар. Кеше төсе дә калмаган үзләрендә, бакчага куйган карачкы диярсең...

260 укчы дивизияне, ял иткәннән һәм тулыландырганнан соң, командующие генерал-лейтенант И. И. Федюнинский булган 11 армиягә, Брянск фронтына китерделәр.

Июль ае. Җәй уртасы. Берничә көн дәвам иткән яңгырдан соң гаҗәеп эссе көннәр башланды. Яңгырдан соңгы мондый матур көннәрне Кайбыч тирәләрендә бик мактый торганнар иде: җир күперә дип. Ләкин хәзер анда да инде урак өсте. Файдасымы, зарарымы күбрәк икән!

Рәшә. Дулкын-дулкын булып җирдән су парлары күтәрелә. Шуңадыр инде, гаҗәеп бөркү, сулыш алырга да авыр...

Юл ниндидер бер авыл аша үтә. Авыл диярлеге дә юк, барлык йорт-каралтылар янып көлгә әверелгән. Мичләр генә тырпаеп калган. Хәтта миче дә җимерелгән бер йорт нигезендә, әниләренең үле гәүдәсе янында өч яр баланың елап торуы Исламның игътибарын үзенә тартты. Олысына күп булса ун-унбер яшьтер. Ислам алар янына килде, бердәнбер калган шикәр шакмагын бүләргә дип тирә-якка карангалаганда, Краюшкин белән Одинцов килеп җиттеләр. Өчесенә өч шакмак шикәр, юату сүзләре, ипи балаларга, әлбәттә, шатлык китермәде. Ләкин мөлдерәмә күз яше тулган олысы Исламны килеп кочаклады. Малайның ябык битләрен, зур булып ачылган күзләрен үзенең кипшенгән, ярылган иреннәре белән шундый үз итеп, яратып үпте Ислам, бала аның муенына тагы да катырак сарылды.

— Без ашыгабыз, — диде Ислам. — Хәзер апаларыгыз килеп җитәр.

Ул баланы урынына утыртты, кипшенгән иренгә тамган тозлы күз яше әчесе шактый вакыт йөрәген телгәләде...

Днепрның бер тармагы булган Сож елгасын 1030 нчы укчы полк беренчеләрдән булып кичәргә приказ алды.

Сож елгасының көнбатыш ярын немецлар бик көчле ныгытканнар. Елганың арьягында Гомель шәһәре... Бу шәһәрне саклау өчен гитлерчылар бөтен чараларны күргәннәр. Шәһәрнең читләрен, ул тирәдәге авылларны ныклы терәк пунктларына әверелдергәннәр. Бу ныгытмалар турыдан-туры Гитлер кушуы буенча ясалган. «Көнчыгыш вал» дип исемләнгән бу оборона сызыгы Днепрның урта агымыннан башлап Нарва елгасына кадәр сузылырга тиеш булган.

Гомель шәһәрен немецлар 1941 елда ук Мәскәү һәм Киевка һөҗүм әзерләүдә плацдарм итеп санаганнар.

1943 елда исә бу шәһәрнең гитлерчылар оборонасы өчен әһәмияте гаять зур иде. Гомель шәһәре — тимер юлларның да, таш юлларның да үзәге. Сож елгасының уң як яры да каршы тору өчен уңай.

1030 нчы укчы полк командиры Охонцев Насыйбуллин расчетының нинди хәлдә дә каушап калмаячагын, узган сугышлар тәҗрибәсеннән чыгып, яхшы белә иде инде. Иң беренчеләрдән булып, аргы якта плацдарм тоту өчен, Ислам расчеты Сожны кичәргә тиеш иде.

Салны расчет үзе ясады. Орудие дә, җитәрлек кадәр снарядлар да салга төялгән. Расчет ишкәкләргә тотынды.

Елга өсте снаряд һәм мина төшеп ярылудан кайнап торса да, Насыйбуллин расчеты аргы якка исән-сау чыгып җитте һәм, уңайлы урыннар табып, позиция әзерләргә кереште. Ләкин эшне төгәлләргә мөмкинлек булмады. Гитлерчылар бу кечкенә плацдармга каршы атакага ташландылар.

Ярый әле снарядларны җитәрлек алганнар иде, төн буе, картечь белән атып, дистәгә якын дошман атакасын кире кайтардылар. Насыйбуллин расчеты урнашкан позиция каршында бер төн эчендә дошманның 52 солдаты һәм офицеры теге дөньяга олакты.

Иртә белән сугышлар яңадан башланды. Плацдарм көчәйтелгән иде инде. Дошман пехотасы танкларга ышыкланып һөҗүм итте. Ләкин, берничә үлем машинасын һәм күп кенә солдатларын сугыш кырында калдырып, кире чигенергә мәҗбүр булды.

* * *

Әйе, солдат хезмәте — авыр хезмәт, бигрәк тә сугыш вакытында. Ул батырлык турында да уйламый, үлем турында да уйламый, чөнки батырлык та, үлем дә — сугышта бик гадәти күренеш. Әгәр батырлык өчен мактыйлар, хөкүмәт бүләге бирәләр икән, — солдатның гаҗәпләнүе бик табигый. Ул мактау, бүләк алу өчен сугышамыни! Ул үз бурычын үти!

Бөдрә чәчле, мөлаем матур чырайлы, тыйнак татар егете коммунист Ислам Насыйбуллинның батырлык турында да, дан турында да, бүләк турында да уена китергәне булмады. Ул — бала чактан ук үзенә кушылган эшне җиренә җиткереп үтәргә күнеккән авыл егете. Менә сугышта да ул башкача булдыра алмый. Бүтәннәр күкрәкләре белән утка, тимергә каршы торганда, ул алардан калып яшеренсенмени! Күкрәгендә йөрәге типкәндә, ул андый хурлыкка төшмәс!

Ислам инде күп сугышты, һәр минутта аны үлем куркынычы сагалый. Ләкин ул исән. Кечкенә генә булса да ул һаман командир. Кул астындагы кешеләр аңа хөрмәт белән генә түгел, якын итеп карыйлар.

Ләкин сугышка күнегеп буламыни! Кешегә төбәп ату, кеше кешене үтерү — гайре табигый нәрсә бит ул. Немец дисәң дә — фашист булып тумаган инде ул. Ничек итеп кешедә ерткыч хисләре тәрбияләп була икән! Ислам болар турында күп уйланды. Ләкин аларны күп үтерүе өчен мактаганда, бүләкләр биргәндә, һич тә уңайсызланмады. Алар бит аны, аның әти-әнисен, туганнарын үтерер өчен, йорт-җирен яндырыр өчен, халкын кол итәр өчен килгәннәр. Бер снаряд мең булып төшсен аның башына!..

...Сталинград та, Курск, Орел далалары да күптән артта калды. Украина һәм Белоруссия җирләре дә инде азат ителеп бетеп килә. 1944 елның язы. Алда зур тимер юл үзәге — Ковель шәһәре.

Исламнар батареясы һаман шул ук 1030 нчы укчы полк составында ике ел эчендә каты сугышлар белән ике мең километрга якын юл узды. Немец җиренә якынайган саен, юлның һәр үлчәм җире авырая, күбрәк корбаннар сорый иде. Әмма, аның карашы, солдатның үз көченә карата ышанычы зурая, дошманны тизрәк җиңеп, туган илләренә кайту омтылышы артканнан-арта бара иде.

Командование приказы буенча 1030 нчы укчы полк Ковель шәһәренә беренче булып бәреп керергә тиеш иде.

Ковель шәһәре уннарча километрга сузылган сазлыклар эчендә утыра. Өстәвенә язгы ташу вакыты. Билдән су ерып, Исламнар батареясы һәм бер батальон пехота шәһәр читенә бәреп керде. Каты сугышлардан соң шәһәрнең ике кварталы азат ителде. Исламнар дошман фронтын 200 метр арада өзеп, 200 метрлап алга уздылар. Яулап алынган шәһәр эчендәге бу плацдармны, төп көчләр килеп җиткәнче, ничек тә кулдан җибәрмәскә кирәк иде.

Сугышлар көнен дә, төнен дә дәвам итте. Дошман, ничек кенә булмасын, фронтны өзеп, үз позицияләренә үтеп кергән безнең сугышчыларны камалышта калдырырга, полкның бүтән частьларын шәһәргә кертмәскә тырыша иде.

Ислам расчетына полкның шәһәргә бәреп кергән көчләрен флангтан дошман танкларыннан саклау бурычы куелды.

Дошман танклары флангка сазлык аша үткән таш юл белән генә бәреп керә ала иде. Ислам, укчылар позициясеннән 50 метрлап алдарак уңайлы урын сайлап, юлның һәр метрын ут астында тотарлык итеп орудиене шунда урнаштырырга булды.

Төн буе, 150 метрлап кына алда торган гитлерчыларга сиздермичә, орудие өчен ныгытылган ут позициясе әзерләнде.

Кояш чыгып кына килә иде әле. Күзәтүдә торган Иванов ял итәргә яткан тупчыларны тревога белән күтәрде. 150 дән артык фашист солдаты, 7 танкка ышыкланып, таш юлдан безнең флангка һөҗүмгә килә иде. Ислам броня яндыргыч снаряд белән тупны корырга әмер бирде. Наводчик Краюшкин тупны җентекләп төзәде.

— Ут!

Беренче снарядтан ук дошман танкларының берсеннән кара төтен күтәрелде. Фашистлар Исламнар расчетының кайдан атканын абайлап өлгергәндә, аларның өч танкысы дөрләп яна иде инде.

Ислам расчеты өч яклап ут эчендә калды: аларга каршы дошманнар пулеметтан да, минометтан да, орудиедән дә аталар иде. Ләкин чигенергә ярамый. Бөтен полкның язмышы алар кулында, үләргә дә хаклары юк: әгәр юлдан дошманны үткәрсәләр, бөтен полк чолганышта калачак.

Расчетта 4 кенә тупчы калды. Иванов үлде, Трудков каты яраланды. Менә якында гына эре калибрлы снаряд шартлады, орудиегә зыян килмәде, Исламның аркасын

снаряд кыйпылчыгы сыдырып узды. Ләкин яраны бәйләргә вакыт юк, танклар һаман килә иде. Аларга каршы Ислам расчеты бер-бер артлы снаряд яудырды. Гитлерчыларның тагын ике танкысы сафтан чыкты.

Ислам як-ягына әйләнеп караган иде, пулеметтан атып ятучы полк командиры Охонцевны күрде, йөгереп аның янына барды.

— Иптәш полковник, сез нишләп биредә!

— Штаб камалыш хәлендә. Дошманны юлдан уздырырга ярамый, — диде полк командиры.

Штабның барлык хезмәткәрләре ут сызыгында иде: кайсы автоматтан, кайсы пулеметтан, кайсы пистолеттан якын ук килергә өлгергән фашистларны кыралар. Исламның ярасын тиз генә бәйләделәр.

Сугыш өч сәгатьләп дәвам итте. Ниһаять, фашистларның исән калганнары үз позицияләренә чигенделәр...

Беренче май. 1030 нчы полк сугышчылары бәйрәмне ут эчендә каршыладылар. Төп көчләр һаман килеп җитмәгән иде әле.

Немецларның 30 апрель иртәсендә башланган контрһөҗүмнәре менә инде тәүлектән артык дәвам итә. Дошманның ничә атакасы инде кире кайтарылды, ә ул һаман полкка каршы яңа көчләрен ташлый.

Ислам расчеты бер җимерек йортның подвалына урнашкан. Беренче май көнне фашистлар һөҗүмне тагын да көчәйттеләр. Исламга расчетны икегә бүләргә туры килде: наводчик Краюшкин, коручы Скоба һәм үзе лафетта калды, өч тупчыны автоматлар белән якынрак үрмәләгән гитлерчыларны юк итәргә җибәрде.

Исламнар туры наводка белән дошман өстенә туктаусыз ут яудырдылар, арулар да, яралар да онытылды. Хәтта тирә-якта сызгырган пуляларга да, снарядлар шартлавына да игътибар итмәделәр. Ә ул көнне бер алар урнашкан йортка гына да төрле калибрдагы 28 снаряд тиеп шартлады.

Хәл торган саен кискенләште. Скоба һәм Одинцов каты яраланды. Кешеләр сорап, комбатка шалтырату да мөмкин түгел, телефон чыбыклары өзек иде. Алгы сызыктан, утка чыдый алмыйча, кайбер сугышчылар артка йөгерә башладылар. Ислам автоматын тотып, аларга каршы чыкты, сугышчыларны үз позицияләренә кире кайтырга мәҗбүр итте. Ә кайберләрен расчетка һөҗүм итүче дошманнарга каршы оборонага куйды. Тылга китеп баручы бер поварга да эш тапты, снаряд ташып торырга кушты.

Ике көн эчендә Исламнар полкы участогында дошман бик күп солдатларын һәм офицерларын югалтты. Ниһаять, полкка ярдәмгә безнең гаскәрләрнең бүтән частьлары да килеп җитте. Ковель шәһәре азат ителде.

Бу сугышта күрсәткән батырлыкларының билгесе булып Ислам күкрәгендәге орден һәм медальләргә Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены өстәлде...

* * *

Илебезнең вакытлыча фашист оккупациялəгән җирләрен азат итеп, Совет Армиясе Көнчыгыш Европа илләренә аяк басканда, Исламның күкрәген ике «Батырлык өчен» медале, Кызыл Йолдыз, Беренче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары бизи иде.

Ә менә солдат данының, солдат батырлыгының иң югары дәрәҗәсен билгели торган өч Дан ордены фашист тоткынлыгыннан Польша халкын азат итү, Көнчыгыш Померааниядә, ерткычның үз өнендә, Эльба ярында, Берлинда күрсәткән батырлыкларының истәлеге.

Өч зур йолдыз. Берсе көмеш йолдыз — III дәрәҗә Дан ордены; икенчесе алтын йөгертелгән көмеш йолдыз — II дәрәҗә; өченчесе саф алтын йолдыз — бусы — иң югары, беренче дәрәҗә Дан ордены. Ислам әле дә хәтерли: Дан ордены статусында бу орденнарның солдатка, сержантка, старшинага — алар офицерга да, генералга да, адмиралга да, маршалга да бирелмиләр — гаскәрләребезнең сугышта уңышка ирешүенә ярдәм итәрлек зур шәхси каһарманлык үрнәге күрсәтүе өчен бирелүе турында әйтелгән.

Насыйбуллин расчетының Польша һәм немец җирләрендә барган сугышларда күрсәткән батырлыклары, хәлиткеч, киеренке моментлары күп булды.

1030 нчы полк сугышчылары 1945 елның 15 январенда пуля һәм снаряд яңгыры астында Висла елгасын кичтеләр, Польшаның башкаласы Варшаваны штурмладылар, туктalышсыз сугышлар белән 500 километр юл үтеп, немецның үз җиренә килеп чыктылар. Немец җиренең һәр метры каршы тору өчен җайлаштырылган, һәр торак пункты ныгытылган районга әверелдерелгән иде. Немец җирендә алга бару тизлеге шактый кимеде. Фашист генералы Генрих Кох: «Без Пруссия җиренең бер карышын да русларга бирмәячәкбез, без ул җиргә ябышып ятачакбыз», — дип юкка гына әйтмәгән иде шул.

Гитлерчылар, Көнчыгыш Померániядә безнең гаскәрләргә нык каршылык күрсәтеп, вакыт отарга һәм Америка магнатлары белән сепарат солых төзергә, аннары барлык гаскәрләрен Совет Армиясенә каршы юнәлдерергә тырыштылар. Ләкин аның бу тырышулары барып чыкмады.

Хәзер бернинди ныгытмалар да, бернинди көч тә совет гаскәрләренең тарихта булмаган куәтле омтылышын туктата алмый иде инде.

1945 елның февралендә Исламнар полкы Померániянең әһәмиятле коммуникация үзәге һәм куәтле ныгытмасы булган Шнайдемюль шәһәренә бәреп керде. Артиллериягә эш күп иде. 1933 елда ук корылган «Померания валы» тоташ озакка чыдамлы ут корылмаларыннан, тимер-бетон ныгытмалардан, танкка һәм пехотага каршы җайланмалардан тора иде. Җитмәсә, атналар буена сузылган яңгырлардан соң, исәпсез күп елгалар, инешләр, күлләр ярларыннан чыкты, фашист ныгытмаларына килү юлларыннан үтү дә бик кыенлашты. Шнайдемюль шәһәре бу ныгытмаларның үзәге булып, аның тирәсендә озакка чыдамлы ут ноктaларының, танкка һәм пехотага каршы тору җайланмаларының исәбе-хисабы юк иде.

Дошман күп мәртәбәләр контратакага күтәрелсә дә, 1030 нчы укчы полк сугышчылары 13 февральдә, гитлерчыларның ныгытмаларын үтеп, ут нокталарын юк итә-итә, беренчеләрдән булып, шәһәрнең кырыена ук килеп җиттеләр. Сугыш кызганнан-кызды. Шнайдемюль өчен сугышларда гына дошманның берничә озакка чыдамлы ут ноктасын җимергән Насыйбуллин расчеты, үз батареялары составында, аэродром янына килеп җитте. Аэродромда ыгы-зыгы. Фашистлар камалышта калган шәһәрдән самолетларга төялеп качарга тырыштылар. Ислам, расчетка уңайлы позиция сайлап, очарга торган самолетларга туры наводкадан ут ачарга боерды. Ике атуда ике самолет күккә очты. Ниһаять, аэродром безнең кулда... Аэродромны яулап алу гитлерчыларның Шнайдемюльдә камалышта калган гаять көчле гарнизоны өчен зур кыенлык тудырды. Шулай да аның исән калган көчләре төньяк-көнбатыш яктан шәһәрне калдырып чигенергә җай таптылар. Ләкин аларның бер өлеше генә гитлерчыларның төп көчләре белән кушыла алды.

Апрель ахырында Беренче Белоруссия фронты гаскәрләре төньяктан, Беренче Украина фронты гаскәрләре көньяктан фашист ерткычларының өнен — Берлинны тулысынча камап алуны тәгәлләделәр.

Одерны кичкәндә һәм Бранденбург шәһәре өчен барган сугышларда шактый сирәгәйгән 1030 нчы полк сугышчыларына моннан соң көнбатышка таба һөҗүмне дәвам иттерергә приказ булды.

7 май көне иде. Эльба елгасы буендагы ниндидер бер торак пункты өчен сугыштылар алар. Төштән соң батарея бу торак пунктыннан көнбатыштарак бер калкулык өстенә тупларны урнаштырды.

Еракта Эльба елгасы сузылып киткән. Аның һәр ике ягы үзәнлек. Бу якындагы уйсулык җирләр Зөя буйларындагы болыннарны хәтерләтә. Уң якта кечкенә генә урман. Машиналарга төялгән гитлерчыларның шул урманга җыелулары уч төбендәге кебек күренеп тора. Бу тамашаны командирлар да, солдатлар да хәзер инде яшерен мичә күзәтәләр — каршыга пулялар да, снарядлар да очмый.

— Соңгы һөҗүмгә!

Сугышчылар «ура!» кычкырып таудан түбән алга ыргылдылар.

Немецлар бөтенләй диярлек каршылык күрсәтмәде, күбесе кулларын күтәрде, бер өлеше, ни туры килсә шуңа ябышып, Эльбага ташланды. Елганың аргы ягында — Америка гаскәрләре, бу якта — безнекеләр. «Аптыраган үрдәк арты белән суга чума», — диләр. Нәкъ шул инде бу. Безнең сугышчылар, һөҗүм ашкынуына бирелеп,

алар өстенә автоматтан сиптерергә керештеләр. Ләкин полк штабы начальнигы майор Хвалин утны туктатырга приказ бирде...

Көн кичкә авышкан иде инде. Кояш каршы яктан безнең сугышчылар өстенә үзенең җылы нурларын сибә, әйтерсең, ул бүгенге көн белән канәгать, әйтерсең, ул сөенә. Алда Эльба елгасы көзге кебек ялтырап ята, җилнең әсәре дә юк. Тоташ гөрелте, атыш тавышларына күнеккән колакка кичке тынлык ничектер ят төсле.

9 май көнне, бик күп газаплар чигүнең ахыргы көнендә, Исламның күзләре мөлдерәмә яшь белән тулды. Иптәшләренә Ислам 1941 елда термит снаряды утында пешеп, күз нервларына зыян килүдән, дип аңлатты бу күз яшьләрен. Бу көнне аңа солдат батырлыгының, солдат данының иң зур билгесе Беренче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнүе турында әйттеләр. Одерны кичү өченме, Бранденбург сугышлары өченме — Ислам бу бүләкнең ни өчен икәнлеген хәзер дә тәгаен әйтә алмый. 2500 тәүлектән артык дәвам иткән солдат хезмәтенең кайсы көннәрен, кайсы сәгатьләрен Ватан иң кыйммәтле, иң кирәкле дип санагандыр, ул белми. Ислам аларның һәрберсен алгы сызыкта уздырды, һәрберсен Ватан өчен, халыкларның бәйсезлеге өчен багышлады.

* * *

...Сөгъдә кибетен тизрәк ябарга ашыкты. Аны да, Исламны да пионерлар Чирмешән урта мәктәбенә чакырганнар иде. Улының да, кызының да класс җитәкчеләре түгел, юк, пионерлар отряды, эзтабарлар чакырды аларны.

Ислам инде кыш көне мәктәптә берничә мәртәбә булды. Балаларга сугыш турында да, үзенең баштан үткәннәре турында да сөйләде. Эзтабарлар белән тәмам дуслашып китте. Менә бүген тагын чакырдылар. Ислам, башта фермаларны йөреп чыгарга исәпләп, иртән үк киткән иде.

Өлгерим дип бик ашыкты Сөгъдә, Багыштан Чирмешәнгә килеп җиткәнче, тәмам тирләп чыкты. Ә мәктәптә тып-тын иде.

— Барысы җыелышып клуб янына киттеләр,— диде җыештыручы апа.

Мулланур Вахитов исемендәге колхоз идарәсе һәм Чирмешән авыл Советы урнашкан бина артында, клуб каршында зур гына бакча бар. Анда өрәңгеләр, сирень агачлары үсә. Шул бакчаның нәкъ урта бер җирендә очына йолдыз куелган таш һәйкәл тора. Постаментка: «Илебезнең азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен һәлак булган геройларга мәңгелек дан!» дип алтын хәрефләр белән язылган. Аны колхозчылар Бөек Ватан сугышыннан кайтмый калган якташлары хөрмәтенә куйганнар. Димәк, бүген пионерлар слеты шунда үткәрелә.

Һәйкәл тирәсенә тезелгән пионерлар арасыннан Сөгъдә алгарак узды. Укучы формасы кигән кечкенә генә бер кыз Исламның муенына кызыл галстук бәйли иде.

— Безнең кадерле якташыбыз һәм дустыбыз Ислам абый, — дип башлады сүзен ул кыз, — без сезнең тырыш колхозчы, игътибарлы партия җитәкчесе, авыл Советы депутаты, колхоз председателе урынбасары икәнлегегезне күптән белә идек. Ләкин сугыш батыры икәнлегегезне безнең эзтабарлар районның хәрби комиссариаты аша гына белә алды. Сезнең Бөек Ватан сугышында солдат данының тулы кавалеры булуыгыз, башка күп орден-медальләр белән бүләкләнүегез, безнең бәхетле бала чагыбыз өчен зур батырлыклар күрсәтүегез белән горурланабыз. Сезне, Ислам абый, безнең оешманың почетлы пионеры итеп кабул итәбез. Шушы һәйкәл янында без, яшь ленинчылар, хезмәттә, әгәр империалистлар коммунизм төзүче илебезгә һөҗүм итсә, сугышта да Сезнең, әтиләребезнең һәм абыйларыбызның сугышчан батырлыкларын дәвам итәргә сүз бирәбез...

Сөгъдә Исламга карады. Иренең йөзе җитди һәм кырыс иде. Ул белә: Ислам бик нык дулкынланган вакытларда, барлык ихтыяр көчен җыеп, шулай кырыс, җитди булырга тырыша. Аннары озак вакытлар нәрсәдер турында уйланып, дәшми йөри. Ләкин бу юлы ул кинәт пионерлар сафына күз ташлады һәм көр тавыш белән:

— Пионерлар, Ленин эше өчен көрәшкә һәрвакыт әзер булыгыз! — диде.

— Һәрвакыт әзер, — дип бердәм җавап бирделәр пионерлар.

Солдат данына, ир намусына тормышта да, хезмәттә дә тап төшермәгән Исламның хәрбиләрчә төз басып торган гәүдәсенә, язгы җилдә җилфердәгән кызыл галстугына, инде яртылаш чал кергән чәчләренә, каядыр еракка төбәлгән зәңгәр күзләренә карап тагын бер сокланды Сөгъдә...

*Муса Җәлил*

## Кошчык

Чәнечкеле тимер чыбык белән
Уратылган безнең йортыбыз.
Көне буе шунда казынабыз,
Әйтерсең лә, тирес корты без.
Кояш чыга коймa аръягында,
Күрше кырлар нурга коена.
Тик нигәдер, аның нуры безгә
Тими үткән төсле тоела.
Ерак түгел урман, кыр...
Кемнеңдер
Ишетелә чалгы кайравы.
Кичә шуннан бер кош очып килеп,
Шул коймага кунып сайрады.
Чакырсам да, кошчык,
Син бу йортка
Үзең теләп очып кермәссең.
Керә күрмә, безнең, кан-яшь йотып,
Интеккәнне үзең күргәнсең.
Сайра безгә шушы нәләт төшкән
Коймa аша гына булса да,
Шунсы да бит безгә зур юаныч,
Җырларыңнан күңел тулса да.
Син очарсың бәлки минем илгә,
Син иркле, җитез канатлы.
Тик әйт, кошчык,
Синең минем янга
Бу килүең соңгы кабатмы!
Соңгы кабат булса, тыңла,
кошчык,
Соң теләген мәгърур җанымның.
Оч син илгә нәфрәт һәм мәхәббәт
Җыры булып тоткын шагыйрьнең.
Ук шикелле үткен канатыңнан,
Таң шикелле якты җырыңнан
Танып сине халкым,
— «Бу, дип, аның
Соңгы җыры көрәш кырыннан.
Чәнечкеле чыбык бәйләсә дә,
Дип, шагыйрьнең аяк-кулларын,
Бер көч тә юк җирдә богауларлык
Аның кайнар йөрәк моңнарын».
Оч син, кошчык,
көчле җырым булып,
Шушы сиңа соңгы теләгем.
Тәнем калсын монда,
(Нәрсә ул тән!)
Барсын илгә минем йөрәгем.

1942.

*Саҗидә Сөләйманова*

# ҖИР-СУ

## *Поэма*

Өй янында ап-ак казлар йөрер,
Тәрәз төбе тулы гөл булыр.
Урадының суын чыгу белән
Күпер каршысында өй булыр.

Күпме яңа йортлар бу урамда,
Такта, калай, шифер түбәле...
Яшел мүкләр кунган шул өйдән дә
Сөйкемлерәк бер өй юк әле.

Әллә каян күренеп, балкып тора, —
Тәрәзәләр зәңгәр буяулы.
Кына чәчәкләре арасыннан
Күзгә чалынып калды ал яулык.

Аллы-гөлле тәрәзләрен сагынып,
Бала чакка кайттым әйләнеп.
Ул чагында туган йортка кайту,
Җәе-кышы — тоташ бәйрәмем:

Кунакларга капка ачык була,
Алдан чапсаң — киртә арасы.
Әллә каян күреп, каршы чыга
Нәнәй — әнкәемнең анасы.

Мәк чәчәкле алъяпкычын япкан,
Ал яулыгын сузып ябынган.
Алъяпкычы белән ал яулыгы
Ямь бирә күк бөтен авылга.

Нәнәй.
    Әллә инде үз кызына
Назлау тимәгәнгә үскәндә,
Безгә — оныкларга ана хисе
Икеләтә артык өстәлгән.

Кунак ашы: балан бәлешләре,
Җиләк кагы — бар да җир сые.
Нәнәй булып күз алдына килә
Урадының урман,
            җир,
                суы.

Җәй көнендә бәбкә казлар белән
Безне дә ул Бүә буеннан
Үзе эзләп алып кайта иде
Йоклатырга җылы куенында.

Чалгы тотып үзе печән чаба.
Бер карасаң, ура урагын.
Урадының болын-басуларын
Нәнәй белән бергә урадым.

Бөрлегәнле Бүә буйларында,
Карлыганлы кара урманда
Сузып кына озын җыр җырлавы
Серләр булып уйга уралган.

Шул йомгакны менә сүтәмен дә,
Бала чакка кабат урыймын.
Җир-суларга гашыйк нәнәемнең
Җир түрендә инде урыны.

Күпер башында йорт һаман шулай,
Түбәләре яшел бәрхетле.
Капка ябык. Җил кермәскә микән,
Әллә инде
Чыгармаска кергән бәхетне.

●

Бу нарат йорт бөтен түбән очка
Шаулап торды элек.
Җиде бала үстерде бу оя, —
Ике кыз, биш егет.

Карт әткәбез дөнья куйган елны
Хәтәр ачлык булган.
Ата төсе булып төпчек улы —
Миңнулласы туган.

Газизә апа белән бәлкабый
Игезәкләр төсле,
гел бергәләр,
Артларыннан калмый
Мин дә шунда үстем.

Безнең әткәй — егермебишмеңче,
Артель төзеп йөрде.
Балдыз һәм кайнишләр җизнәләрен
Ата сыман күрде.

Бердәм гаилә яңа йорт тергезде.
Йортның нигезенә
Өткәй чүкеч, әнкәй урак салды
Дуслык билгесенә.

Ике яклы йортка — уртак түбә, —
Бәрәкәт — берлектә.
Хәл җитмәде бераз кече якка,
Түшәмгә, өрлеккә.

Анысын атадылар бәлкабыйга,
Өйдә, җае чыгар.
Солдатка чаклы да Миңнулланың
Биш-алты елы бар.

Аннан ликбез,
курслар да туйлар, —
Барын кара, өлгерт.
Бергә сирәк җыела торган булды
Ике кыз, биш егет.

Җыелганда әткәй башлап җырлый:
«Һаваларда йолдыз...»
Һаваларга җырны күтәрүче —
Газизәкәй балдыз.

Өйдәгеләр бердәм кушылалар:
«Шаулый кара урман...»
Иң ахырдан һәр чактагы сыман
Яңгырый «Кузгал, уян...»

Авыл сәхнәсендә ул чагында
Әткәй, әнкәй,
балдыз.
Кайнишләр дә шунда.
Нәнәй белән
Без икәү генә ялгыз.

Нәнәй көйләп калын китап укый,
Өйдә кеше юкта.
Ара-тирә сүз дә кушып куя:
— Йокла, балам, йокла.

Һавада бер йолдыз күзен кыса,
Мин йокыга талам.
Әнкәй кайтып, урам тәрәзәдән
Ак пәрдәне ала.

Төшенәмен кинәт, йолдызның ник
Миңа күз кысканын.
Торып, киез итек элдерәм дә
Чабам аргы очка мин.

Урам буйлап агыла моңлы тавыш:
— Һаваларда йолдыз...
Сылу җырчы миңа күптән таныш —
Газизәкәй балдыз.

Клуб шыгрым. Мине кемдер алып
Бирә алгы рәткә.
Ә сәхнәдә кызылармеецлар
Һәм комиссар әткәй.

Ак яулыклы сестра — әнкәй кирә, —
Кемдер авыр хәлдә.
Ә мин әйтеп салам: «Башында бит
Яулык түгел, пәрдә!»

Атышлардан сәхнә җырга күчә:
«Шаулый кара урман...»
Алкышлардан соң да бетми кичә,
Яңгырый «Кузгал, уян...»

Егет, кызлар безне озата бара,
«Абзыкай да җизни...»
Комиссарның күкрәгендә мин шул,
Йоклыйм берни сизми.

---

Мин уяндым көчле бер шартлаудан,
Бар да тора катып.
Башым һаман әткәй кулбашында,
Мич кирпече ватык.

Җил сызгыра. Агарынган нәнәй
Ватык тәрәзәгә
Каплана да, бер ишарә ясый:
«Пәрдә юк бит, пәрдә...»

Җинаятьче тотылмады.
Соңрак
Әйткән имеш үзе:
«Туры аталмадым,
күкрәгендә
Йоклый иде кызы.»

Дөнья — куласа ул, бер әйләнеп басар...
Ачу йөрткән дошман.
Афәт булса, агу чәчкән елан,
Иген уңса — куштан.

●

Әткәй.
Кайда кирәк эшче кулы,
Шунда булды аның урыны.
Таянычы гына түгел иде, —
Намусы да кардәш-ыруның.

Бер колхоздан икенчегә күчте,
Күтәрделәр аннан үзәккә.
Кайда өзек, аны ялгый белә,
Артык бөгелгәнне төзәтә.

Җимеш-куак язын утыртабыз,
Кузгалабыз, алмый җимешен, —
«Коммунистның булмый шәхси милке,
Булмый аның шәхси тормышы».

Килгән җирдә торыр куыш була
Кисмәсәк тә өйгә буралык...
Кая гына китмик, без, балалар,
Урадыда җәен уралдык.

Уелып-боегып көтә Бүә буе.
Каенлыкта кичке уеннар...
Җырлы урамнарның төнге моңы
Күңелемә тирән уелган.

«Төн буена нинди йөрү...»
Нәнәй
Сукрангалап ача ишекне.
Әллә егетләрнең өй турыннан
Җырлап узуларын ишетте:

«Минем сүнмәс мәхәббәтем булыр,
Һаваларда янса бер йолдыз...
Газизәкәй балдыз, елама,
Калдырмам ялгыз».

Ә егетләр бер көн армиягә
Китеп барды шулай җырлашып...
«Сәфәр ерак, сызламасын йөрәк,
Озатмагыз безне елашып».

---

Ил чигенә китте Миңнулла да,
Хат язды өзлексез.
Ә кече өй аны көтеп калды
Түшәмсез, өрлексез.

Нигез булса, өе бер очланыр,
Өч ел үтәр-китәр.
Миңнулладан көн дә хәбәр алып,
Кояш кайта иртән.

Иртән кайта, кичен тагын бата,
Эңгер-меңгер ята.
Шикләнгәндәй нәнәй карап тора
Төн куерган якка.

Шул якларның шомлы җилләренме
Ана күңеле сизгән!
Көн башлана торган җирләремне
Күпсенәләр бездән.

---

Зәңгәр һава кинәт сорыланды,
Шул кояш, шул таңмы!
Таңдай якты, алсу иде дөнья, —
Көн һәм төн буталды.

Әткәй!
Кемнәр сиңа салды шулай
«Дошман» дигән тамга!
Күкрәгеңә төбәп аткан төн ул —
«Дошман» минем анда.

Ә син таң нурлары белән бергә
Җылың бирдең җиргә...
Әйләнәме дөнья куласасы, —
Афәт килә илгә.

Күкрәкләрне ачып атлар чакта
Дошман тупларына,
Ялгыш язмыш
ялгыз алып китте
Себер сукмагыннан.

●

Сугыш.
Җәйләр коры, кышлар кырыс.
Саекты елгалар.
Туган йортка кайтты килен, кызлар.
Өстәүгә — ун бала.

Мең чакрымнан җәяү катыш кайтып
Туган җиргә баскач,
Әллә каян танып, каршы чыккан
Нәнәй капка ачкач,

Әнкәй көлеп куйды.
Иңнәреннән
Таулар төште гүя.
Әйтерсең лә, алты бала түгел,
кайтты алтын төяп.

Ә әткәйне, төн пәрдәсен ертып,
Алып киткән чакны
Онытасым юк, —
Сыкрап калган иде:

«Кемнән әзлим хаклык!
Бәрәңге чәчәрлек җирең дә юк,
Яшәргә юк куыш...»
Бар кешедә хәзер уртак кайгы:
Илдә — канлы сугыш,

●

Сугыш.
Җәйләр коры, кышлар кырыс.
Җилләре дә зәһәр.
Күпер төбенә чыгып, иртә саен
Нәнәй көтә хәбәр.

Телеграмма килде Миңнулладан,
Чынмы, әллә ялгыш:
«Бәлки очрашырбыз,
көнбатышка
Безнең узып барыш».

---

Таң аткан яклардан
Көн баткан якларга
Узалар солдатлар...
Агыла, агыла
Тәрәзсез вагоннар.
— Улым, сез кай яклар!

Киләләр, китәләр,
Тукталмый үтәләр.
Поездлар, поездлар,
Каршылап, озатып,
Уза көн, уза төн,
Бик таныш бу йөзләр.

Анадан фатиха,
И солдат балакай,
Көчтәнәч ал юлга.
Ул сезнең арада,
Бәлки шул вагонда
Барадыр Миңнулла.

---

Бер тәүлек тулуга
Нәнәбез тагын да
Май яза ашыгып,
Ай буе йөреде
Очраган солдатка
Күчтәнәч тапшырып.

Көнбатыш ягына
Ашыгып уздылар
Поездлар, поездлар.
Яңгырлы күзләрдә
Йомылды йолдызлар,
Боекты яшь кызлар.

---

Арышлар урылса,
Бодайлар коела,
Тарала көлтәләр.
Барсалар, кайтсалар,
Апалар, җиңгиләр
Көн дә хат көтәләр.

«Сәгатькә тезелә
Минутлар исәбе.
Ник көтәм бу кадәр
Бер кәгазь кисәге,
Бер сәлам кисәге,
Мин көтәм бер хәбәр.

Җилдә тал сыгыла,
Инде таң сызыла.
Очрашырбыз, дидең.
Әйтәсе сүзләрем
Үзәкне өзгәли,—
Сөйләшербез, дидең.

Бу сүзләр кичәге,
Бу эзләр кичәге.
Ә бүген ни хәлләр!
Бер кәгазь кисәге,
Бер сәлам кисәге,
Мин көтәм бер хәбәр».

Һәм килде бер хәбәр,
Җәйге җил ник зәһәр,
Ник, нәнәй, син хәлсез!
Ник көттең бу кадәр! —
Һәм килде бер хәбәр:
«Югалды хәбәрсез».

Югалды хәбәрсез...
Кем өчен кадерсеә
И йөрәк парәсе!
Янса да утларда,
Батса да суларда,
Югалмас хәбәрсез.

Тәрәзсез йорты да
Моңаеп утыра,
Бер кайтыр Миңнулла.
Җир көя, ил яна,
Ил белән бер юлда
Югалмас ир бала.

---

Өстәлде ун бала.
Сыйдыра карт ана,
Кем ятим, кил сыен.
Туйдыра да ана,
Җылыта да ана,
Бар сые — бер сыер.

Хатын-кыз басуда,
Бар да җир казуда,
Карт ана көрсенә.
Алтыны озатты,
Калмады ир заты,
Кайтмады берсе дә.

Кайтмады берсе дә.
Кызлары җир сөрә
Тагылып сыерга.
Канатлы чаптарны
Һәм акбүз атларны
Тапмассыз бу җырда.

Күктәге хыяллар
Җиргәрәк сыенган.
Бар өмет — җир-суым
Балтырган буткасы,
Үләнле сөт ашы —
Барысы да җир сые.

Уллары юнәлгән
Якларга юл ала
Өлгергән икмәге.
Сызлап та ярасы,
Туйдыра баласын
Җир-ана күкрәге.

●

Кече өй хуҗасыз.
Ишеге йозаклы,
Тәрәздә капкач.
— Сат, — диләр, — юнәрсез.
Нәнәй сүз озайтмый:
— Миңнулла кайткач.

Һаваларга менде,
Суларга төште
Лачындай егетләр.
Җанлы күпер булып,
Утлы өрлек булып
Янды өметләр.

Янды да кабынды,
Толлар да кагынды
Канатның сыңарын.
Бәбкәләр үстеләр,
Буәне кичтеләр,
Киң Идел суларын.

Хуҗасыз йорт кына
Корышып утыра
Җиргә кар яткач.
— Сүт, — диләр — утынга.
Ә нәнәй нык тора:
— Миңнулла кайткач...

●

Сынап шулай ана чыдамлыгын,
Кышлар китеп тора беразга.
Уятучы — кояш.
Юатучы —
Җылы, йомшак, кара буразна.

Буразнага салган бөртекләргә
Тирең тамса, бирә җир сыен.
Үзән-үрләрендә йөреп аргач,
Куенына ала җир-суым.

Шатлыклары — кура җиләк микән,
Кайгылары — кара бөрлегән.
Илләр гизсәң, нинди киң дә җирем, —
Ана кабере җирдә бер генә.

Җир әйләнгән саен, шар тирәли
Йөрер иде кеше әйләнеп, —
Туган туфрак чәчнең һәр бөртеген
Бәбкә уланнарга бәйләде.

Бик җирсәгән чакта,
җир суларны
Бер күрмичә күңел түзәме!
Кендегеннән анаң кайда кискән, —
Шунда була җирнең үзәге.

Җирнең тарту көче шул үзәктә,
Китсә дә гена юллар кай таба, —
Балаларны алып киткән юллар
Оныкларны алып кайталар.

●

Еллар узган, еллар...
Исән икән
Яр буенда урам.
Аллы-гөлле тәрәзәләре белән
Йорт та исән торган.

Күпме яңа йортлар бу урамда,
Карап барам юри, —
Яшел мүкләр кунган шул өйдән дә
Сөйкемлерәк бер өй

Булмас икән бөтен дөньясында!
Ничә еллар күрмә!
Уйлап йөрдем, нәнәй белән бергә
Кергәндер дип гүргә.

Әллә инде тирән уйга талган,
Башын түбән игән.
Нигезеннән читкә кузгалмаган,
Җиргә ныграк иңгән.

Тәрәзәдә тамчы гөлләр булыр,
Узып китмә ялгыш.
Капка төпләрендә тора ялгыз
Газизәкәй балдыз.

---

Газизәкәй, ана өметләре
Киселмәсен өчен
Сүтмәдеңме иске бу нигезне —
Туганнарың төсен.


Үзең өзлегеп тә өзмәгәнсең
Кайтыр сукмакларын.
Шул сукмактан җырлап киткән иде
Сөелмәгән ярың.

Сакланганмы әллә иске нигез
Хатирәләр өчен!
Үсеп чыккан яңа, якты йортлар —
Шул нигезнең көче!

Дөнья — куласа ул.
Ә күчәрен аның
Койган урак-чүкеч.
Үз күчәрен үз кулына алгач,
Юк, чигенмәс бу көч.

Җиргә иңгәч,
шул хаклыкны раслап,
Күтәрелде авыл.
Иске өй искәртә:
— Онытмагыз!
Югалтулар авыр.

——□——



*Көн килер дә,*
*Бер матур таңда кинәт*
*Карт тарих башын түбән табан ияр.*
*Һәм:*
*„Бүген көн Октябрьга*
*Илле ел тулды“, — дияр.*

ҺАДИ ТАКТАШ.

*Зәки Нури*

## Яз көнендә туган кешегә

Безнең Идел сине бөркет итте,
Канат ярдың безнең якта син.
Мәңге-мәңге безнең Казандагы
Ленин урамыннан атла син.

Мәңге куан безнең белән бергә,
Яңара дип җирнең һәр төше.
Бездә хәзер эше белән данлы,
Белем белән көчле һәр кеше.

Байрак булып безнең сафта йөри
Йөрәгеңнең синең ялкыны.
Чикләр аша үтеп ага хәзер
Татарстан кара алтыны.

Иделебез диңгез булып тулды,
Бодай башаклары тук бездә.
Утлар арты утлар кабыналар,
Зарлы җырлар инде юк бездә.

Синең юлдан шулай атлыйбыз без,
Шулай бара безнең эшебез,
Җирдә язлар якты булсын өчен
Яз көнендә туган кешебез!

Утыр безнең барча түрләрдә син,
Вышкаларга безнең менеп бас.
Син Казанны нурлы Казан иттең,
Казан сине мәңге онытмас.

## Сибгат Хәким

* * *

Яшьлегем искә төшереп
Тора һаман артымда.
Җәйге өйрәнү уздырган
Частьта, Кабан артында,

Сөйләдек шигырь Муса, мин.
Язмышка тагылмаган,
Болай кяргән, үзенә
Ялгыш та кагылмаган

Яшь бер кыз безнең арада...
Тормышта ул инанган
Шигырьгә... бергә кайтабыз,
Атлыйбыз, кыз — иң алдан.

Туктаусыз, өзлексез, мәңге
Өстә шулай ян, кояш!
Кинәт караңгы каплады
Арыш кырын яртылаш.

Юк кына яңгыр куркытты.
Күләм, күлеп бушамыйм;
Туфлиләр — кулда, йөгердек,
Без өчәү: кыз, Муса, мин.

Безгә шул яңгыр астында
Җайлап барасы икән,
Яңгыр китергән яшеннәр —
Алар нарасый икән,

Зурлары еракта булган,
Ә без, юләр, йөгердек
Каршына шуларның, утта
Яраланып егылдык...

Дусларны эзлим, дусларны
Сугыш утта яндырды...
Йөгермим хәзер, төн буе
Тыңлап ятам яңгырны.

1967

—— ——

*Әхсән Баянов*

## Тыйнак кеше турында баллада

Ерак йөргән ораторлык аннан,
Ул үзе дә
Цицеронны санга сукмаган.
Аның өчен штык килгән сүзгә,
Дәрәҗәсен мылтык яклаган.
Сүзсез генә киткән ул Себергә,
Җырларын да сүзсез җырлаган.
Аның өчен буран килгән телгә,
Аның өчен богау чыңлаган:
— Яшәсен революция!

Февраль җиле ачы булган аңа,
Кайтарса да туган җиренә.
Яраткан ул апрель бураннарын,
Үз сүзләрен тапкан шул җилдә.
Андый сүзләр килгән Петроградтан
Октябрьда тагын яздагы
Таныш көйләр кабат килгән аңа,
Чыгышларның килгән азагы:
— Яшәсен революция!

Кулдан кулга күчкән авыл шунда,
Бер кызыллар узган, бер аклар.
Сәйлән төсле тирадалар тезеп,
Кайберәүләр элгән флаглар:
Аклар килсә, күтәргәннәр акны,
Ә кызыллар килсә — кызылын...
Һәр заманның була ялагае,
Акыл кыска булса, сүз озын:
— Яшәсен... яшәсен... я... я... я...

Ә басынкы кеше эндәшмәгән,
Һаман бер көй аның, бер байрак.
Таң атканда биек манарада
Шул байракны күргән тирә-як...
Ул хәзер дә яши, речь сөйләми,
Күп төс белә, кызыл төс сөя.
Аның сүзе безнең канда тибә:
— Яшәсен революция!

——□——

*Нурихан*

*Фәттах*

Повесть



# МӨДИР

*Беренче бүлек*

## I

31 нче июль көне гомергә онытылмаслык булып минем хәтеремдә калды. Ул көнне мин иртәрәк тордым. Тиз-тиз генә ашадым-эчтем дә көзгегә карандым. Көзге белән эшемне бетергәч, китап-дәфтәр арасындагы дипломымны алдым. Ике битлек катыргы кисәген кул очына тоттым да урамга чыгып киттем.

Райздравка барып кергәндә, мин бөтенләй дулкынланмадым. Райздрав мөдире әле килмәгән иде. Секретарь миңа утырырга, көтеп торырга кушты.

Утыра торгач, бүлмәгә кыюсыз гына атлап бер кыз килеп керде. «Бу да минем кебек техникум бетергән кешедер инде», дип уйладым мин. Кыз исәнләште: «Исәнмесез», диде. Секретарь да: «Исәнмесез», диде. Мин эндәшмәдем, эре генә утыра бирдем. Шулай да кызның өс-башына игътибар иттем. Әллә ни түгел. Ярым авылча, ярым шәһәрчә. Техникум бетергән кешенең нинди булыр дисең инде... Нәрсә ул техникум бетергән кеше? Надан дисәң, надан түгел, белемле дисәң, белемле түгел. Институт белән мәктәп арасында буталып калган. Урта кул. Мин, билгеле, үземне әйтмим. Мин — башка. Мин... Ярар инде, калып торсын.

Беркадәр вакыттан соң тагын бер кыз килеп керде. Аннары бер кыз белән бер егет керде, ике кыз керде. Бүлмәдә утырыр урын да калмады. Чыш-пыш сөйләшкән, тыелып кына көлешкән тавышлар ишетелә башлады.

Мин берсе белән дә сөйләшмәдем. Үзләрен тиешенчә тота белмәгәннәре өчен, кызларга эчтән генә ачуланып та куйдым. Теләсә кем алдында, теләсә кайда ихахай да михахай килеп йөрсәң, булырсың фельдшер! Безгә бит укыганда юкка гына әйтмәделәр: фельдшер кеше кайда да үз-үзен тота белергә тиеш, диделәр...

Минә бервакыт тышкы ишек ачылып китте. Бүлмәгә җилләнеп, ашыгып бер агай килеп керде. Агай да түгел, абый. Япь-яшь. Үзе чибәр, озын буйлы, зур кара күзле, куе кара чәчле. Кулына «стильный» сары күн портфель тоткан. Өстендә вак шакмаклы җәйге пинжәк. Ап-ак, чип-чиста күлмәк. Чалбары тар балаклы, яшькелт-зәңгәр төстә.

Ялт итеп торган бу чибәр кеше безнең белән елмаеп исәнләште дә түргә узды. Мин шундук аның райздрав мөдире икәнлеген аңлап алдым. Мөдирне мин бик житди кыяфәтле, күзлекле, бөкрәйгән карт кеше итеп күз алдына китергән идем. Хәзер мин чак-чак кына каушап калгандай булдым. Күңелемнән, аптырап: «Шундый япь-яшь начальниклар да була икән дөньяда!» дип уйлап алдым.

Соломон Моисеевич, ягъни әлеге райздрав мөдире, портфелен шап итеп өстәлгә ташлады, ак эшләпәсен, пинжәген чөйгә элеп куйды, елкылдап торган чәчләрен тарады да, күтәрелеп безгә карады.

— Сөйләгез, коллегалар, мин тыңлыйм, — диде.

Шулай дигәндә үзе ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды, никтер өстәл тартмасын ачып җибәрде. Без аңа үзебезнең йомышны әйтеп бирдек: менә без — яшь белгечләр, медицина техникумы бетергән кешеләр, сез-

# саҗидә

нең карамакка килдек, дидек. Кая булса да эшкә билгеләвегезне телибез, дидек. Без, дигәч тә, мин түгел. Мин берни эндәшмәдем, сихерләнгән кебек Соломон Моисеевичның күзләренә карап тик утырдым.

Соломон Моисеевич безнең һәрберебезне сораштырып чыкты: кайдан килдегез, кайда укыдыгыз? диде. Аннары безнең дипломнар белән танышты. Украинадан килгән бер-ике кешене исәпләмәгәндә, без барыбыз да Башкортстанныкылар булып чыктык. Ләкин мин аларның берсен дә белмим. Мин алар белән укымадым. Мин Уфада укыдым. Алар Бөредә, Стәрлетамакта, тагын шуның ише вак-төяк шәһәрләрдә укыш-

тырганнар. Шул турыда белгәч, мин үземне тагын да эрерәк, дәрәҗәлерәк тотарга тырыштым. Баштарак Украинадан килгәннәр генә бераз шиккә төшергәннәр иде. Мин аларны Киевтандыр дип уйлаган идем. Түгел икән. Нindидер Винницаданмы, Конницаданмы. Минем андый Конница-Винницаларны ишеткәнем дә юк.

## II

Беренче танышудан соң эш урыны билгеләү башланды. Миннән соң килгән кыюсыз гына кыз үзләренең туган авылында калдыруны сорады. Украинадан килгәннәр берәр культуралырак, зуррак авылга китәргә теләделәр. Егет белән кыз исә икесен дә бер пунктка җибәрүне үтенделәр.

Соломон Моисеевич елмаеп кына тыңлап утырды да, шулай бит, болай бит дип, үз фикерен аңлатырга тотынды. Кызлар шаулаштылар, урыннарыннан кузгалыштылар, өстәл янына җыелдылар. Барысы да өстәл янына баргач, миңа утырган җирдән Соломон Моисеевич күренми башлады. Шулай да мин урынымнан кузгалмадым, кулларымны тез өстенә салып, башымны югары тотып, әдәпле генә утырып тордым.

Бер заман Соломон Моисеевич миңа төбәп карады да:

— Ә син, сылукай, кайсы авылга китәргә телисең? — диде.

Кисәк кенә бирелгән сораудан мин каушап калдым. Сораудан да түгел, ахрысы. «Сылукай» сүзеннән. Шундый матур, ягымлы күз карашыннан... Йөземә кызыллык йөгерде, башым түбән иелде. Утырам берни эндәшмичә. Үзем Соломон Моисеевичның соравын аңларга тырышам, үземнең никтер йөрәк суга. Шулай да бераздан исемне җыйдым да, җитди булырга тырышып:

— Мине район больницасында гына калдырырга мөмкин булмасмы? — дидем.

— Ник? Авылга китәсегез килмимени? — диде Соломон Моисеевич.

— Килми шул, — дидем мин.

Бүлмәдәге шау-шу тынып калды. Барысы да минем якка борылдылар, барысы да кызыксынып карап торалар. Мин тагын да ныграк кызарындым.

— Әти-әниләр... — дидем, нәрсәдер ялганларга чамалап.

— Нәрсә, картлармыни? Сездән башка торалмыйлармыни? — диде Соломон Моисеевич.

— Юк та соң...

— Шулай булгач?

Ул тагын миңа төбәп, сынап карады. Минем үзеннән-үзе телем чишелеп китте. Күңелдәге яшерен серләрне ачарга ярамаганлыгын белсәм дә, барысын да сөйләдем дә бирдем.

Авылга киту-китмәү мәсьәләсендә минем үз исәбем бар. Исәпнең хисабы шул: мин Яңавыл кешесе. Яңавылда безнең үз йортыбыз бар, әти-әни, эне-сеңел бар. Яңавыл минем өчен теләсә нинди «культуралы» авыллардан артыграк. Яңавыл ул минем башкалам, минем республикам. Якында гына Бүә суы. Көн дә мин Бүәгә су кирәргә барам. Анңары... бигрәк тә шул: Яңавылда мин кечке мәктәпкә йөри алачакмын. Унынчы класска. Институтка керү өчен. Шулай булгач, нишләп әле мин авылга китеп мүкләнергә тиеш?

Райздрав мөдиренә мин шулайрак дидем. Бары тик авылда мүкләнәсем килмәгәнне генә әйтмәдем дә, көн саен Бүәгә су кирергә барырга кирәклеген генә әйтмәдем. Алары үземә дә нигезсез булып тоелды. Кичке мәктәпкә йөрү, институтка әзерләнү — болары инде, уйлавымча, теләсә кемне ышандырырга тиеш.

Ләкин Соломон Моисеевич ышанмады. Ышануын, бәлки, ышангандыр да — тыңламады.

— Юк, кадерлем, — диде.

«Кадерлем» сүзен ишетеп мин тагын тынычсызланып куйдым. Тагын бер дә юктан башымны түбән идем.

— Беренчедән, район больницасында буш урын юк, — диде райздрав, миннән күзен алмыйча. — Икенчедән, авылда кадрлар житми. Мин сезне иң артта калган авылга җибәрәм, медицина ярдәменә иң мохтаҗ пунктка... Барып төшәрсез, җиң сызганып эшкә тотынырсыз, бөтенесен юлга салырсыз. Килештекме?

— Ә уку? — дидем мин, әле һаман бирешергә теләмичә.

— Уку? Бик укыйсыгыз киләмени? — диде Соломон Моисеевич, көлемсерәп.

— Килә шул! — дидем мин.

— Менә нәрсә, сылукай, — диде Соломон Моисеевич, — мин сезне район больницасына күчерермен. Тик хәзер түгел. Соңыннан. Җай чыккач. Килештекме?

— Килештек! — дидем мин, елмаеп.

## III

Мине Яңавыл районының Мәсәгут дигән авылына билгеләделәр. Кулыма приказ тоттырдылар да хәерле юл теләп озатып калдылар.

Мин юл буена Соломон Моисеевич турында уйлап кайттым. «Әллә гашыйк булдым инде?» дидем үземә үзем. Шулай дип уйлагач, миңа бик-бик рәхәт булып китте. Кичтән йокларга яткач та бары шул турыда гына уйладым.

Мәхәббәт уйлары белән булашып йокыга бик соң киткәнмен. Иртән әни көчкә уятты. Тордым да сәгатькә күз төшереп алдым. Мәсәгут ягына йөрүче автобус китәргә ярты сәгать чамасы вакыт калган. Ашык-пошык юындым, тышка чыгып кердем, көзге янына килдем.

— Нәрсә кадалдың тагын шул көзгеңә? Тиз бул! — дип кычкырды әни.

Кичтән тутырып куйган кечкенә чемодан белән студентлар сумкасын кул очына гына эләктердем дә ишеккә юнәлдем.

— Ярый, хушыгыз, — дидем.

— Нинди «хушыгыз» ул? — диде әни. — Сау бул, диген. Әллә кая китмисең. Кайтырсың әле, машина йөреп тора.

Шулай сөйләнгәләп ул мине озата чыкты. Мин җәяүләп автовокзалга киттем. Үземчә бик кызу бардым. Барып житкәнче тирләп төштем. Шулай да соңга калганмын. «Ашыгуым әрәмгә китте», дип уйладым, үкенеп.

Аптырап тордым-тордым да Мәсәгут ягына бара торган «трах»ка чыктым. Җобанай күпер төбенә туктап көтә башладым. Әледән-әле машиналар, атлар узып китә. Күбесе мин барасы яктан киләләр. Мәсәгут ягына да киткәләделәр. Буш кабиналы машина килгәнен күрдемме, шундук кулымны күтәрәм. Тик нишләптер беркем дә туктамый.

Бер сәгать чамасы көттем. Эч поша башлады. Менә борылмадан, Ходайбирдин урамыннан бер машина килеп чыкты. Күпер турысына житте дә минем каршыда туктап калды.

— Кая барасың? — диде шофер.

— Мәсәгуткә, — дидем мин.

— Әйдә, Ямадыга кадәр утыр. Аннан Мәсәгуткә күп калмый.

Минем моңа бик үк утырасым да килмәде. Беренчедән, кабинасы буш түгел, аннары, кузовының да рәте юк — кырыйлары аркылы-торкылы сугылган такталар белән киртәләп алынган. Киртә эчендә ике-өч агай күренә. Шунда ук бер ала сыер басып тора.

Берни эшләр хәл юк. Чемодан белән сумканы кузовтагы бер агайга суздым да, тәгәрмәчкә басып, әйберләр артыннан үрмәләдем. Агайлар

миңа игътибар итмәделәр, кычкырып сөйләшүләрендә булдылар. Ала сыер гына миңа моңсу күзләрен тутырып карады да тыйнак кына мөңгерәп куйды.

Машина кузгалып китте. Мин, такта киртәгә тотынып, тирә-якны күзәтә башладым. Кая карама — дулкын-дулкын басулар, калкулыклар, түбәнлекләр. Калкулык араларында авыллар күренгәли. Анда — биек тупыллар, тирәкләр, ак такта түбәләр өелешеп утырган җирләрдә бик күңелледер, рәхәттер кебек. Еракта, күк читендә, болыт кисәкләре кабарып тора. Басулар өстендә елкылдап рәшә тирбәлә. Күңел шул болытлар ягына, зәңгәрсу калкулыклар арасына кысылып утырган сихри авыллар, сирәк-мирәк әрәмәләр ягына омтыла. Тирә-якта шундый иркенлек, кояш. Каршыга салкынча җил исә. Шундый күңелле, шундый рәхәт!

Ямады авылына барып җиткәнче минем күңел шулай бик күтәренке булды. Утыз чакрым араны ничек үткәнебезне дә сизмәдем.

Машина кибет каршында туктап калды. Мин җиргә төштем, рәхмәт әйттем. Әйберләрне кибет баскычына куйдым да өс-башымны каккалап алдым.

— Менә шушы юл бара инде Мәсәгуткә, сеңелкәш, — диде шофер, каядыр авыл артына күрсәтеп. — Китә торсаң да ярый, берәр нәрсә туры килер әле шунда.

Машина кузгалды. Миңа карап сыер тагын мөңгерәп куйды. Кибет алдында мин бер үзем торып калдым. Кинәт кенә моңсу булып китте. Як-ягыма караным алдым. Менә ул авыл. «Культуралы» зур авыл! Нишләргә хәзер — җәяүләп китәргәме, әллә «берәр нәрсә» көтеп торыргамы?

## IV

Шулай тора торгач, кибеткә кереп чыкмакчы булдым. Кергәндә кинәт үземнең фельдшер кеше, мөдир кеше икәнлегемне исемә төшердем — юлда килгәндә ул турыда онытып җибәргәнмен. Башны югары күтәрдем, эре генә түргәрәк уздым, киштәләрдәге товарны күздән кичердем. Карасам, үлчәү янындагы киң тактада кып-кызыл кура җиләге өелеп тора. Сатучыдан ярты кило җиләк үлчәттем дә баскычка чыктым. Торам шулай җиләк ашый-ашый. Яннан гына бер бабай китеп бара.

— Бабай, Мәсәгуткә ничә чакрым? — дидем.

Бабай туктады, башындагы түбәтәен арткарак чөеп:

— Җәяү барсаң, биш чакрым, ат белән барсаң, өч чакрым, машинага утырып барсаң, бер чакрым да булмас, — диде.

Мин көлеп куйдым. Бабай белән сөйләшеп торган арада, кибет алдына җигүле бер ат килеп туктады. Арбадан яшьрәк кенә бер егет төште, чак-чак кына аксаклап аты янына килде, дилбегәсен тәртә башына чалып куйды да баскычка менде.

— Исәнме, апасы? — диде бу кинәт.

Мин җавап бирмәдем. Теләсә нинди авыл малае белән сөйләшеп тормассың бит монда!

— Җиләк тәмлеме, юанкай? — диде бу тагын, авызын ерып.

Юанлык минем иң нечкә җирем. Кем дә кем миңа юан дип, симез дип әйттеме, шартлар дәрәҗәгә җитәм инде. Әлеге егетне күрмәмешкә салынып, аңа бөтенләй артым белән борылдым.

— Ачуланма-а! — диде бу, юаткан сыман.— Кая барасың?

— Сезнең өчен барыбер түгелмени? — дидем мин.

— Барыберен барыбер дә, минем ат бар бит! — диде бу, минем әйберләрне караштырып. — Мужыт, юллар бер яккадыр.

— Мужыт түгелдер, — дидем мин, үчекләшеп.

— Шулай да, кая барасың?
— Мәсәгуткә.
— Мәсәгуткә?! Булды алайса! Хәзер папирос кына алып чыгам да...
Аксаклап ул тиз генә кибеткә кереп чыкты. Аты янына барышлый миңа карап елмаеп алды: әйдә, утыр, алып кайтам Мәсәгуткә, диде.

Мин алай әчкерле түгел. Утыр дигәч, шундук йомшарып киттем. Әйберләрне алдым да җиргә төштем. Егет арбаның бер ягыннан мина урын әзерләде, чемоданны алга җайлап куйды да үзе икенче якка аякларын салындырып утырды.

Менә кузгалып киттек. Таш юлда тәгәрмәчләр дыңгырдый. Арба артына бәйләнми салынган буш мичкә сикергәли. Койрыгын күтәреп, бөтен гәүдәсе белән селкенеп, лыс-лыс ат чаба. Ат селкенгән җайга тәртә башындагы дуга селкенә, тимер аеллар чылтырый.

Минем инде күптән, бик күптән атка утырганым юк. Кайчаннан бирле икәнен дә белмим. Арбада утырып бару искиткеч рәхәт. Никтер көләсе килә. Шулай да көлмәскә тырышам. Бөтен гәүдәм белән селкенгәләп, йомшак печән өстендә тик барам.

— Мәсәгуткә кемнәргә барасың? — дип кычкыра егет, сүз башлап.
Сөйләшкән сүз ныграк ишетелсен өчен, ул дилбегәне тарта төшә.
— Беркемгә дә түгел, — димен мин.
— Кунаккамыни? — ди егет.
— Юк, кунакка да түгел, — димен. — Эшкә барам. Эшләргә.
Шулай дип әйткәндә күкрәгем шатлык, горурлык хисе белән тула. Мин үсеп киткәндәй булам. Авыз ерылып китә. Эшкә! Нинди зур сүз, мәгънәле сүз! Эшләргә... барлык кешеләр кебек эшләргә... үз көнеңне үзең күрергә...

— Укытучымыни? — ди егет.
Бу сүзләрне ул миңа бик гаҗәпләнеп әйтә кебек.
— Түгел... фельдшер... — димен мин.
— О, врач икән! — ди егет, миңа карата ачыктан-ачык хөрмәт белән.

«Врач» сүзенә минем түбәм күккә тия. Без беразга тынып калабыз. Үземнең «врач» икәнлегемне белдергәч, минем хәзер ныклап торып сөйләшәсем килә. Мин каерылып егетнең какча йөзенә, киң чандыр җилкәсенә карап алам.

— Аягың нишләде? — димен.
— Комбайнда эшләгәндә трактор астында калдым, — ди бу.
Шуннан соң тагын сүз бетә. Бу минутта минем аяк турында, авырулар турында бөтенләй сөйләшәсем килми. Мин егетнең үзенең сораштыруын телим. Минем күңелне аңлагандай, бераздан бу шаян гына сорап куя:

— Апасы, исемең ничек? — ди.
— Сажидә, — димен мин.
— Мин — Равил, — ди егет.
Беркадәр баргач, тагын сорый бу:
— Безнең авылга ничә көнгә барасың? — ди.
— Ничек инде «ничә көнгә?» — димен. — Эшкә барам димен ич. Медпунктка мөдир булып.
— Һи, безнең авылда врачлар озак яшәмиләр! — ди Равил.
— Ник?
— Белмим. Әллә авылның суы килешми. Мин белгәндә генә дә инде ничә кеше алышынды! Шагапов абый эшләде — Яңавылга күчте. Вазилә исемлесе барые — ире белән читкә китте. Юнысова Фәһимә дигән бер чибәркәй эшләде, анысы укырга китте. Зөбәйдә исемле бер башкорт кызы барые — анысы үзләре ягына кайтып китте. Әле күптән

түгел Зина апа эшләде, Ермакова, ул да хәзер Яңавылда. Син кайсы якныкы соң?

— Яңавыл.

— Һи, әйттем бит! Күз җиткәнче таясың инде син бездән!

— Белмим... — димен мин.

Мин чыннан да ни әйтергә дә белмим. Күңелгә шом төште. Нишләп беркем дә тормый икән ул Мәсәгуттә? Бик алама авыл микәнни?

Равил атына бер кизәнеп алды да, минем барлыкны-юклыкны да онытып, кычкырып җырлап җибәрде.

Арба дыңгырдыгы, җыр тавышы миңа үткән бала вакытларны искә төшерде. Бәләкәй чакта, Эткенавылда, бер вакытны картәтәй мине үзе белән арбага утыртып, көлтә ташырга алып барган иде. Биектә, көлтә төялгән йөк өстендә, утырып бару рәхәт тә, куркыныч та. Минем аста картәтәйнең бишмәте, тирә-ягымда кылчыклы көлтәләр. Урылган арыш исе, камыл исе килә. Күктә тургай сайрый. Без басу юлыннан барабыз. Арба янтайгандай иттеме, куркып, мин юан бастырыкка тотынам, чыркылдап кычкырып җибәрәм. Картәтәй уйламый да, — авыз эченнән әкрен генә көйләп тик бара.

Менә миңа хәзер дә бераз куркыныч та, күңелле дә. Эшли алырмынмы мин анда, әллә чынлап та, Равил әйтмешли, күз җиткәнче үк таярга туры килерме?

Бер арада Равил җырыннан туктады да:

— Ничәнче елгы син? — диде.

— Утыз жиденче, — дидем.

— Унтугызда, алайса. Мин дә унтугызда.

— Шулаймыни?

— Шулайрак шул, апасы. Егетең бармы?

— Ник кирәк ул сиңа?

— Яшел тышлы китапка язып куям, — дигән була Равил.

— Яза бир! — димен.

— Һо, безнең авылда егетләр җитәрлек! Үзем берәрсе белән таныштырырмын әле.

— Мин егетләр эзләп бармыйм, — димен, кырт кисеп. — Мин укырга китәсе кеше.

— Әйттем бит! — ди Равил, куанып. — Алайса, уку башланганчы гына эшлисең?

— Кем әйтте алай дип?

— Үзең.

— Мин алай димәдем. Миңа егетләр кирәкми генә дидем.

— Ха-ха-ха! Ансыз буламени?! — ди Равил. — Унны бетергәнсең, техникум бетергәнсең. Нинди бетмәс уку инде ул?

— Ул гына аз. Мин институтка китәчәкмен, — димен мин.

— Ничә ел укыдың барысы?

— Унике.

— Мин менә җидене генә бетердем. Укып мулла булмассың дигәндәй...

— Дөрес түгел, Равил, — димен мин белдекле генә.

— Һи, ник дөрес булмасын! Менә син унике ел укыгансың, мин җиде... Икебез дә бер арбада утырып барабыз, бер үк юлдан. Ха-ха! На, малкай!

## V

Мин бәхәскә кереп тормадым. Авыл егетләренең шулайрак фикер йөрткәнлекләрен бик яхшы беләм. Шуңа күрә Равилнең сүзләренә бик үк гаҗәпләнмәдем дә. Тик менә шундый егетләр алдында каушап төш-

мәскә генә кирәк. Аларча фикер йөртә башласаң, бик тиз тәгәрәрсең мещанлык баткагына! Аннары инде егетләр белән дә йөри башларсың...

Юк инде, анысы булмас! Минем үз-үземә биргән сүзем бар: авылда мин егетләр белән йөрмәячәкмен! Мин институтка китәсе кеше, мин югары белем аласы кеше. Төп максатың тормышка ашмый торып, нинди егетләр белән йөрү ди ул?! Минем әле барысы да алда, барысы да киләчәктә.

Мин шулай уйланып барганда, Равил кинәт кычкырып җибәрде:

— Менә болары безнең басулар инде! — диде. — Әнә, Фатыйма-тау астында безнең авыл.

— Бер нәрсә күрмим, — дидем мин.

— Күрерсең әле! Ә ул басуларның начальнигы — мин!

— Кемнәрнең начальнигы? — димен, берни аңламыйча.

— Басуларның.

— Басуларның начальнигы буламыни?

— Булмыйча! Мин — басу каравылчысы. Басудагы бөтен нәрсә миңа буйсына, ха-ха!

«Без икебез дә начальник икән», дип әйтмәкче булдым, шулай да тыелып калдым.

— Матурмы безнең яклар? — ди Равил.

— Матур, — дигән булдым мин.

Үзем исә бернинди матурлык күрмим. Бөтен җир шәп-шәрә. Бернинди урман юк. Як-якта иген кырлары.

Фатыйма-тауның өстенә үк менеп җиткәч, чыннан да, алда матур күренеш ачылды. Калкулык астында, уч төбендәге кебек булып, Мәсәгут авылы күренде. Тип-тигез ике урам. Урамнар яшеллеккә күмелгән. Авыл янышнан ук бормаланып елга ага. Авыл артында, елга буенда кечкенә әрәмәлек. Тагын да арырак, зәңгәрсу томан эчендә, нинди-дер башка авыллар...

Таудан чаптырып төштек тә, елга аша салынган күперне дөбер-шатыр чыгып киттек, «олы урам» дип аталган урамга килеп кердек. Урамга килеп керүебез булды, Равил, тиле кебек, очраган бер кешегә:

— Менә, яңа врач алып кайтам! — дип кычкырып бара башлады.

Мин моңа ачуланырга да, көләргә дә белмим. Иплән кенә: кычкырма алай, димен. Равил ишетми дә. Аннары, ишетерлек тә түгел. Ат чаба, буш мичкә дыңгырдый, өрә-өрә арттан нинди-дер эт йөгерә.

Бер заман Равил атын алты почмаклы яңа гына бер йорт алдына китереп туктатты да:

— Менә, килеп тә җиттек, апасы, — диде. — Шушы була инде безнең митпункт.

— Ярар, рәхмәт алып килүегезгә, — дидем мин.

— Кич клубка чык. Бүген үк! — диде Равил, кузгалып киткәндә.

Мин аңа җавап кайтарып тормадым.

Менә мин килеп җиттем. Шатланырга да, кайгырырга да белмим. Берни уйлый белмим. Арбадан шулай тиз генә төшкән өчен, шалтыравык Равил белән шулай тиз генә аерылышкан өчен бераз моңсу да, авыр да кебек. Шул ук вакытта күңел нәрсәгәдер очына да шикелле.

Әкрен генә як-якка — урамга, йортларга күз йөртеп чыктым. Урам тигез, чиста. Яшел чирәм. Ятып ауныйсы килә. Каршыда гына, урамның икенче ягында, алты почмаклы зур йорт тора. Йортның бер почмагына: «Марс» колхозы идарәсе» дип язылган такта беркетелгән. Колхоз идарәсеннән арырак, сулга таба, тыкрыкның икенче ягында, искерәк кенә клуб күренә. Клуб тирәсендә биек тупыллар үсеп утыра.

Урамның пункт урнашкан ягында, бер йорт аша, тагын бер алты почмаклы йорт. Анысы авыл Советы булырга тиеш кебек.

Барысы да якын. Мәсәгутнең үзәгендә торачакмын икән. Һы.

Чемодан белән сумканың икесен ике кул очына элдердем дә капка ягына борылдым.

## VI

Ишек алды керү белән беренче булып күзгә ташланган нәрсә шул булды: ишек төбенә үк диярлек киселмәгән утын аударып ташлаганнар. Шунда юан гына бер агачта тәмәке көйрәтеп бер агай утыра. Уртача яшьләрдә. Озынча ябык битле, төскә ямьсез. Өстенә ак буй төшкән яшел штапель күлмәк кигән. Чалбары кара, таушалып беткән. Ялан баш. Аягында сандали.

Мин капкадан килеп кергәч тә бу мине җенгекләп күздән кичерде. Күзен дә алмыйча, минем үзе янына килеп җиткәнне көтеп тора башлады. Аның шулай текәп каравын сизгәнгә күрә, үземне бераз уңайсыз тоеп, әкрен генә ишек төбенә якынлаштым. Килеп җиттем, әйберләрне җиргә куйдым да, елмаерга тырышып:

— Исәнмесез, — дидем.

— Исән генә, — диде агай.

Шулай диде дә буылып ютәлләргә тотынды. Ютәлләп туктагач, янадан тәмәкесен суырырга тотынды.

— Эчләрне актара инде, дошман, — диде. — Чистый теңкәне корытты.

— Салкын тидердегезмени? — дидем мин, кызганган булып.

— Күптән инде... тарта башладыммы, өзгәли генә...

— Ташлап булмыймени?

— Булмый шул. Ташлыйсы да килми. Тартсаң, кайгылар басылып китә.

Минем сүз озайтып торасым килмәде. Шундый фикердәге кеше белән ничек сөйләшәсең? Файдалы дип уйлый икән, тарта бирсен! Тартуны гына түгел, эчүне дә файдалы дип уйлый, ахрысы, ул. Йөзе таушалган, күз төпләре күгәргән, бит очлары ямьсез булып кызарып тора...

Мин ишеккә карап алдым. Ишектә — йозак.

— Болар юклар икән, — дидем, үз алдыма сөйләнеп.

— Нәрсә, эшкәме? — диде агай, аз гына да гаҗәпләнү белдермичә.

— Әйе, эшкә, — дидем мин, елмаеп.

— Алай икән.

— Пункт мөдире итеп җибәрделәр, — дидем. — Әле генә Равил дигән егет китереп куйды... ат белән...

Бу турыда әйткәч, агайда миңа карата хөрмәт хисе уяныр дип көткән идем, ләкин минем «мөдир» булуыма аның әз генә дә исе китмәде. Ашыкмыйча гына тәмәкесен сүндерде дә чалбар балагындагы мамык кисәкләрен сыпыргалап төшерде.

— Һе, алай икән алайса, — дигән булды. — Түлке авылы начар шул, сеңелкәш. Авылыннан бигрәк, начальствосы яман.

— Сез шушы авылныкымы? — дидем мин.

— Юк, мин читтән килгән кеше. Укытучы мин.

— Укытучы? — дидем мин, исем китеп.

Шундый кыяфәттәге укытучы була алуына минем никтер ышанасым килмәде.

— Бу авылда өч ел эшләдем инде, — диде агай. — Менә быел эшләмәячәкмен. Кампликтавание вакытында исемлектән төшереп калдырганнар.

— Ни өчен?

— Мин дөреслекне сүләргә яратам — шуның өчен, — диде агай, үртәлеп. — Дөресен сүләгән кешегә монда тыңгы юк. Ялагайлансаң, ярарга тырышсаң, майда йөзәсең. Мин андый түгел. Директор белән тыныша алмадык. Булмады. Турысын әйткән — туганына ярамаган. Шулай, сеңелкәш. Авыр булыр сиңа монда. Кырыкка бөгәрләр. Кәтлит ясарлар.

— Мин бит мәктәп директорына буйсынмыйм, — дигән булдым мин. — Мин авыл Советына буйсынам.

— Алары мәктәп директорыннан да яманрак. Әнә пунктның сарае буш тора. Шунда сыер кышлатканыем, җанымны ашадылар шуның өчен.

— Сез кайда торасыз соң? — дидем мин.

— Менә... пунктның икенче ягында, — диде агай теләр-теләмәс кенә. — Аннан кысрыклап чыгармакчы булдылар — чыкмадым. Мин андый түгел. Кая чыгаем мин аннан? Бала-чага, катын... Катын эшләмәй. Бер үзең тырышкан буласың, дөнья артыннан куган буласың. Ул синең яканнан эләктерә дә ала. Да, сеңнекәш. Мин әле аннан чыкмаймын! Мин әле Уфага барам. Яңавылда да ышаныч юк. Сине инде акыртып җылатачаклар алар.

Ул шулай зарланган саен минем эч поша, күңел төшә бара. «Ник килдем мин монда?» дип үкенеп тә куям. Тизрәк бу агайдан аерылып та китәсе килә, йозакны ачтырасы, эчкә керәсе, үзеңне эш урынында итеп күрәсе килә.

Агай белән шулай күңелсез темага гәп сатып торганда, урам якта пункт турысына ниндидер ат килеп туктады. Икебез дә шул якка борылып карадык.

## VII

Капкадан унөч-ундүрт яшьләрдәге бер малай килеп керде. Йөзе борчулы. Ашыкканлыгы, курыкканлыгы әллә каян күренеп тора. Мөгаен, бер-бер хәл булгандыр.

Безнең янга килеп җитте дә бу, башта бикле ишеккә, аннары безгә карады.

— Бырачлар кая икән? — диде.

Мин, җавап көткән сыман, агайга карадым.

— Ник кирәк бырач? — диде агай, ашыкмыйча гына.

— Җиңгәй бәбәйгә чирләде,— диде малай, җыларга җитешеп.— Тиз генә кушарка алып килергә куштылар. Кайда торалар? Өйләре кайда? Пунктта булмаса, өенә барып ал дип җибәрделәр.

— Алар юк, энекәш, — диде укытучы, кемнеңдер бәбәйгә чирләвенә әз генә дә исе китмичә. — Кушарка бүгеннән башлап эшләмәй. Иртәгә эшен тапшырачак. Менә монда бераү бар да...

Ниндидер җансыз әйбергә күрсәткән сыман, ул миңа төртеп күрсәтте.

— Апа, әйдә тизрәк! — диде малай.

Мин, билгеле, «кушарка» түгел, мин — мөдир. Белемем буенча мин — фельдшер, ягъни — терапевт, хирург, невропатолог, күз-колак-борын авырулары белгече. Мин — универсал. Авылда нинди чирле бар, барысын да мин карарга тиеш. Ләкин килмәгән «кушарка»ны көтеп торып булмый бит инде! Тиз дигәннәр, хәзер үк алып кил дигәннәр...

Тик мин әле пунктка аяк та басмаганмын! Мин әле эшне дә кабул итмәгән, кемгә дә булса күренмәгән дә. Нишләргә?

Шушы минутта мин үз гомеремдә беренче мәртәбә чын-чынлап җаваплылык дигән нәрсә тойдым. Кеше өчен, кешенең язмышы өчен

җаваплылык тойдым. Ни генә булмасын, малайны кире борып җибәрергә минем хакым юк. Димәк, эш сәгате минем шушы минуттан башлана.

— Ярар, барырбыз, — дидем малайга. Аннары агайга борылдым да: — Пунктның ачкычы кемдә икән? — дидем.

— Минем катынга әйт, — диде агай, пунктның үзләре тора торган ягына ымлап.

Мин ашыгып урынымнан кузгалдым. Ишектән миңа каршы тәбәнәк буйлы, юан гына, түгәрәк кенә бер хатын килеп чыкты. Ул, ахрысы, безнең сөйләшүне ишетеп торган. Хатын миңа бүрәнә ярыгыннан ачкыч алып бирде.

Ишекне ачтым, эчкә кердем. Килеп керү белән, борынга дару исе бәрелде. Бүлмә эче салкынча гына, тыныч. Бөтен җир ялт итеп тора. Чебен юк, ни юк. Идән ап-ак итеп юылган. Тиешле җиһазлар барысы да үз урынында.

Монысы — кабул итү бүлмәсе.

Ишек төбендә тагын көтеп тору бүлмәсе бар. Такта стена артында — өченче бүлмә. Анда ике тимер карават тора. Караватлар арасында — кечкенә өстәл. Урындыклар. Ишек төбендә мич, юынгыч...

Монысы минем тора торган бүлмәм булачак. Тимер караватка чемоданымны куйдым да чемоданнан үземнең студент чакта киеп йөргән ак халатымны алдым. Аны кечкенә сумкага салдым. Аннары, икенче якка чыгып, тумбочка өстендә торган чирек литрлы шешә белән йод алдым. Шунда ук бинт кисәге белән кайчы да табылды.

Ишекне бикләп, ачкычны билгеле ярыкка куйгач, арбага чыгып утырдым. Юл мине тагын каядыр алып китте.

## VIII

Колхоз идарәсе янындагы тыкрыктан бәләкәй урамга чыктык. Малай атны туктаусыз куып бара. Менә соңгы йортлар да артта калды. Мин яңадан кырда-яланда. Як-якта кукуруз басуы. Миңа әле булса мин Равил белән барам кебек.

— Без кая барабыз соң? — дип сорыйм мин шулай да бераздан.

— Тау-авылга,— ди малай.

Андый авылны мин беренче мәртәбә ишетәм.

— Еракмы соң ул? — димен.

— Моннан өч-дүрт чакрым, — ди малай.

«Минем өчен ат җибәргәннәр бит әле!» дип уйлап алам, шатлык хисе тоеп. Шул ук вакытта шүрләгәндәй дә булам. Ышанырлармы, артык яшь димәсләрме? Ярый әле мин Галия кебек кечкенә гәүдәле түгел.

Галия... Ниләр генә эшләп ята икән инде минем Галиякәем? Ахирәтем. Күптән инде аннан хат алган юк. Вакыты юктыр. Нинди бәхетле ул! Минем менә шулай арбага утырып барганны күрсә, нәрсә дип әйтер иде икән?

Ара никадәр ерак, шулай да мин аны үз янымда итеп тоям. Аның җанга үтеп керә торган ачулы күз карашын тоям, аның шелтәле сүзләрен ишетәм. Менә кем булырга кирәк миңа! Галия кебек. Какшамас, буйсынмас Галия кебек. Тимер рухлы, чыдам Галия кебек...

Иң авыр минутларымда мин һәрвакыт аны искә төшерәм, аңа охшарга тырышам. Тик менә шунысы яман — үземә авыр булмаган чакта мин аның турында уйламыйм да. Мин, күрәсең, бик начар кешедер. Минем әле һаман да үземдәге алама якларны тулысынча бетерә алганым юк. Күрәсең, капитализм калдыгы миндә ныграк саклана дыр. Ник?

Каян белим мин аны?!

«Туктале, ник шүрлим соң әле мин? Чыннан да, батыр булырга кирәк! Батыр булырга!..» дип уйлыйм үзем, күңелне күтәрмәкче булам.

Күп тә үтмәде, Тау-авылга барып та җиткәнбез. Безнең килгәнне ерактан ук күреп торганнар, ахрысы. Каршыдагы бер йорттан шунда бер апа килеп чыкты.

— Килдегезме? Әйдәгез, әйдә, бик вакытлы килеп җиттегез, — диде апа, безне каршылап. — Син, Фәрит, ерак китмә. Йомышка кирәк булырсың.

Мин апа белән исәнләштем дә, ишек алга уздым, ниндидер иске галошлар янында тузанлы танкеткамны салып, өйгә кердем. Мин килеп кергәндә йөкле хатын, куллары белән эчен тотып, ух-вах килеп, ишеклетүрле йөренеп тора иде. Агарынган, ябыккан булса да, үзе болай яшь, таза күренә. Шунда ук сандык өстендә, озын күлмәгенең җиңнәрен сызганып, үзенчә бик эшчән кыяфәттә, мөлаем гына бер әби утыра.

— Исәнмесез, апа. Хәлегез ничек? — дидем мин.

Авыру хатын урынына әби җавап бирде.

— Әйбәт бара, балакаем, аллага шөкер, дөрес бара, — диде.

Кирәк булса миңа булышмакчы булып әби җитез генә урыныннан торды. Мин сумкадан халатны алып кидем. Күңелемнән үзем шунда уйлап куйдым: мөгаен, бу карчык кендек-әбидер, дидем.

— Авыр шул, апай... Кайчаннар гына котылырмын инде, — диде йөкле хатын, көрсенеп.

Мин аңа караватка ятарга куштым. Яткач, колагымны куеп, баланың йөрәк тибешен тыңладым. Шуннан соң апаның исем-фамилиясен сорадым, тегесен-монысын сораштырдым. Исеме Рәмзия икән, утыз өч яшьтә. Тракторчы булып эшли. Ике баласы бар. Балаларының икесен дә өйдә тапкан. Җиңел тапкан. Тапкач тиз савыккан, озакламый тракторда эшли башлаган.

Йөкле хатынны караштырган-сораштырган арада өйгә теге безне каршы алган апа килеп керде. Керде дә, миңа карап:

— Ничегрәк, апай? — диде. — Монда гына котылыр микән, әллә Йогәмәшкә алып барырбыз микән?

— Дивана булдыңмы әллә?! — диде кендек-әби, ачуланып. — Шушы хәлендә кешене юлга алып чыгалармени!

Аның шулай миннән узып, минем өчен җавап бирүенә, минем эшемә кысылуына үртәлеп куйдым. Техникумда укыганда безгә әйттеләр: имтомчылар сезнең дошманнарыгыз, диделәр, аларга каршы авылда көрәш алып барыгыз, авырулар янына аларны якын да китермәгез, диделәр.

— Әби, кысылмагыз әле! Чыгып торыгыз моннан! — дидем мин тупас кына.

Ул вакытта мин үземне әллә кем итеп исәпләдем. Укытучыларым әйткән сүзләргә сукырларча ышануны изгелек, патриотлык дип белдем. Ул вакытта мин карт кешенең хәтерен калдыру мөмкинлеген дә, үземнең яшьлегем, тәҗрибәсезлегем турында да уйлый алмадым. Мин: медиклар кендек-әбиләргә табынырга тиеш дип әйтергә җыенмыйм. Медик буларак мин беркайчан да андый сүзне әйтмәм. Ләкин шунысы да хак: кендек-әбиләр гасырлар буенча изге эш эшләгәннәр: йөкле хатыннарга булышлык күрсәтә килгәннәр. Аларның да, билгеле, төрлесе булган. Яхшысы, яманы дигәндәй... Әлеге кендек-әби нинди «белгеч» булгандыр — әйтә алмыйм. Тик шулай да әзме-күпме теоретик белем үзләштереп, ак халат киеп кайткан унтугыз яшьлек кызыйдан ул, һичшиксез, тәҗрибәлерәк булгандыр.

Моны мин бары соңыннан гына, эш узгач кына аңладым.

## IX

— Арбага яхшылап урын әзерләгез! — дидем мин. — Йөгәмәшкә больницага алып барабыз. Монда бернинди шартлар юк. Дару юк, шприцлар юк, стерильность турында әйтеп тә тормыйм...

Барысы да аптырап калдылар. Өйдә тынлык урнашты.

— И, балакаем, котылыр вакыты җитә хәзер, — ди әби, сукранып. — Юлга чыгарга ярамас, әллә ни булуы бар.

— Үзем озата барырмын, — дидем мин.

Мин моны нык итеп, үз-үземә ышанып әйттем. Минем үзсүзлелек йөкле хатынга да, анык каенанасына да тиешенчә тәэсир итте.

— Ярар, барыйм әйдә, Сәлимәттәй. Бырач кеше белми әйтмидер әле,— диде Рәмзия апа.

— Беләдер дә соң, балакаем, — диде кендек-әби күңелсез генә. — Барасы җире бигрәк ерак шул.

Мин тиз генә халатны чишеп сумкага салып куйдым. Аннары мендәрләр алып чыгарга куштым.

Мендәрләрне җайлап арбага салдык та, йөкле хатынга арбага утырырга булыштык. Хатын, ыңгырашмаска тырышып, йөзен чытып, иплән кенә сузылып ятты. Хәерле юл теләп капка төбендә безне хуҗа хатын белән кендек-әби озатып калдылар.

Инде төш ауган. Көн шулай да кызу. Безгә уникe чакрым юл барырга кирәк. Бер-ике чакрым арба юлы белән баргач та, таш юлга чыктык. Мин Фәриткә атны кызуларга куштым.

Ат юрта башлагач, моңарчы тыныч кына яткан хатын ухылдарга тотынды.

— Фәрит, әкренрәк алып барчы атны, селкетә, — диде бу еламсырап.

Ул шулай дигәч, Фәрит атны әкренәйтә төште. Хатын беразга тынычланып калды. Ат әкренләгәч, минем эч поша. Болай атлатып кына барсак, кичкә дә барып җитә алмабыз, чыннан да юлда ул-бу булыр кебек.

— Фәрит, чаптыр атны, йоклама! — димен малайга.

Беркадәр вакыт кызу гына бардык та, хатын тагын ухылдарга тотынды.



*Х. Әхмәтҗанов рәсемнәре.*

— Фәрит, туктат атны! Үләм... әкренрәк... — ди.

Әле әкренләп, әле кызулап бара торгач, бер вакытны Йогәмәшкә керә торган юл чатына килеп җиттек. Фәрит атны читкә борды.

Ат юлы тузанлы, ләкин таш юлга караганда тигезрәк. Арба хәзер бөтенләй диярлек дыңгырдамый, тузан өстеннән йомшак кына селкенеп тик бара. Ике якта да урылган арыш басуы. Арырак, чокыр-чакырлы урыннарда, биш-алты уракчы күренә. Алар комбайн керә алмаган кыйтыкларны урып яталар.

Беркем сөйләшми. Бары тик хатынның әледән-әле ухылдап куйганы гына ишетелә. Әлеге дә баягы атның коры җиргә дөп-дөп басканы, камыт-ыңгырчак селкенгәне ишетелә, ара-тирә мае беткән арба тәгәрмәче шыңшып ала.

Йогәмәшкә тикле, күп булса, ике чакрым ара калды. Еракта биек агач башлары күренде.

— Җитәбез, апа, җитәбез!

Бу сүзләрне мин, йөкле хатынны тынычландырудан бигрәк үземне тынычландыру өчен әйтәм. Миңа чыннан да күңеллерәк була башлый. Ләкин авырлы хатын көтмәгәндә көйсезләнергә тотынды. Кинәт каты гына итеп:

— Фәрит, туктат атны! — диде.

Фәрит дилбегәне тартып җибәрде. Ат туктады. Күз ачып йомган арада хатын урыныннан торды, арбадан төште. Төште дә, шунда юл буена, арба янына чүгәләде.

— Фәрит, артың белән борыл! — дип кычкырды каенсеңә.

Мин аптырап калдым. Аягыма бастым да торам нишләргә белмичә. Шулай да телгә килдем.

— Апа, нишлисез! Ярамый! — димен. — Хәзер үк арбага ятыгыз. Ярамый, рөхсәт итмим!

Минем кисәтү хатынга чебен безелдәгән кебек тә тәэсир итмәде, ахрысы. Ике куллап арба читенә тотынган көе бу һаман көчәнүендә булды, ух-вах килде. Бар көченә: ах! дип бер кычкырып җибәрде дә кинәт тынып калды.

Мин тетрәнеп киттем. Иелдем, чүгәләгәндәй иттем. Берни эшли алмаганга, үгетләп, шелтәләп, тагын нидер сөйләнгән булдым.

Искәрмәстән хатын ачу белән миңа кычкырып җибәрде:

— Тот баланы! Нәрсә каттың! — диде.

Күп тә үтмәде, дөньяга бер бала туды. Теп-тере, шәп-шәрә бер бала туды. Мин кабаланып аны кулыма алдым. Кендекне кистем. Баланың кызыл, җылы тәпиләре бераз гына җиргә тиде, тузанга буялды. Әллә басарга ирек бирмәгәнгә үпкә белдереп, әллә дөньяга чыгуына шатланып, үзенең уймак чаклы гына авызы белән бала кычкырып елап җибәрде. Чын кеше тавышы белән, чын хис-тойгылар акырып җибәрде.

Мин Фәриткә сумкадан ак халатны алып бирергә куштым. Халатны алдыма җәйдем дә баланы шуңа төрдем, аннары мендәр өстенә салдым. Бала белән эшне бетергәч, ана кешегә булышыйм гына дигән идем... хатын, берни булмагандай, җитез генә кыланып, арбага менеп тик бара! Менде дә бу арбага, баласы янына чалкан сузылып ятты.

Мин баланы яңадан кулыма алдым, хатынның баш астындагы мендәрен җайладым, күлмәк итәген каплаштырып куйдым.

— Кем? — диде ана бераздан, хәлсез генә.

Баланы карарга да онытканмын икән. Халатны сүтеп карадым да, күңелсез генә:

— Мала-ай... — дидем.

Хатын тынып калды, күзләрен йомды.

Ул арада мин дә бераз айныгандай булдым. Як-ягыма күз төшереп алдым. Күктә кояш кыздыра. Баш очында гына тургайлар сайрый. Юл буенда үләндә, камыл арасында, бер-берсен узышып, чикерткәләр

чәкелдәшә. Исе китеп, хәйран калып Фәрит тын гына арба янында басып тора. Кара бия, тынычсызланып, койрыгын селтәштереп куя, башын борып әледән-әле безнең якка күз ташлап ала. Бездән арырак, урылмаган арышлар янында, кайсы кулын маңгаена куеп, кайсы биленә таянып, безгә таба уракчылар карап тора.

Уракчыларны күрү белән, мине оят-хурлык хисе көйдереп алды. Менә синң врач! Менә синң мөдир! Эшкә башлавыңның беренче адымыннан ук хурга кал, имеш! Бөтен халык алдында! Бөтен дөнья алдында!..

— Әйдә... Фәрит... — дидем төшенке генә. — Кузгал.

Баланы җайлап тоттым да арбага менеп утырдым.

Берничә минуттан без больницага барып җиттек.

## X

Мәсәгуткә без Фәрит белән икәү генә кайттык.

Инде кич булып килә. Урамда бала-чагадан башка беркем күренми. Фәрит мине капка төбенә кадәр китереп куйды. Мин ишек алдына уздым, бүрәнәдәге ярыктан ачкычны алдым да, ишекне ачып өйгә кердем.

Бүлмәләр әйтеп бетергесез дәрәҗәдә ят булып, чит булып тоелды. Стеналардагы плакатлар да, тәрәзә пәрдәләре дә, ак җәймә җәелгән сәке дә — барысы миңа шелтәләп, ачуланып карыйлар шикелле тоелды.

Чемоданнан Галиянең фотосын эзләп таптым да өстәлдәге графинга сөяп куйдым. Озак кына аның күзләренә карап тордым. Күңелемнән: «Нишләргә? Нишләргә?» дип үз-үземә сорау бирдем. Дус кызымның бераз гына кысылган очкынлы күзләренә, нечкә иреннәренә карап торгач, күнелгә ял булып киткәндәй булды. Өйдән алып килгән суык бәрәңге белән бер телем икмәкне алдым да, иренеп кенә, теләр-теләмәс кенә ашарга керештем.

Карама коелып утырам шулай тимер караватта. Инде бөтен авыл белгәндер. Сөйлиләрдер, гайбәт саталардыр...

Шулай нишләргә белми утырганда, кемдер бүлмә ишеген ачты да:

— Мөмкинме? — диде.

Мин ишеккә борылып карадым. Минем «мөмкин» дигәнне дә көтмәстән, бүлмәгә чая гына бер кыз килеп керде. Керде дә бу, елмаеп, туп-туры минем янга узды.

— Исән-имин килдегезме? — диде. — Сез инде өлгергәнсез дә... Фәритне очраттым. Тау-авылда булгансыз икән.

Авыздагы бәрәңгене чәйнәмичә йотып җибәрдем. Кып-кызыл булдым. Ишеткән! Барысын да белә! Кем соң бу?Ник килгән? Җитмәсә, үзен шундый иркен тота.

Яшькә дә, буйга да ул минем чама. Ләкин, миңа капма-каршы буларак, искиткеч җиңел сөякле. Нечкә билле. Төскә-биткә матур, бик матур. Нәфис кара кашлар, кыю кара күзләр. Җыйнак кына, матур гына борын. Иреннәр дә җыйнак, матур. Чокырланып торган ирен асты, түгәрәк кенә ияк. Маңгае гына бераз тәбәнәк сыман. Аннары, калку, тулы күкрәк. Кашлары, күзләре аеруча матур. Шәрә беләкләре кояшта янган. Тулып, күзгә бәрелеп тора.

Өстенә авылчарак тегелгән алсу штапель кофта кигән. Җиңе, кыска булса да, терсәккә җитеп тора. Анысы бик үк килешле түгел. Аннары — кара трико юбка. Юбкасы нечкә билен тагын да нечкәртеп күрсәтә. Аягында биек үкчәле кара туфли. Чәче кистерелгән, шпилькалар белән тоттырып, артка җыеп куелган.

Әллә минем Тау-авылга барганны белгәнгә күрә, әллә үз-үзен чамадан тыш кыю тотканга, беренче караштан ук ул миңа ошамады. Кем белә, бәлки, бераз гына көнләшү дә булгандыр.

— Сез кем буласыз соң? — дидем мин, ашавымнан туктап.

— Мин Зөһрә булам, — диде кыз җиңел генә. — Мин пунктта санитарка булып эшлим. Әле әйтмәдем дәмени? Менә, мин инде ул Зөһрә... сезнең санитарка!

Без сөйләшеп киттек. Мин аннан пункт хәлләре турында, минем киләчәк эшемә кагылышлы кайбер нәрсәләр турында сораштырдым. Зөһрә әйтте: мин инде монда дүртенче ел эшлим, диде, шушы дәвер эчендә өч фельдшер алышынды, менә сез дүртенчесе, диде. Баштарак ул шулай «сез» дип эндәште, аннары, иялләшә төшкәч, «син»гә күчте.

Минем белән ул бер дә санитарка булып, миңа буйсынган кеше булып сөйләшмәде. Үз-үзен ул миннән зуррак, өстенрәк итеп тотты. Ничәнче елгысың, диде; кайдан килдең, кайда укыдың, диде; әтиең-әниең бармы, Яңавылда йортыгыз кайсы урамда, ничәнче номер, диде. Шуннан соң Уфа турында, шәһәр тормышы турында сораштыра башлады.

Баштарак аның өстенлегенә эчем пошса да, Уфа турында сорагач, шундук ачылып киттем. Зөһрә дә күз алдында үзгәрде. Йотлыгып, авызга керердәй булып тыңлый!

— Эх, ятабыз инде шушында әрәм булып! — диде бу, көрсенеп. — Кеше кебек, ичмасам, читкә дә китеп булмады.

«Чынлап та, авылда әрәм булып ята шундый чибәрлеге белән», дип уйлап куйдым.

— Ничә класс бетердең соң? — дидем.

— Кая инде ул! — диде Зөһрә, кулын селтәп. — Җиде... Аның белән кая барасың? Авыл капкасыннан чыгарга да ярамый.

— Әзрәк шул, — дидем мин. — Ник, шулай да техникумга керергә тырышып карарга була.

— И, уку белән дә берни кырып булмый инде хәзер, — диде Зөһрә, үзенә үзе каршы килеп. — Әнә, бездә әле унны бетергәннәр дә беркая китә алмый йөриләр... чабата киеп... тирес түгеп...

— Сездә әле дә чабата кияләрмени? — дидем мин.

— Кимиләр дә соң. Итек кисә дә чабата кебек инде ул. Кайсы тракторда эшли, кайсы фермада. Берсе бригадир ярдәмчесе. Көтүче кебек. Белемем булса, шушында чиләнеп ятырыеммы соң!

«Минемчә уйлый бу!» дидем мин үз-үземә. Ә мин барыбер монда чиләнеп ятмаячакмын. Җай чыгу белән Яңавылга сыпырачакмын. Инде икеле-микеле уйланып торасы юк. Яңавылда больницада эшләрмен дә, тагын Уфага, я Казанга юл тотармын. Монысында инде институтка. Туп-туры институтка!

Зөһрә чыгып китәргә ашыкмады. Минем янда эше булмаса да, тәрәзә пәрдәләрен сыпырыштыргалап, өстәлдәге графинны бер урыннан икенче урынга күчергәләп, тегесен-монысын сөйләнгәләп, һаман минем янда булды. Мин ашамлык төрелгән кәгазьне читкәрәк алып куйдым. Үзеңнең санитаркаң алдында ярлы кеше кебек суык бәрәңге ашап утырмассың лабаса!

Шуннан соң чемоданнан үземнең китап-дәфтәрләрне, бер-ике күлмәгемне алдым. Әйберләремне тәртипкә китерә башладым.

— Их, карыйм әле! — диде Зөһрә.

Күлмәкләрнең берсен минем кулдан тартып диярлек алды да, сүтеп яктыга карарга да тотынды. Аның нинди материядән тегелүенә игътибар итте, ничә метр китүен, ничә сумга төшүен сорады. Тегелешендәге кайбер яңалыкларны күреп алды. Берсен карап бетерде дә икенчесенә тотынды. Анысын да җәеп җибәрде, үзенә үлчәп карады. Метрлар, сумнар турында сорашты. Уфада хәзер ничегрәк киенәләр диде. Фәлән апа Чиләбедән кайткан, аның күлмәге фәләнчә тегелгән дип такылдап алды.

Күлмәк турында аның шулкадәр фәлсәфә сатуы миңа бер дә ошамады. Кием-салым, мода турында сөйләшү ул, минемчә, наданлык,

мещанлык. Мәктәптә безне шулай өйрәттеләр. Мода турында, киенү-ясану турында элек бай хатыннары, бай кызлары гына сөйләшкәннәр. Чөнки аларның башка эшләре булмаган. Аларга менә минем кебек фельдшер булырга да туры килмәгән, башка төрле мәктәптә укырга да туры килмәгән. Чын кеше, алдынгы карашлы совет кешесе, минемчә, бары тик уку турында гына, илгә, халыкка хезмәт итү турында гына уйларга тиеш.

Күлмәкләр турында сүз булып алгач, Зөһрәне ошатмау тойгысы яратмауга әйләнде. Аның белән бөтенләй сөйләшәсе килми башлады.

— Бераерсендә үтүк юк микән? — дидем шулай да.

— Ярар, хәзер, — диде Зөһрә.

Күз ачып йомганчы ул кемнәрдәндер үтүк алып чыкты. Кайдан күмер алырга, кайда кыздырырга, ничегрәк үтүкләргә кирәклеген аңлатты да:

— Мин киттем. Клубны җыештырасым бар. Мин бит клубта да эшлим. Заф булып, — диде.

Ничек килеп кергән булса, шулай ук ялт кына чыгып та китте.

## XI

Икенче көнне Зөһрә килеп ишек шакыганда әле бик иртә иде. Мин тиз генә сикереп тордым, ишекне барып ачтым. Бүген Зөһрә кызыл бизәкле ситса күлмәк кигән. Бөтенләй икенчеләнеп калган. Тагын да нечкәргән, җыйнакланган. Мин аңа сокланып, көнләшеп карадым. Кичәге яратмау тойгысы каядыр юк булды. Үзләреннән алып килгән калай чәйгүн белән бу миңа чәй кайнатырга куйгач, бөтенләй күңелем эреп китте.

Мин тора торган бүлмәдәге плитәгә ягып җибәргәч, Зөһрә, җитез генә кыланып, юеш чүпрәк белән өстәл өсләрен, шкафларны, тумбочкаларны сөртеп чыкты, тәрәзә пәрдәләрен караштырды, урындык-өстәлләрне кузгаткалап алды. Ул бик тиз эшләде, ялт-йолт кына эшләде. Эшкә уңганлыгы, булдыклылыгы аның әллә каян күренеп тора иде.

Бүген мин анда тагын бер яңалык күреп алдым. Эшләгән арада ул әледән-әле минем белән сөйләшкәли, сөйләшмәгәндә җырлап-җырлап ала. Тавышы шундый матур. Искиткеч матур! Юеш чүпрәк белән өстәл-шкаф сөрткән кебек җинел генә, көчәнмичә генә җырлый.

«Нинди бәхетледер бу!» дип уйладым мин үз алдыма. Егетләр үлеп яраталардыр моны. Ләкин егетләр турындагы уйны мин шундук куалап җибәрергә тырыштым. Үзем дә сизмәстән, көрсенеп куйдым. Бит әле миңа бер генә егетнең дә чын-чынлап гашыйк булганы юк! Кайбер килде-киттеләрне исәпләмәгәндә...

Минем өчен бу бик зур нәрсә. Серле, тирән нәрсә. Мин моны кузгатырга да куркам. Котым алына.

Юындым да, сүзсез генә чәч тарарга тотындым. Кинәт кузгалган күңел үз урынына утыргач, ачыктан-ачык мактау белдереп:

— Тавышың бик матур икән, Зөһрә, — дидем.

Зөһрә көлде, юеш чүпрәген карават башына куйды. Аннары, берниндн тартынусыз, минем чәчләрне тоткаларга керешеп китте.

— Синең чәчең матур, — диде, үзен мактаганга әз генә дә исе китмичә.

Миңа ничектер җылы булып, рәхәт булып китте.

— Чәч белән генә нишлисең, — дигән булдым мин. — Мин бит юан... күәс кебек...

— Һи, кияүгә чыксаң әле бал корты кебек кенә калырсың, — диде Зөһрә.

Чәчне тарап бетергәч, чәй эчтем. Чәй эчкәндә утыз яшьләр чамасындагы, ягымлы гына бер хатын килеп керде. Бу акушерка булып чыкты,

Моңа кадәр ул пунктның мөдире дә булып торган. Бөтен эшне бер үзе алып барган. Хәзер пунктны миңа тапшырырга килгән.

Танышкач-белешкәч, мин аңа кичә Тау-авылга барганда булган теге күңелсез хәлне дә сөйләп бирдем. Аның моңа бер дә исе китмәде. «Дөнья булгач, булыр инде», дип кенә куйды. Тәҗрибәле кеше авызыннан мондый сүз ишеткәч, минем өстән тау-таш ишелеп төшкәндәй булды. Хәзер шул турыда ныграк, тәфсилләбрәк сөйлисем килеп китте. Ләкин хатынның тыңлап торасы килмәде. Шуннан без икәүләп авыл Советына киттек.

## XII

Авыл Советында эш сәгате башланган да. Председатель дә, секретарь да шунда. Бер хатын белән бер ир кеше дә бар.

Без исәнләштек, түргә уздык.

— Менә, Галим абый, минем урынга килгән, — диде акушерка хатын, миңа күрсәтеп.

Калын иренле, тәбәнәгрәк буйлы, тыныч кыяфәтле Галим абый (күрәсең, авыл Советы председателе) өстәлдәге салам эшләпәсен кулына алды да:

— Һо, яңа фельдшермени? — диде. — Бик шәп, сеңелем. Бик кирәк кеше син безгә. Кайчан килдең?

Мин, үз-үземне кыю тотарга тырышып:

— Кичәгенәк, — дидем. — Менә пунктны кабул итәргә кирәк... сез кирәксез.

Кулына кәгазь кисәге тоткан бер хатын шунда сүзгә катышып:

— Алар халкына тынычлык бармыни, — дип куйды. — Кичәгенәк килеп төшү белән, мескенкәемне, алып та киттеләр.

— Каян килеп алдылар? — диде председатель, кызыксынып.

— Тау-авылга, бер хатын янына,— дидем мин, теләмичә генә.

— Бик яхшы булган, — диде Галим абый. — Килгән дә, китеп тә барган. Эшне кабул итәсем бар дип көтеп ятмаган.

— Әйтмә инде, мескенкәем, — дип куйды тагын да әлеге хатын, мине кызганып.

— Нишләп мескен булсын? — диде Галим абый. — Яшь кеше, көче ташып тора. Белеме бар. Дөрес эшләгән!

Бу турыда сөйләшәсе килмичә мин сүзне тизрәк икенчегә борып җибәрергә ашыктым.

— Нишләрбез икән, Галим абый? — дидем.

Галим абый авыл Советы секретарена безнең белән пунктка барырга кушты. Җәенке борынлы, ямьсез генә бер агай шомарып беткән өстәле янынннан торды да безнең янга килде. Өчәүләшеп пунктка киттек.

Пунктны тапшыру, кабул итү ике-өч сәгать эчендә тәмам булды. Кирәкле кәгазьләргә кул куйгач та, элекке мөдир белән авыл Советы секретаре, миңа эшемдә уңышлар теләп, саубуллашып чыгып та киттеләр.

Мин кабул итү өстәле янына килеп утырдым. Халат төймәләрен барлап чыккан булдым, чәч тузгымаганмы дип, халат якасы үз урынындамы, кием-салымда андый-мондый кимчелек юкмы дип, шкаф пыяласына карап алдым. Өстәлдәге кара савытына, журналга, дару шешәләренә кагылгалап алдым. Ничектер кисәк кенә шүрли башладым. Гомергә калтыранмаган кул, тез буыннары калтырый. Үземнең бер дә юктан авыз ерыла.

— Керсеннәрме? — ди Зөһрә. — Эшкә барасы бар диләр, ашыкталар.

Ашыктырганнарын үзем дә ишетеп торам. Ашыктырмыйлар да. Берәү генә ашыктыра.

— Керсеннәр... берәмләп... — димен.

Тавышым әллә нинди ят булып, ямьсез булып чыга. Авырулар белән сөйләшкәндә дә тавышым шулай бозылып чыкмасын дип, тамак кыргалыйм. Шул вакыт, авыр кирза итекләре белән шак-шок басып, ашыктырган егет килеп керә. Таза. Юан. Кызгылт йөзле. Киемнәре каралып беткән. Күренеп тора — я тракторчы, я комбайнчы. Сул кулын күтәрә төшкән. Кул аркасында җәрәхәт күренә.

— Илла да, апасы, көттерергә яратасың икән! — ди бу, бөтен бүлмәгә шаулап. — Кайчан килгәнием инде — эшкә китәргә кирәк. Шуның өчен никадәр вакытны әрәм итәргә туры килә.

— Утырыгыз, — димен мин.

Тавышым җитди, тыныч чыкты.

— Исемегез, фамилиягез ничек?

## XIII

Ул көнне мин биш-алты кеше генә кабул иттем. Авыруларны бик җентекләп, озаклап карадым. Үземчә диагнозлар куйдым, рецептлар яздым.

Кулына ялгыш чүкеч белән суккан тракторчы егетнең ярасын бәйләдем дә аңа тагын икенче көнне дә килергә куштым. Аның артыннан урта яшьләрдәге бер апа керде. Моның тамагы авырта булып чыкты. Эштән тирләп кайткач, кое суы эчкән. Ападан соң, корык-корык йөткергәләп, саргылт йөзле, ябык кына бер агай керде. Үпкәсе авырта икән. Аңа Яңавылда күренергә язу бирдем, чөнки диагноз куя алмадым. Йөрәге авырткан яшь кенә бер хатынга икенче көнне килергә куштым.

Зөһрә авыруларны берәм-берәм кертеп торды. Чираттагы авыруларны керткәч тә, ишекне ябып куйды. Шуннан соң минем янга килде, мин әйткәнне дә көтмәстән, миңа ярдәм итеп, кайберсенең кулын тотып торды, кайберсенә сәкегә ятарга булышты.

Бер малайның чалгыга киселгән аягын бәйләп ятканда, кемдер ишекне ачты да, башын тыгып:

— Мөмкинме? — диде русча.

Мин, башымны калкытмыйча гына:

— Сабыр итегез, — дидем.

Малай соңгы кеше иде. Таягына таянып ул ишеккә юнәлде.

— Кем бар анда — керсен, — дидем Зөһрәгә.

Зөһрә ишекне ачты да икенче як бүлмәгә кычкырып:

— Керегез! — диде.

Бүлмәгә озын гына, чандыр гына бер кыз килеп керде. Өстенә зәңгәр бизәкле чуар ситса күлмәк кигән. Күлмәгенең зур ак якасы әллә каян күзгә ташланып тора. Нечкә биленә ак пластмасса каеш буып куйган.

— Утырыгыз. Фамилиягез ничек? — дидем русча.

Кыз утырды.

— Бородуля, — диде.

— Ничә яшьтә?

— Унсигездә.

— Кайда торасыз?

— Мәсәгуттә.

— Кай җирегез авырта?

Кыз елмаеп җибәрде.

— Мин авыру түгел, — диде. — Мине монда акушерка итеп җибәрделәр. Менә приказ.

Кыз миңа бер кәгазь кисәге тоттырды. Чыннан да шулай, акушерка итеп җибәргәннәр.

Шуннан без ныклабрак таныштык. Мин бераз гына авырулар белән сөйләшкәндәге шикелле сөйләштем. Кызның исеме Таня икән. Украинадан килгән. Иптәшләреннән бераз соңга калган булган. Мин теге Соломон Моисеевич бүлмәсендә очраткан украин кызлары аның иптәшләре булган икән. Фельдшерлык-акушерлык мәктәбен быел гына тәмамлаган. Дипломына теркәлгән кәгазьгә караганда, мәктәпне бик яхшы бетергән. Менә дигән итеп бетергән! Бер генә «яхшы»сы да юк, барысы да «отлично!»

«Оһо!» дип куйдым үз алдыма. Ләкин нишләп соң ул монда эшкә килгән? Аңа бит турыдан-туры институтка керергә мөмкин булган. Бернинди имтихан тапшырмыйча! Кем бу, нинди ахмак бу?

Үзем турында мин аңа кыска гына итеп сөйләдем. Менә мин дә бүген генә кабул иттем әле, дидем; килүегез бик яхшы булган, дидем. Аннары өстәп куйдым: үзегезне өегездәге кебек хис итегез, дидем; юлдан соң арыгансыздыр, хәзер менә урнашырсыз, ял итәрсез, дидем.

Таня тыйнак кына тынлап торды. Сөйләшү-аңлашу тәмам булгач, көтеп тору бүлмәсенә чыктык. Анда Таняның чемоданы белән зур гына төенчеге тора. Чемоданны мин алдым, төенчекне Зөһрәгә күтәрергә куштым. Таняны үзем төн кунган арткы бүлмәгә алып кердем.

Шулай итеп, минем штатта тагын бер кеше артты.

## XIV

Мәсәгут фельдшерлык-акушерлык пунктына барлыгы җиде авыл карый. Бу күп, бик күп. Мәсәгуткә иң якын авыл — Алдар. Ераклыгы бер чакрым. Иң ерак авыл — Куштирәк. Анысы унике чакрым. Аннары: Кызыл Яр, Тау-авыл, Түбән Чат, Югары Чат.

Менә шушы авыллардан безгә таң ату белән авырулар килә. Җәяүләп киләләр, атка утырып, машинага утырып киләләр. Бер авылдан берәр авыру булганда да, көненә җиде кеше. Гадәттә җиде генә булмый, унҗиде, егерме җиде була. Зөһрәнең әйтүенә караганда, миңа кадәр бер дә болай күп кеше килгәне булмаган. «Зина апа» дигән фельдшер эштән киткәч тә, пунктның эшләре таркала башлаган. Бөтен пунктка баш булып калган теге акушерка хатын авыруларга кул селтәгән. Рәтләп карамаган, кычкырынган, авыруларны бер дә юкка тиргәп чыгарган чаклары да булган. Аның үзенең тормышы рәтле булмаган — ире белән начар торган, аерылышып йөргән. Шуңа күрә үзенең төп эшен тиешенчә алып бара алмаган. Аннары, аның вакыты да булмаган. Бер үк вакытта аңа фельдшерлык эшен дә, акушерлык эшен дә башкарырга туры килгән.

Ә без Таня белән икәү. Ул яктан караганда, безнең эшләр җайлы. Шулай ук безнең ирләребез белән талашып торасыбыз юк, балалар турында, йорт-җир турында да кайгыртасы юк. Безнең бөтен кайгымәшәкать — эш. Шуның өстенә, без яшь, без әле каешланмаган, шомармаган. Эш безнең өчен яңа нәрсә, тансык нәрсә. Шуңа да без җилләнеп, дәртләнеп эшлибез.

Авыруларны кабул итүдә Таня сирәк була. Аның үз эше бар. Ул авырлы хатыннарны исәпкә ала, аларның хәлләрен белешеп тора, бала табуда булыша, яшь балаларны тикшерә — патронаж сестра ролен дә үти.

Менә шулай көннәр безнең бик кинренке үтә. Безнең буш вакыт бөтенләй диярлек калмый. Кичләрен, караватка яту белән, йокыга китәбез. Ә кайчакта бик озак кына сөйләшеп, серләшеп ятабыз. Таня үзенең Украинасы турында, әнисе, әбисе турында сөйли.

Кичләрен, йокларга ятар алдыннан, кайчагында баскычка чыгып утырабыз, китап укыйбыз. Карангы төшә башлагач, аяк очтагы, елга буендагы бакалар тавышын тыңлыйбыз. Алар бер-берсен уздырып кычкыралар, сайрыйлар... Берсе бер көйгә сайрый, икенчесе икенче көйгә сайрый. Бөтенесе бергә кушылгач, ниндидер оркестрны, музыканы хәтерләтә. Чынлап, музыканы.

Аннары, бака сайравыннан башка, кичләрен тагын икенче төрле тавышлар да ишетелә. Карангы төштеме, яшьләр клубка җыела. Алар безнең яннан гына үтеп китәләр. Төн уртасына кадәр клуб ягында сөйләшкән, көлешкән тавышлар яңгырап тора. Андый чакларда бигрәк тә моңсу була. Күңел тынычсызлана башлый. Нидер җитми кебек, кемнедер көтәсең кебек. Бер сәбәпсез елыйсы килеп куя. Авыр гына көрсенәсең дә тып-тын, буп-буш булмәгә кереп ятасың. Башта бераз йоклый алмый азапланасың, аннары кинәт кенә онытылып китәсең. Берничә сәгатькә чынбарлыктан юкка чыгасың.

Иртән иртүк тагын Зөһрә килеп җитә. Тагын эш көне башлана.

## XV

Унынчы классны бетергәч мин Башкортстан медицина институтына укырга кермәкче булдым. Гариза бирдем, имтиханнар тапшырып йөрдем. Ләкин конкурстан үтмәдем. «Балл» җитмәде. Җиңелеп, хур булып кире Яңавылга кайтуны күз алдыма да китерә алмадым. Шуннан соң мин Уфада торып калдым. Шәһәрдә берәр эшкә кереп, бераз чарланырга, ныклап торып имтиханга әзерләнергә, икенче елны тагын бәхетне сынап карарга булдым.

Шуларның барысын да әйтеп әтигә хат яздым. Озакламый җавап хаты да килеп төште. Әти миңа киңәш биргән: син, кызым, дигән, бер дә алай бетеренмә — дөньяның кендеге институт түгел, дигән; алай чынлап медик буласың килгәч, тот та фельдшерлар мәктәбенә укырга кер, дигән; үзеңә бер һөнәр булыр, телисең икән, соңыннан институтка да керерсең, бәлки, дигән.

Мин әтинең сүзен тотарга булдым. Өйдә чакта да ул миңа нәкъ шунда керергә киңәш иткән иде, институтка керә алмассың, азапланма юкка, дигән иде.

Техникумга мине бернинди имтихансыз алдылар. Туп-туры өченче курска. Анда барлыгы ике ел укыдым. Үземне язмыш тарафыннан рәнҗетелгән итеп хис иткәнгә, теләмичә генә укыдым. Шуңа күрә минем теоретик белем сай булды. Практикасы да инде...

Таняның эшләр башкача. Фельдшерлык-акушерлык мәктәбендә ул дүрт ел укыган, ягъни җидене бетергәч тә кергән. Үзенең әйтүенә караганда, ул институт турында уйламаган да. Ул чеп-чи авыл кызы. Тормышка ул ачыграк күз белән карый, авылчарак, практик буларак карый. Ул гомере буена «кушарка» булып эшләү өчен укыган. Мин моны эшкә башлауның беренче көннәреннән үк аңлап алдым.

Шулай бер көнне сорый бу миннән:

— Нәрсә ул аорта? — ди.

Мин көлеп куйдым.

— Китаптан карарга кирәк булыр, — дигән булдым.

— Ю-ук, андый аорта түгел, — ди бу, сузып. — Татарча «аорта» нәрсә?

— Ә-ә! Авырта? — дидем мин.

— Әйе, аворта! — ди Таня, татарча әйтергә тырышып.

Мин аңа «авырта»ның нәрсә икәнен аңлатып бирдем. Чемоданыннан тиз генә бу башланмаган калын дәфтәр алды да, беренче биткә: «авырта — болит» дип язып куйды. Бер тотынгач, тагын сораштыра башлады. Үзе мин әйткән бер сүзне дәфтәренә теркәп бара. Мин аңа

авырулар белән сөйләшкәндә еш кулланыла торган сүзләрне, «Кай жирегез авырта?», «Кайчаннан бирле авырта?» кебек җөмләләрне яздырдым.

Буш вакыты булдымы, Таня дәфтәрендәге сүзләрне, җөмләләрне ятларга тотына. Тапкырлау таблицасы ятлаган кебек ятлый. Бирелеп, тырышып өйрәнә. Ул, гомумән, тырыш, карусыз.

Бер көнне, кичке ашны ашагач, Таня белән икәүләп татар теле өйрәнеп утырганда, тышта ишек ачылган тавыш ишетелде. Дөбер-шатыр килеп кемдер кереп ята. Без тынып калдык, көтә башладык.

— Мөмкинме, апалары? — дип кычкыра Равил, такта ишекне ачкандай итеп.

— Кер әйдә, кер, Равил! — дип кычкырдым мин, куанып.

Теге көннән соң Равил пунктка бер-ике мәртәбә кереп чыккан иде. Болай гына, хәл-әхвәл сораштырыр өчен генә. Ничек урнаштың, диде, ошыймы, диде. Аннары клубка чакырды. Икенчесендә чирле булып, аягым сызлый дип керде. Ике керүендә дә мин аны дусларча каршыладым, иркенләп сөйләшеп утырдым.

Бүген дә мин Равилне түргә чакырдым, утырырга урын тәкъдим иттем. Равил алай кыстатып тормады — лап-лоп атлап туп-туры өстәл янына килде, утырды да елмаеп миңа карады, Таняга карады.

— Тавык кебек әллә кунакларга да җыендыгыз? — дигән булды. — Бүген клубта кино була.

Таня аның нәрсә сөйләгәнен бик үк аңлап җитми. Шулай да нидер чамалый, сораулы караш белән әле миңа, әле Равилгә карый.

Шунда минем күңелгә бер уй килде.

— Равил, — димен, елмаеп. — Безгә укытучы кирәк әле.

— Кирәк булса, каян алыйм мин аны? — ди Равил.

— Үзең бул.

Равил аңламады. Йөзенә аптырау билгесе чыкты.

— Кем булырга? Укытучымы?

— Укытучы... профессор, — димен мин, көлеп. — Менә Таня татарча өйрәнмәкче була. Шуңа укытучы кирәк.

Үзе турында сөйләгәнне сизеп торган Таня, ачуланган булып, мине шелтәләп алды: нәрсә син анда «Таня» дип лыгырдыйсың, дигән булды.

Равил, ниһаять, аңлап алды. Күңелләнеп елмаеп җибәрде. Таняга борылды да татарча:

— Шулаймени, апасы? — диде.

— Нярся-я? — диде Таня, сузып.

Равил белән без көлеп җибәрдек. Мин Таняга аңлатып бирдем.

— Була ул, апасы! — диде Равил, урыннан торып. — Әйдә, киногa барасыңмы минем белән? Барганда өйрәтермен.

Мин тәрҗемә итеп бирдем. Таняга җитә калды. Ул инде моңарчы да кино турында, клубка чыгу турында сүз кузгаткалап караган иде. Мин каршы килдем. Клублар, кинолар турында минем ишетәсем дә килми. Ләкин бүген мин Равил белән клубка барырга Таняга үзем әйттем. Таня шундук әзерләнергә тотынды.

Алар мине дә өндәп карадылар. Мин риза булмадым. Шуннан соң болар икәүләп кенә чыгып киттеләр. Буш, тын бүлмәдә мин бер үзем торып калдым. Миңа никтер ямансу булып китте. Тоттым да Галиягә хат язарга утырдым.

## XVI

Хатымны язып та бетермәдем, тышта тагын кемнеңдер кергәне ишетелде. Мин, тын калып, көтә башладым.

Соңгы вакытта мин әллә нишләдем. Бигрәк тә кичкә таба. Урамда сөйләшеп узган кешеләрне ишеттемме, шундук тәрәзәгә капланам, узып

баручыларның йөзләрен күрергә тырышам. Тышта, ишек алда кыштырдык ишеттемме, тагын колак үрә тора, күңел никтер тынычсызлана башлый. Кемнедер көтәсең, кемнедер күрмәкче буласың. Соңыннан, беркем юклыгын аңлагач, тирә-якта бушлык, моңсулык барлыкка килә. Кайчагында төннәрен сискәнеп уянам. Үземчә мин моны күп эшләгәнгәдер дип уйлыйм, әллә чирләдем инде дип тә куям.

Чынын гына әйткәндә, үземнең ни өчен үзгәргәнемне мин бик яхшы сизенәм. Шуны да сизенмәгәч! Тик менә үз-үзеңне алдыйсың килә. Чын сәбәпне юри оныткан буласың, бөтенләй булмаган сәбәпләр эзләгән буласың. Миндә, гомумән, үз-үземне алдарга тырышу гадәте бар бугай. Миндә, Такташ әйтмешли, ике «мин». Шул ике «мин» арасында һәрвакыт каршылык чыгып тора. Бер «мин» дөреслекне сөйләргә тели, икенче «мин» нәрсәдәндер курка. Әллә кеше сүзеннән курка...

Эшкә башлавымның беренче атнасында ук миңа Яңавылга райздравка барырга туры килде. Дару, марля-бинт алырга. Анда баргач, билгеле, Соломон Моисеевич янына керми булмый. Соломон Моисеевич минем белән елмаеп кына сөйләште, эшләп буламы, коллега, диде; иптәш начальник, диде.

Мин аңа нәрсә дип җавап биргәнмендер, хәтерләмим. Бары шуны гына хәтерлим: аның алдында мин никтер оялдым, кызарындым. Аның янып торган зур кара күзләренә карадыммы, ни хикмәттер — коелам да төшәм. Телем көрмәлә, күзем күрми башлый.

Тагын шуны хәтерлим: аның яныннан чыккач мин үземне исерек кебек хис иттем. Өйгә кайткач эти әйтә: әллә, кызым, начальнигың тиргәдеме — бик кызарынгансың, ди. Булыр, булыр, аны бер дә рәтле кеше түгел дип сөйлиләр, ди. Минем эти белән бәхәсләшәсем, Соломон Моисеевичны яклыйсым килде. Ләкин аны яклап берни әйтә алмадым. Бары: тиргәмәде, дип кенә куйдым.

Мәсәгуткә кайткач, атна буена Соломон Моисеевич турында уйланып йөрдем. Яңавылдан әллә кайда читтә яткан бер караңгы авылга, шушындый бер вакытта аның килеп чыгуы мөмкин түгеллеген аңласам да, аннары, урамда берниндн машина тавышы ишетелмәсә дә, тиле бер өмет белән мин хәзер аның бүлмәгә килеп керүен көтә башладым.

Нинди дер кеше чолан ишеген ачты, тамак кырды, безнең бүлмә ишегенә таба килә башлады. Ишек шакыган тавыш ишетелде.

— Керегез! — дип кычкырдым мин.

Бүлмәгә кояшта янган таза, яшь бер егет килеп керде.

Мин аны танып алдым. Тимерҗан дигән егет. Үзеннән бигрәк, исеме истә калган. Бераз гына искечәрәк булса да, колакка ягымлы исем. Кешесе яшь булгач, искечәрәк икәнлеге дә сизелми.

Мин аның белән комсомол учетына кергәндә таныштым. Танышмадым, күрдем генә. Шунда аның бригадир ярдәмчесе булып эшләвен белдем. Никтер колакка чалынып калды. Бары шул.

Язылып бетмәгән хатны читкә этәреп куйдым да керүчегә күтәрелеп карадым. «Әллә мине дә кинога алырга килгәннәрме?» дип уйладым, үз алдыма елмаеп. Тик нишләптер бу кинога алырга кергән төсле күренми. Йөзе җитди. Киеме дә эш киеме. Кырынрак салынган кепкасы астыннан тотам-тотам булып чәче чыгып тора.

— Вакыт соң булса да, килдем әле, — диде бу. — Әнинең хәле начар. Барып карамассыз микән?

— Нәрсә булды? — дидем.

— Лапас түбәсеннән егылып төшкән, — диде бу. — Эштән кайтып ашарга гына утырганыем, кычкырган тавыш ишетелде. Чыксам, егылып төшкән... «Ай, аягым!» дип бер генә ыңгырашты да, тыны да бетте. Өйгә дә алып кермәдем, менә монда сезгә йөгердем.

— Хәзер! — дидем мин, тиз генә урынымнан торып.

Без Тимерҗаннарга барып җиткәндә, аның әнисен инде өйгә алып кергәннәр иде. Ул инде һушына килгән. Караватта чалкан сузылып ята. Шунда ук ике-өч хатын кайнаша. Алар аңа су бөркегәннәр, киемнәрен чылатып бетергәннәр. Кемдер башына юеш сөлге бәйләп куйган, кемдер аягы астына мендәр кыстырган.

— Аягы тайган, аягы! — диештеләр хатыннар мин килеп кергәч тә.

— Аны бырачлар берни эшләтә алмайлар. Хәбирәттәйне алып килергә кирәк, — дип куйды шунда олы авызлы бер хатын.

Үземнең алда минем дәрәҗәне төшереп торган хатынга ачуым килеп куйды.

— Ышанмагач, чакырмаска кирәгие! — дидем каты гына.

— Ышанам, балакаем, ышанам, — диде Тимерҗанның әнисе, ыңгырашып. — Ышанмаска, менә! Шул да булдымы сүз, Маһирә җиңгәй... кешенең хәтерен калдырып...

— Минем хәтер калмый, — дигән булдым мин.

Аннары ыгы-зыгы килгән хатын-кызга борылдым да кырыс кына:

— Тавышланмагыз әле, — дидем. — Авыру яныннан чыгып торсагыз да ярар.

Хатыннар мыштым гына чыгып киттеләр. Мин шундук эшкә керештем. Апаның аягыннан иплән кенә оекларын салдырып алдым. Җентекләп капшап карадым. Аяк таймаган да, сынмаган да. Күрәсең, сеңере тартылган, кан сауган.

Карап бетергәч, артыма борылдым да, Тимерҗанга табак белән салкын су китерергә куштым.

— Аягыгызны хәзер салкын суга, бераздан җылы суга тыгып утырырсыз, — дидем апага. — Хәзергә йөрмәскә кирәк булыр.

— Йөрүләр юк инде ул! — диде апа. — Котым алынды. Сынгандыр дип торам. Мондай көнне кеше күзенә карап яту күңелле эш түгел, балакаем, аллам сакласын.

— Курыкмагыз, ике-өч көннән төзәлер, бернәрсәсе калмас, — дидем мин.

— Шулай булсын, алла бирсә, шулай булсын, балакаем, — диде апа, сүзчәнләнеп. — Имгәк аяк астында. Карап йөрмәсәң, аллам сакласын, вакыт җиткәнне сизми дә калырсың.

— Әйттем мин сиңа! — диде Тимерҗан, әнисен шелтәләп.

— Әйткәч тә бит, балакаем, — диде әнисе. — Син эштә, атаннан булмый, ул печәнне өяргә кирәк ләбаса. Тарауда яткырып булмый ич инде.

— Үзем өярмен дип әйттем ич! — диде Тимерҗан, үртәлеп. — Биек җирдә башың әйләнгәнне үзең дә беләсең. Кем кушкан сиңа анда менәргә?

— Казалгыры диген, ялгыш басканмын, сизми дә калдым, — дигән булды апа, акланырга тырышып.

Минем алда алар шулай җиңелчә генә әйткәләшеп алдылар. Мин кулыма сумкамны эләктердем дә чыгып китәргә җыендым.

— Балакаем, бырачны озатып куй, куркыр, — диде Тимерҗанның әнисе.

— Юк, юк, мәшәкатьләнмәгез! Курыкмыйм, — дидем мин, ишек тоткасына тотынып.

— Мин шул якка барам. Клубка, — диде Тимерҗан.

Бу сүзләрне ул болай гына сөйләнгән кебек әйтте. Үзең кара, миңа барыбер дигән сымаграк итеп кенә. Мин апаны караган арада ул инде юынып, өстен-башын алыштырып өлгергән иде.

Без ишектән икәү бергә чыктык.

## XVII

Тимерҗан белән сөйләшми генә барабыз. Икәүдән-икәү генә булганда, җитмәсә, әле бер-береӊ белән тиешенчә таныш та булмаганда, нәрсә турында гына сөйләшәсеӊ? Каян сүз табарга да каян кыюлык табарга?

Барабыз әкрен генә атлап. Кайбер йортларда ут алганнар. Шулай да күпчелек өйләрдә бернинди җан әсәре күренми — әллә ятып беткәннәр, әллә үлеп беткәннәр. Бары тик онытканда бер анда-санда эт өргән тавыш ишетелеп куя да, басынкы гына сөйләшкән, капка шыгырдаткан тавышлар ишетелгәли.

Чыш-пыш көлешеп, кызулап безнеӊ яннан гына ниндидер кызлар узып китте. Бераз киткәч, берсе артына борылып карады, иптәшләренә нидер әйтеп алды. Кызлар, ераклашып, караӊгыда юк булдылар. Берсенеӊ ак күлмәк итәге озак кына күренеп барды.

Алар узып киткәч, мин, тагын берәрсе килмиме дигән сыман, артыма әйләнеп караган булдым, аннары күккә карап алдым. Күктә йолдызлар. Шундый зур булып, якты булып күренәләр. Әллә соӊ ул төнне йолдызлар бөтенләй юк иде микән? Менә хәзер инде истән дә чыккан!

— Ник сез бер дә клубка чыкмыйсыз? — диде Тимерҗан, сүз башлап.

— Анда нишлим? — дидем мин.

— Нишлим дип инде...

— Мин бит клуб мөдире түгел, пункт мөдире, — дигән булдым мин, шаяртып.

— Клубта күӊел ачарга була, — диде Тимерҗан.

— Минем күӊел болай да ачык, — дидем мин.

Тимерҗанныӊ шундук сүзе бетте. Сизеп барам: аныӊ сөйләшәсе килә, ләкин минем тиз генә ачылып китмәвем эчен пошыра.

— Буш вакытларыгызны ничек уздырасыз соӊ? — дип куйды бу тагын да бераз баргач. — Иртә йоклыйсыз, ахрысы. Тәрәзәгездә ут күренми.

— Тәрәзәләрне без мендәр белән томалыйбыз, — дигән булдым мин.

— Мәдрәсәләрдәге кебекме?

Аныӊ бу сүзе миӊа бик тапкыр булып тоелды. Мин нәрсә әйтергә дә белми калдым.

— Кичләрен без баскычка чыгабыз, бака тавышы тыӊлыйбыз, — дидем, соӊлап булса да.

— Бака тавышы гармун тавышына караганда күӊеллерәктер ул? — диде Тимерҗан, көлемсерәп.

— Әйе, күӊелле! — дидем мин.

Тимерҗан көлеп җибәрде.

— Тагын ниләр эшлисез? — диде бу, башланган сүзгә өзелергә ирек бирмичә.

— Тагынмы? Китап укыйбыз. Таня татарча өйрәнә. Мин аны өйрәтәм, укытам.

— Кызык. Китаптан карапмы?

— Татарча мин китапка карамыйча да беләм, — дидем мин.

Хәзер инде минем үз сүзләрем миӊа бик тапкыр булып тоела.

— Сез унны кайда бетердегез? — ди Тимерҗан. — Татарчамы, русчамы?

Уку темасы — минем иӊ яраткан темам. Бу турыда мин сәгатьләр буе сөйләшә алам, үз-үземне, дөньямны онытып сөйләшә алам.

Ул төнне без чыннан да дөньяны онытып сөйләштек.

Безнеӊ арада искәрмәстән ниндидер уртаклык барлыкка килде. Мин аӊа үземнеӊ моннан ике ел элек Янавыл татар мәктәбен бетерүем, шуннан соӊ Уфага баруым, конкурстан үтмәвем турында сөйләдем.

Тимерҗанның да язмышы бөтенләй минеке төсле булып чыкты. Ул да моннан ике ел элек урта мәктәп тәмамлаган. Яңавылда түгел, Ямадыда. Ул да минем кебек үк институтка кермәкче булган. Бер үк елны! Ихтимал, Уфага без аның белән бер үк автобуста утырып барганбыздыр әле! Тимерҗан авыл хуҗалыгы институтына керергә исәпләгән. Беренче имтиханда ук «икеле» алган да, кайткан да киткән. Баштарак ул да минем кебек кайтмаска уйлаган. Ләкин аңа кайтмыйча ярамаган. Әти-әниләрен үзләрен генә калдырырга батырчылык итмәгән. Әнисе карт, әтисе аннан да картрак. Җитмәсә, гарип икән, авыр эшкә ярамый икән. Шуның аркасында Тимерҗанны армиягә дә алмаганнар.

Шулай итеп, кайткан да киткән. Кайткач колхозда эшкә йөри башлаган. Нинди эш кушсалар, шуңа йөргән. Механизаторлар курсына җибәрмәкче булганнар — бармаган. Һаман институтка керү турында хыялланган. Кыш көннәрендә имтиханга әзерләнгән. Икенче елны тагын шул ук институтка барып караган. Тагын керә алмаган. Тагын Мәсәгуткә кайтып килгән. Икенче мәртәбә уңышсызлыкка очрау моның барлык хыялларын юкка чыгарган. Шуннан соң бөтенләйгә авылда торып калырга уйлаган. Былтыр көз көне аны бригадир ярдәмчесе итеп куйганнар.

Сөйләшә-сөйләшә без клубны да, пунктны да узып киттек. Урам уртасында өелешеп йоклап утырган казларны уята-уята, авыл башына кадәр барып җиттек. Алдан килешеп куйган кебек, бер сүз әйтмичә, күперне чыктык та, басу юлы белән китеп бардык. Бераздан алда, уң яктарак, караеп ферма каралтылары күренде. Фермага чаклы барып тормадык, кире борылдык.

— Инде бөтенләй укырга исәп юкмы? — дидем мин әкрен генә.

Мин бу сүзләрне эчке бер киеренкелек белән, сагаю-шомлану белән әйттем. Әйтерсең, әгәр дә мәгәр ул киләчәктә минем кебек институтта укырга уйламаса, ниндидер начарлык булырга мөмкин иде.

Тимерҗан эндәшмичәрәк барды.

— Юк дип әйтеп булмый, — диде ул, икеләнгәндәй итеп. — Синең кебек укыган кешеләрне күрсәм, авылга иптәшләр кайтса, студентлар... күңел тузына башлый. Кыен була, көнләшәсең, кызыгасың. Эшкә чыктың исә, онытыла.

— Гомергә шушында, шушы авылда калырга уйлыйсыңмы? — дидем мин, котым алынып.

Үзебез дә сизмәстән без бер-беребезгә «син» дип эндәшә башладык. «Сез»не мин бөтенләй яратмыйм. Элекке байларны хәтерләтә. Аристократияне. «Син» ул шундый якын. Туганың кебек, әтиең-әниең кебек якын.

— Ник, калса ни булган? Мин — шушы авылда туган кеше, — диде бу тыныч кына. — Бөтен кеше шәһәргә китеп бетсә, авылда кем калыр?

Мондый сүзләрне мин кайчандыр ишеткән идемме, укыган идемме — хәтерләмим. Шулай да бу миңа чын күңелдән әйтелгән шикелле тоелды.

— Юк! — дидем мин, һөҗүмгә ташланган сыман. — Дөрес түгел, дөрес түгел! Ун класс бетер дә бригадир ярдәмчесе булып йөре, имеш! Ярый, бригадир да булдың, ди, хәтта колхоз председателе дә булдың, ди. Шуннан соң нишләргә? Гомергә катып калыргамы? Авыл кешесе булып?.. Ышанмыйм. Шундый япь-яшь кеше...

Мин дәртләнеп, ялкынланып сөйләдем. Чын күңелдән сөйләдем. Үз сүзләремә үзем нык ышанганга күрә, Тимерҗан да ышаныр дип уйладым. Тимерҗан исә, беравык тын гына барды да, үсүзләнеп:

— Алай түгел ул, — дип куйды.

Ул да моны үз-үзенә ышанып әйтте. Нык итеп әйтте.

— Мин дә баштарак шулай дип уйладым, — диде аннары. — Укырга, укырга! дидем. Безне бит шулай тәрбияләделәр. Ни өчен укырга, кем өчен укырга — рәтләп әйтүче булмады. Без уку өчен укыдык. Үзебез өчен. Укыган кеше шәһәрдә генә түгел, авылда да кирәк. Шуны безгә аңлатучы булмады. Хәзер инә әйтеп карыйлар да, бер дә тәэсир итми. Әзме-күпме язарга-укырга өйрәндеме, шәһәргә таю ягын карый. Институткамы анда, техникумгамы...

Кинәт минем йөрәк сугып куйды. Тимерҗанга берәр усалрак сүз әйтәсем килеп китте. Ләкин тел очына бер генә усал сүз дә килмәде.

— ...институтка, техникумга эләгә алмый икән, һөнәрчеләр мәктәбенә керә, слесарьлыкка, токарьлыкка керә, — диде Тимерҗан. — Анысы да булмый икән, урам себереп йөрергә дә риза. Бары шәһәрдә генә булсын! Мин алай булдыра алмыйм. Шәһәрдә урам себереп йөрүгә караганда, авылда көтүче булу мең артык миңа.

— Кеше көтүчесе булып! — дидем мин һәм искәрмәстән пырхылдап көлеп җибәрдем.

Тимерҗан туктап калды. Миңа карап алды да, бөтенләй үзгәргән, чит бер тавыш белән:

— Көтүче дә кеше, — диде. — Менә... килеп җиттек. Хәзер инде курыкмассыз. Хушыгыз.

Минем йөрәк кинәт урыныннан купкан кебек булды. Каушап калдым. Үземнең ни дәрәҗәдә ахмаклык эшләгәнлегемне әле тулысынча аңлап та җитмәдем, шулай да, сер сынатасы килмичә, тыныч булырга тырышып:

— Хушыгыз. Рәхмәт... китереп куюыгыз өчен, — дидем.

Тимерҗан инбашларын кызу селкетеп, ашыгып китеп барды.

## XVIII

Мин дә үзебезгә кереп киттем. Таня чыгып ишек ачты. Ул әлерәк кенә кинодан кайткан. Йокламыйча мине көтеп тора икән.

— Кайда йөрдең? — ди бу гаҗәпләнеп. Күңеле күтәренке. Күрәсең, кино ошаган.

— Чакырдылар. Бер авыру хатын янына бардым, — дидем сүлпән генә.

Таня минем күңелсезлекне сизеп алды, борчылгандай итеп:

— Нәрсә, хәле бик авырмыни? — диде.

— Авыр, — дидем мин.

Шулай бер-ике сүз сөйләшкәләп үз бүлмәбезгә кердек. Минем эч поша. Елыйсы килә. Үкенү тойгысы бөтен нәрсәнең астын-өскә китерә. Нәрсә булды соң әле бу? Шундый күңелле башланган сөйләшү нишләп шулай күңелсез бетте соң әле?

Чишендем дә урынга яттым. Түшәмгә карап ятам. Күзгә йокы керми. Йокларга тырышмыйм да. Уйланам. Юк, уйланмыйм да. Ниндидер билгесезлек. Бүлмә эче кап-караңгы, тып-тын. Теге якта бүрәнә аша тонык кына булып бала елаган тавыш ишетелә. Уй җепләре шул якка юнәлә. Дөнья кайгысы баскан укытучы агайны, аның йомры, бәләкәй хатынын кызганып куям. Миңа аларны еш күрергә туры килә. Йорттагы бар эшләрен хатыны эшли. Көн-төн печән ташый, сыер сава, бәрәңге бакчасында булаша, ашарга пешерә, балаларын карый. Эшли дә эшли, һич тик торганы юк. Агай шушы арада Янавылда югалып торды. Аны Тау-авылга башлангыч мәктәпкә укытырга куйганнар. Өч чакрым җиргә ул җәяүләп йөриячәк. Ничек йөрер ул анда? Әллә күченеп китәрләр микән? Менә шәп булыр иде! Авыл Советы секретаре инде мине ике мәртәбә котыртып алды. Чыгыгыз дип әйт син аларга, ди. Мин, тиле, чыннан да әйттем: апа, кайчан чыгасыз инде, безгә бүлмә кирәк, дидем; без анда бала табу бүлеге ачарга уйлыйбыз, дидем.

Апаның кәефе кырылды. Шуннан алар безгә рәтләп җавап бирмәс булдылар. Өч балалары белән кая китсеннәр инде алар? Минем өчен барыбер түгелмени? Торалар икән, тора бирсеннәр. Бала табу бүлеге турында уйлап та карамыйлар алар... авыл Советында... Юри генә сөйләнәләр. Безнең тилелектән файдаланалар. Ул секретарь, чыннан да, бик алама кеше. Утыз яшькә кадәр өйләнмәгән. Авылда аны беркем яратмый, диләр. Мәкерле, эчкерле, диләр. Торсалар ни, тора бирсеннәр! Шул балаларны кызганмый ничек куалап чыгарырга кирәк! Агай да кызганыч, хатыны да, балалары да кызганыч.

— Сиңа нәрсә булды? — ди Таня кинәт, мине уйларымнан бүлеп.

— Бернәрсә дә булмады, — димен мин.

— Юк, нидер булган сиңа.

— Кино күңелле булдымы? — дигән булам, сүзне икенчегә борып.

— Бик күңелле булды! — ди Таня.

— Клублары ошадымы соң?

— Ошады. Бик ошады!

— Нәрсәсе ошады соң?

— Бөтенесе дә. Халкы да, клубы да.

— Равил ошадымы соң?

Таня эндәшмичәрәк ята.

— Ул да ошады, — диде, көттеребрәк.

Аннары, никтер Равилне яклыйсы килеп, әйтеп куйды:

— Аксаклыгы гына бар, — диде. — Нәрсәсе ошамаслык? Син теләсә нәрсә диген, ләкин ул миңа ошый. Үзе кыю, шаян.

Мин эндәшмәдем.

— Миңа аның аксаклыгы бөтенләй сизелми, — диде бу, яңадан сүзгә башлап.

Күрәсең, шулай да күңелен тырныйдыр. Тырнамый ни, шәп нәрсә түгел инде ул аксаклык.

Мин тагын берни эндәшмим. Минем тын гына ятуны Таня хупламау дип уйлады, ахрысы.

— Мин үзем дә әллә ниткән чибәр түгел лә! — диде бу бераздан, үз-үзен кимсетеп.

— Син ябык, мин симез, — дидем мин, уфтанып.

— Шулай шул, — диде Таня, сөенеп.

— Юанлыкның беразын гына сиңа биреп булсыные ул! — дидем мин, буш хыялга бирелеп.

— Үзебез медик, үзебез берни булдыра алмыйбыз, — диде Таня, көлеп.

— Шуның өчен укырга кирәк!

— Нәрсә-ә?

— Бер кешедәге юанлыкны икенче кешегә күчерү өчен!

Мин моны чынлап әйтәм. Бернинди шаярусыз. Таняга бу, күрәсең, кызык тоелды. Миннән көләргә тотынды.

— Ник көләсең? — дидем тупас кына.

— Уку дип саташкансың инде син, — диде Таня бераз тын ятканнан соң, җиңелчә шелтә белән.

— Нәрсә, әллә син дә шушы авылда торып калырыеңмы? — димен, әтәчләнеп.

Мин моны тиргәшкәндәге кебек усалланып әйттем.

— Чынлап, тилергәнсең син, — ди Таня.

— Тилерсә тилерер, әйт: гомергә шушында торып калырыеңмы? — дип кычкырам мин. — Шулкадәр белемең була торып, сәләтең була торып, шушы караңгы авылда торып калырыеңмы?

— Ник калмаска, туры килә икән... кирәк икән, ник калмаска? — ди Таня, уйланып.

— Ә уку?

— Мин инде үземә кирәген укыган. Миңа җиткән.
— Ничек оялмыйсың шулай дип әйтергә?! — димен мин, кызганнан-кыза барып. — Ярь-яшь көеңә! Шундый дипломың була торып!
— Нәрсәсеннән оялырга аның?
— Киләчәктә нишләргә уйлыйсың соң син?
Шулай димен дә, нәрсә әйтер икән бу дип, тынып калам. Мин моны үземчә бик авыр сорау дип, бик туры куелган сорау дип исәплим. Ләкин Таня һич тә аптырап тормый, гап-гади нәрсә турында сөйләгән кебек, тыныч кына:
— Бер нәрсә дә эшләргә уйламыйм, — ди. — Үз эшемне тиешенчә эшли алсам, миңа шул җиткән.
— Юк, ул гына җитмәгән! Син дә укырга тиеш, институтка керергә тиеш! Ничек кенә авыр булмасын, барыбер керергә тиеш!
— Кирәге барые! — ди Таня киреләнеп. — Унбер ел укыдым, җитәр. Тагын биш-алты ел ач торып туберкулез аласым юк.
Мондый сүз ишетеп мин ни әйтергә дә белми аптырап калдым. Җен ачуларым килде. Аның шундый аңсыз, шундый кире булуына, үземнең берни аңлата алмавыма ачуым килде.
— Укыйсым килми, кияүгә чыгасым килә! — дидем, мыскыллап. — Грибоедовның теге Митрофанушкасы кебек...
— Фонвизин... — ди Таня, мине төзәтеп.
— Ярый, Фонвизин да булсын, — димен, кинәт сүрелә төшеп.
Уй җепләре өзелеп, тынып калдым. Шул вакыт мин тагын да Таняның миннән белемлерәк икәнлеген аңлап алдым. Аннан наданрак була торып та, тилереп-тилереп аны укырга өндәвем үземә дә мәгънәсезлек булып тоелды. Шулай да мин үземнең хаклы икәнлегемне бик яхшы аңлыйм. Укырга, укырга кирәк! Бу мәсьәләдә минем карашны беркем дә, берни дә үзгәртә алмаячак!
— Әйт, кияүгә чыгасың киләме? — димен, Таняның эндәшми ятуын күреп.
Мондый туры куелган сорауга Таня ничек җавап бирергә дә белми.
— Син уку турында хыяллангансың, мин хыялланмыйм, — ди. — Нәрсә тагын ми черетергә? Миңа җиткән. Минем үз эшем бар. Бөтен кеше врач булып бетсә, кем акушер булыр? Алты ел буена мине кем туйдырыр?
— Үзеңне үзең туйдырырсың!
— Стипендиягәме? Рәхмәт!
— Дүрт ел торгансың бит әле.
— Тордым. Әни ярдәм итте. Кайчанга чаклы ярдәм итәр ул? Юк, хәзер, киресенчә, мин аңа ярдәм итәргә тиеш.
Мин аңа каршы берни әйтә алмыйм. Билгеле, ул хаклы. Әти-әниләргә ярдәм итәргә кирәк. Ярый әле минем әти эшли. Ул миннән бернинди ярдәм өмет итми. Үзеңне үзең карый алсаң, безгә шул җиткән, кызым, ди. Күңеленнән, бәлки, аның да миннән ярдәм өмет иткән чаклары буладыр. Әйтми генәдер. Нәрсә алып кайтырга икән киләсе атнада? Әти белән әнигә генәме, әллә барысына дамы? Алар бит дүртәү. Өмет итсәләр, барысы да өмет итәдер. Таняның рәхәт — әнисе дә әбисе.
Күңелгә шундыйрак уйлар килә. Минем инде бәхәсләшәсем дә килми. Барысы да надан, барысы да туң баш. Ничек аңламыйлар алар?!
Күңелдә шулай да бер нәрсә калган икән әле.
— Бүгеннән кияүгә чыгарыенмы, Таня? — димен әкрен генә.
— Чыгарыем, — ди Таня. — Яраткан кешем булса... ул мине ратса, мин — аны... Тотарыем да чыгарыем!
— Равилгә дә?
— Ә ник «дә?» — ди Таня, хәтере калып. — Әллә ул кеше түгел?
Мин телемне тешләп тынып калдым. Шул чакны кемдер колак төбендә генә: «Көтүче дә кеше!» диган кебек булды.

## XIX

Икенче көнне без соңгарак калып тордык. Нишләптер Зөһрә дә соңга калган. Минем кәеф кырылды. Көндәгечә иртәрәк килеп уятмаган өчен Зөһрәгә ачуланмакчы да булып карадым, ачулана алмадым. Зөһрәнең дә йөзе чытык. Килеп керде, эндәшмәде-нитмәде, дөбер-шатыр килеп плитәгә ягарга кереште.

— Сиңа тагын нәрсә булды? — дидем, аптырап.

Зөһрә җавап кайтармады, ишетмәгән кеше шикелле кыланып, тышка чыгып китте. Чыккач авыруларга кычкырынып алды. «Нәрсә булган аңа? Кем кушкан аңа кешеләргә кычкырырга?» дип уйладым, ачу белән. Кергәч тә шул турыда үзенә әйтергә дип күңелемә салып куйдым. Ләкин эш сәгате башланганчы Зөһрә бүтән күренмәде.

Юындым да, ашап-эчеп тә тормыйча, кабул итү бүлмәсенә чыктым. Таня бүген Кызыл Ярга, яңа туган бала янына барырга тиеш иде. Татарча әле яхшы аңламаганга, үзе белән Зөһрәне дә алып барыр дип сөйләшкән идек. Мин беренче авыруны кабул иткәндә, каяндыр ашыгып Зөһрә кайтып керде. Минем янда тукталып тормыйча, бу безнең бүлмәгә, Таня янына кереп әйләнде.

— Кызыл Ярга Таня хәзер үк бармакчы була, — диде, миңа каш астыннан карап.

Сөйләшү буенча, Кызыл Ярга алар авыруларны карап бетергәч китәргә тиеш иде. Мин аңлап алдым: Таня түгел, Зөһрә үзе китмәкче була хәзер үк. Берәр ашыгыч йомышы бар микәнни Кызыл Ярда? Дөресен генә әйтсә, ни булган инде!

— Ярый, барыгыз, — дидем, рөхсәт итеп.

Авыруларны мин үзем генә карадым. Үзем кешеләрне сораштырам, үзем әледән-әле тәрәзәгә карап алам, көтеп тору бүлмәсендә ишетелгән тавышларга колак салам. Кемнедер көтәм. Мин аны көтәм.

Мин аны көне буе көттем. Кичкә таба бу көтү газаплы бер тынычсызлыкка әйләнде. Күңелемнән әллә нәрсәләр уйлап бетердем. Ныклап торып уйлап карагач, мин үземнең бик нык гаепле икәнлегемне, бер дә юкка аның хәтерен калдырганлыгымны аңладым. Мин аңа «көтүче», дидем. Дөресен әйткәндә, мин аны үзем дә уйлап тапмадым. Мин аны Зөһрәдән отып калганмын. Шулай да беренче мәртәбә диярлек күргән кешегә шулай дип әйтергә минем ни хакым бар? Мин кем аңа? Беркем түгел. Мин бары Сажидә генә, пункт мөдире генә...

Уйлана торгач, үзем дә сизмәстән, шурләп куйдым.

«Көтүче» дигән өчен әгәр дә мәгәр комсомол җыелышына куеп тикшертсә? Менә аннан булыр!.. Бик мөмкин. Персональ эш, дип. Совет яшьләренә хас булмаган караш, дип. Мещанлык, капитализм калдыгы, дип... Шуннан торып сөйләрләр, кыздырырлар. Безнең Тимерҗанны көтүче дип атаган, диярләр. Ул көтүче булгач, без алайса көтүмени, диярләр. Сезне әллә Уфада шуңа өйрәтеп кайтардылар, иптәш Фәррахова, диярләр, Сез аксөяк, диярләр; безнең комсомоллар арасында андый мораль яктан череп таркалган кешеләр булмаска тиеш, диярләр.

Мин чынлап та куркуга төштем. Тотып кына күрсәтерлек берниндә гаебем булмаса да, үземне мин ниндидер җинаятьче итеп сизә башладым. Баскычка чыгып утыргач та әле озак кына баш ваттым. Бары тик янымa Таня килгәч кенә курку-өркү кимегәндәй булды. Аның чандыр гәүдәсеннән кочаклап алдым да, үз итеп, якын итеп, аны үземә табарак тарттым. Кызыл Ярда күргәннәре турында сораштырдым. Татарча өйрәнгән яңа сүзләрен әйттереп карадым. Шуннан соң Фатыйма-тау ягына, сүнеп барган кызгылт офыкка текәлдек тә, тынып калдык. Таняга да күңелсез, миңа да күңелсез. Икебезгә дә ямансу, бик ямансу.

*(Дәвамы бар)*



# Ерактагы якташларыбыз янында

Тайга естендә сызылып таң ата. Эре йолдызлы, куе зәңгәр тестәге күк гөмбәзе шәмахә төскә керә. Йолдызлар салкын күктә бер-бер артлы эриләр, югалалар. Кар туннары киеп утырган мәһабәт наратлар, йомшак юрганга төренгән агач йортлар салкын кышның биредә тулы хокук белән яшәве турында шигъри тел белән сөйлиләр шикелле.

Тышта шулай. Ә без утырган кечкенә йортның түрендә җылы һәм күңелле. Өй эчендә яз. Өстәлдә чәй кайнап утыра. Йорт хуҗалары стаканнарга шикәр тутыра, бераз уйланып әңгәмәне тагын җанландырып җибәрә.

Николай Борисович Петрушин — Төмән өлкәсе статистика идарәсе начальнигы урынбасары. Статистика дигәч тә, ул саннар белән генә эш итүче кырыс табигатьлә бер кешедер дип уйлаган идем мин башта. Ләкин Коля абый кешеләрне саннардан да яхшырак белә, аларны ярата икән. Ул минем белән чын күңелдән, рәхәтләнеп сөйләшә, районнарның эшләре, планнары турында таныштыра, кешеләр турында дулкынланып сөйли.

Лениногорскидан һәм Әлмәттән, Бөгелмәдән һәм Азнакайдан килеп, инде менә дүрт ел буе җир хәзинәсен казып алуда катнашкан нефтьчеләргә җиткәч, ул салкын кан белән сөйли алмый, табыннан торып китә, ишекле-түрле йөри башлый.

— Моннан ике гасыр элек безнең якларда язучы А. Н. Радищев булган. Һәм ул үзенең көен дәфтәренә:

Ир-арслан булсаң әгәр дә,
Кеше эз басмаган җирдән юл яр син,
Шигырьдә һәм чәчмә әсәрдә...

— дип язган.

Безнең якларның нефтенә беренче тапкыр юл ячуы ир-арсланнарыбыз Татарстан кешеләре булды. Бу кырыс якларның иң караңгы почмакларына беренче башлап алар үтеп керделәр һәм йорт-җир салу өчен беренче казыкларны алар кактылар. Беренче скважинаны алар борауладылар һәм беренче тамчы «кара алтын»ны аларның уңган куллары чыгарды. Күпме җирләрне тикшермәде дә, күпме-күпме хәзинәнең серләрен ачмадылар! Исәпләсәң, исең китәр! Хәзер инде алар поляр түгәрәккә барып җиттеләр!

Сөргенгә җибәрелгән ялкынлы декабристлар Илим утравына Себер аша барганнар. Минем алар эзеннән үтәсем һәм бу якларны егерменче гасыр кешесе күзлегеннән карыйсым килде.

Якташлардан беренче кешене мин Төмән аэропортында ук очраттым. Бу кеше — элек Лениногорскида яшәгән һәм эшләгән танышыбыз Социалистик Хезмәт Герое Александр Григорьевич Тимченко иде. Ул Верховный Совет сессиясеннән кайтып килә икән.

Вышка монтажлау остасы, атаклы бригадир белән бергә утырып, Тобол яклары-ның борынгы юллары, елгалары, караңгы урманнары өстеннән очабыз. Бу юллар, бу сулар күңелләрне еракларга алып китә. Узган гасырларда бөек көрәшчеләрне, зур акыл ияләрен бу кыргый юллардан сөргенгә куганнар. Ә хәзер ул тузанлы юллар белән янәшә корыч тасма сузыла — тимер юл салалар. Ул Төмән белән Сургутны тоташтырачак. Бу — бишьеллыкның удар төзелешләреннән берсе.

Самолеттан караганда, юл буенда кайнашкан машиналар, кешеләр умарта илен хәтерләтә. Шырпы кабы зурлыгындагы вагоннар, кырмыска зурлыгындагы трактор-лар, саргылт ялкынлы кечкенә учаклар күңелне кытыклап, безне сәламләп калалар сыман.

Александр Григорьевич кесәсеннән бик пөхтә итеп төрелгән бер газета ала. Газета эчендә шушы өлкәнең картасы бар икән.

— Карагыз әле: иксез-чиксез киңлекләр бит! — ди ул. — Төмән өлкәсенең мәй-даны гаять зур — өч Франция, Англия, Испания, Швеция һәм Төркиянең барысын бергә кушсаң да, бу мәйданнан кечерәк булачак.

Ул тәрәзәгә карады. Түбәндә зур поселок балкып күренде. Бу бораулаучылар поселогы — Горноправдинск икән. Аның барлыкка килүенә дә әле нибары өч кенә ел.

— Бу якларда революциягә кадәр кеше аягы да басмаган. Ә промышленность турында сөйләп торасы да юк. Хәзер анда ике миллионнан артык кеше яши. Лайсан яңгырыннан соң тишелеп чыккан чәчәкләр шикелле шәһәрләр, поселоклар берьюлы күтәреләләр.

Алда — тагын авыллар, нефть факеллары, вышкалар безгә каршы йөгерәләр.

— Бу якларның шундый мәһабәт җиргә әйләнәчәген элек кем уйлаган? — ди Александр Григорьевич. Үзе шунда ук Себер җирләренең байлыгы турында сөйләп китә.

1932 елда академик Губкин Себер тигезлекләрендә зур байлыклар яшеренеп ят-канын ача, һәм монда тиз арада бораулау эшләре башлана. Шул чакта ук Татарстан егете Рифгать Харисов бу җирдә беренче бораулаучы була. Ләкин беренче бораулау-чылар башлаган көрәшләренең җиңү тантанасын бәйрәм итү бәхетенә ирешә алмый-лар. Коточкыч бәхетсезлеккә дучар булалар алар: вахта тайгада адаша һәм батыр нефтьчеләр, 40—50 градус салкында туңып, һәлак булалар.

Миллион сумнар җилгә оча, нефть тә, газ да чыкмый.

Ләкин буровойларда эш дәвам итте һәм, ниһаять, Казан университетын бетергән яшь геолог Гранит Вәлиуллин 50 нче еллар ахырында бу тирәдә җир асты байлыгы барлыгын яңадан исбатлады. Бу шатлыклы хәбәр Мәскәүгә, Казанга барып җитте, ә аннан яшен тизлегендә дөньяга таралды.

Нефть «Төмәнneке» дип тик административ бүленешкә карап кына әйтелә. Өлкә үзәгеннән алып иң якын нефть ятмасы урынына кадәр мең километр ара бар. Без нефть һәм газ иленә очабыз. Бу яклар Александр Григорьевичка таныш, ә миңа һәрнәрсә яңа, кызыклы. Самолет тәрәзәсенә ак күлле, сазлыклы караңгы тайга карый. Төмәннән ераклашкан саен, урман сирәгәя, кар катламы тираная. Тоболдан башлап горизонтка тоташкан зур сазлыклар еш очрый.

Алда тагын бер сазлык күренде. Хәзерге заман тизлеге белән очып та аның өстен-нән тиз генә үтә алмыйбыз.

Бар җирне боз каплаган, тик кайбер урыннарда тәбәнәк урман һәм буш утраулар күренә. Искиткеч кыргый көч!

Александр Григорьевич: «Төньяк нефть башкаласы — Сургутны шундый зур саз-лар чорнаган», — дип аңлатты. Табигать бу якларда бик кырыс: җәен җылылык 12 градустан артмый, ә кышын салкыннар 50 градустан кимеми. Хәзер бу усал як




Зөлфия Миңнуллина дәрес бирә.

белән нәрәш бара, кем — кемне җиңәр диган сорау алда тора. Кеше үз күзе белән бу бәрелешне күргәч кенә, авырлыкның нинди икәнен белә.

— Революциягә кадәр бу җирләрдә болан һәм этләр генә йөргәннәр, — ди Александр Григорьевич. Себер тарихын дүрт ел эчендә искитәрлек итеп өйрәнгән ул.

Өч сәгатьләп очканнан соң, самолет Сургут аэропортына төште. Бу район урынында кайчандыр Көнбатыш Себер диңгез төбе булган. Хәзер аның астында нефть океаны ята.

Безнең әңгәмәгә якташыбыз, «ИЛ-18» самолетының очучысы Вил Рөстәмов та кушылды.

— Күрәсең, император йортының аппетиты бик үк начар булмаган. Екатерина II нче үз кулы белән язган указында тикмәгә генә аларны «Бөек Император кабинеты җирләре» димәс иде...

Менә дүртенче ел инде Вил пассажирлар ташый икән.

Якташлар белән танышуны миңа атаклы Шәүкәт Сафиуллин экспедициясеннән башларга тәкъдим иттеләр. Юлның озын булачагын, 800 чакрым төньяккарак икәнлеген дә кисәтеп куйдылар.

Ике көн үткәч, «АН-2»дә геологларга таба очабыз. Аста бетмәс-төкәнмәс соры тайга. Сирән генә утырган бораулаучылар поселогы, аучылар алачыгы очрый. Самолет кечкенә күл өстенә җиткәч, кинәт түбәнәя башлады. Алдымда әкияттәге кебек булып бер авыл үсеп чыкты. Тәртипсез урнашкан бүрәнә өйләр. Самолет янына болан җиккән чаналар килеп җитте. Кешеләр ашамлыкларны, почтаны карталарга төяп бетергәч, боланнар поселок ягына җилдәл генә чабып киттеләр. Сейсмологлар моннан 2 километр арырак урнашкан икән.

Мин бу җирләрдә хант һәм мансиларның тирмәләрен, күчмә халыкның таркау тормышын күрермен дип уйлаган идем. Ә чынында исә хантлар хәзер бер урында яшәргә өйрәнгәннәр, аучылык, балыкчылык белән бик оста шөгыльләнәләр икән. Тром-Аган поселогында утызлап йортка ике кибет, интернат-мәктәп, балыкчылар клубы, почта бар. Илле градуслы салкыннарда да мәктәптә укулар туктатылмый.

— Монда тимер кеше булырга кирәк, — ди юлдашым Зөлфия Миңнуллина.

— Сез ничек Себерга элактегез? — дип сорыйм мин аннан.

Ә ул көлә генә.

Алабуга педагогия институтын тәмамлагач, алар, тормыш иптәше белән, тайгага күчеп килгәннәр. Ул геолог, ә Зөлфия бишенче ел инде хант һәм мансиларның балаларына белем бирә. Рәсемнәрне дә яхшы ясый икән Зөлфия, мәктәптә рәсем дәресләре дә алып бара.

— Хант һәм мансиларның балалары пейзажны бик оста ясыйлар. Хәтта тәҗрибәле художник та көнләшерлек, — дип аңлата якташыбыз...

Тайга поселогының тәбәнәк йортлары арасыннан Тром-Аган елгасы ярында кара гына шома бер таш күзгә бәрелә.

Ун ел элек бу урынга геологлар килеп төшкәннәр. Сазлар арасындагы җир кисәген «Беренче үтүчеләр утравы» дип атаганнар. Әлеге таш — җир асты байлыкларын тикшергәндә һәлак булган батырлар истәлегенә куелган ул. Бу тирәләрдән кеше өзелми. Без күргәндә дә анда бер төркем халык иде.

Җылы киемле, рюкзаклы егетләр янында олы яшьтәге иптәшләре дә күренә. Тайгада 30 лап бай нефть ятмасын тапкан геолог Шәүкәт Сафиуллин аларга күптән булып үткән фаҗигале вакыйганы сөйли:

— Гранит Вәлиуллин тапкан җирда нефть фонтаны бәрә башлагач, илебез буенча сөенечле хәбәр таралды. Бу — яшь геологның беренче уңышы иде. Аның турында ишетү белән Гранит буровойга йөгерә. Ташып чыккан шатлыкка түзә алмый, ул ашкынып туры юлдан, сазлык аша йөгерә, әмма мәрхәмәтсез баткаклык аның юлын бүлә...



Александр Тимченко монтажчылар арасында.

Әйе, бу таш Себер байлыкларына беренче юл ачкан геройга һәйкәл итеп куелган. Ә озаклямый яңа йортта тайганы тикшерүчеләрнең данлы юлын сөйли торган музей ачылачак.

Яшь геологлар монда Гранит Вәлиуллинның, аның иптәше Таһир Минюповның, һаман да биредә эшләүче экспедиция начальнигы Ленин орденлы геолог Шәүкәт Сафиуллинның һәм башка егетләрнең батырлыкларына сокланып баш алмыйлар. Эзләүчеләр отрядында Хезмәт Кызыл Байрак ордены кавалерлары: Казаннан килгән электросварщик Григорий Мажаев, Миңвәли Шабаев, Василий Петровлар эшлиләр. Аларны 60 градуслы салкыннар да, көчле җилләр һәм чәнечкеле Себер бураннары да куркытмый. Әнә әле алар хәзер дә учак янында геологик карта белән танышып уты-

ралар. Картага бик еш сибелгән түгәрәклар нефть ятмалары урынын аңлата. Шәукәт аларның һәрберсенә билге куя бара. Шул түгәрәкләрнең берсе, иң зурысы, бай нефть ятмалары урынына беренче утеп керүче кеше — Шәукәт Сафиуллин исемен йөртә икән.

Кичен якындагы планнар турында фикер алышырга экспедиция начальнигы янына геологлар җыелды. Совет властеның 50 еллыгына алар 200 яңа нефть ятмаларын ачарга, җир асты байлыкларын тикшерүне Төньяк Боз океанына кадәр җиткерергә планлаштырдылар.

— Нефть елгасы киңәя, — диде Сафиуллин.

Ләкин әңгәмә дәвам итәргә дә өлгермәде, сүзне шартлау тавышы бүлде.

Мин сагаеп калдым. Ләкин бүлмәдәгеләрнең аңа исе китмәде.

— Салкыннан агачлар шартлый, — диде бер геолог.

Төн кунар өчен без Тимченко бригадасына юнәлдек. Әче җил битне пешерә. «Урал» машинасы көч-хәл белән сейсмологлар шәһәреннән чыга.

— Көне бозылып тора, — диде шофер Ринат Шәрәфетдинов. — 17 нче километрда утырмасак ярар иде...

— Көпчәкләре кеше биеклеге «Урал» ник тоткарлансын, — дип гаҗәпләнәм мин.

— Ничек кенә әле! Хәзер шулай да түзәрлек, авыр машиналар юлны салдылар, әмма төрле вакытлар була, хәрәкәт туктала. Ул вакыт ярдәмгә вертолетны көтәсең.

Менә шөбһәле унҗиденче километр. Алда ике метрлы кар өеме. Шофер моторны сүндерә һәм, чыгып, машинаның саулыгын тикшергәндәй, кулы белән сыйпап куя.

Тирә-якта җилнең сызгыруы, агачларның шартлап ярылган тавышлары өзелми. Томанлы күк йөзенә, җилле тайгага караган саен, бу җирләрне аякка бастыру өчен күпме көч кирәк булганын күз алдыңа китерәсең.

Без тагын кузгалып китәбез. Алда буровой вышкасы күренде. Монтажчылар бригадиры якташыбыз Александр Григорьевич Тимченко аз сүзле, тыйнак, озын буйлы, төз гәүдәле кеше. Тракторлар янына бер төркем кеше җыелган. Монтажчылар Төмән нефть һәм газ төзелешенең бораулау бүлеге начальнигы Иван Васильевич Воевода белән нефть табуны тизләтүдә яңа юллар эзләү турында фикер алышалар. Бораулау



— Киләсе елга бездә җылы да, якты да булачак,— ди Виктор Шадрин.



Трубаны салганда эшләр күп.

вышкасын бер тәүлек эчендә урнаштыру Себер өчен яңа рекорд. Ләкин бу күрсәткечкә егетләр риза түгелләр. Аларның күбесе инде миңа таныш булып чыктылар. Менә Лениногорскидан килгән Николай Литовченко, Петр Гаврилов, Ким Худолей учак янына җыелганнар. Аларның юбилейга алган зур йөкләмәләрен — 36 вышканы җыеп бетерү — үтәү өчен күп көч куясылары бар әле.

— Озакламый «Волга»да йөрербез, — ди Карабаштан килгән тракторчы Габбас Әгълиуллин. Монда кала салачакбыз.

Әңгер-меңгердә Сургут шәһәренә якынлашабыз. Алда горизонт яктылыгында түбә башлары ялтырый. Текә таудан якындагы 5 эр катлы йортларга юнәләбез. Кинотеатр һәм стадионны карыйбыз.

— Обьның аръягында ТЭЦ төзелә, — дип өсти Виктор Шадрин. — Киләсе елга бездә җылы да, якты да булачак.

— Кинотеатрдан сулрак, эре панельле йортлар, ә арттарак нефтьчеләр сарае, — дип Салих Нәфиков та сүзгә кушыла.

Төзүчеләр булачак урамнарны «Әлмәт», «Казан», «Азнакай» дип атаганнар. Ә «Монтажчылар» урамында Тимченко бригадасы яши икән.

— Без килгәнче монда үтә алмаслык сазлыклар һәм берничә генә агач йорт бар иде. Аларда декабристлар яшәгән дигән сүз дә йөри. Үткәндәгене искә төшерү өчен ул йортларны истәлек итеп калдырабыз, — ди маляр Мөнирә Бикчурина.

Шәһәр яңа бишьеллыкка старт алды. Ул үсә, көч ала һәм матурлана. Кара һәм зәңгәр алтын табучы Татарстан нефтьчеләре ямьләндерә аны.

Якташларыбыз Нефтеюганск поселогы турында горурланып сөйлиләр. Өч ел элек ул куе тайгада төзелә башлаган. Сазлыкны ком белән тутырганнар; урманны кисеп мәйдан әзерләгәннәр.

— Хәзер монда ун меңнән артык кеше яши, — ди танылган бораулау мастеры, якташыбыз яшь егет Зәки Әхмәтшин.

Зәки Төмән өлкәсенең төньягында инде 4 ел яши. Әлмәттә нефть институтын тәмамлагач, шушы якларга күчеп килгән. Башкалар белән бергә ул да беренче йортның нигезен салган.

Төп эш — бораулау башлангач та ул беренчеләр рәтендә бара. Зәки бер станокка елга дүртәр мең метр ара узып, бораулау буенча узенчәлекле рекорд куя.

Ул күбесенчә «безнең Себер», «безнең Казан», «безнең Әлмәт», «безнең Нефтеюганск», — дип сөйли. Бу чандыр, тынгысыз егет бөтен байлыкны «безнеке» диючеләр токымыннан икән. Күрәсең, нефтьчеләр аны тикмәгә генә өлкә Советына депутат итеп сайламаганнар.

— Моннан бернечә адым алдарак әллә шәһәр, әллә поселок дигәндәй, Усть-Балык урнашкан. Тайгада мин аның турында күп нәрсәләр ишеттем, әмма күз алдыма ачык итеп китерә алмый идем. Самолеттан Обь елгасы буенда торган алты йортны күрдем. Менә шушыннан инде Төмән нефте башлана, моннан ягулык океаны агып чыга. Аның белән бөтен илебез бәйләнгән. Кечкенә йортлар тирәсеннән 3 нефть магистрале юл ала.

Мин тагын бер якташыбыз белән очраштым. Зур белемле, Хезмәт Герое йолдызы таккан кешене кунакка килгәндер дип уйлаган идем. Чынында исә бу кеше — механикалаштырылган колоннаның начальнигы Идрис Ибраһимов булып чыкты. Аның данлы эше турында мин тик ишетеп кенә белә идем.

Бу җирдә туган батырлыкның чын икәнлеген, үтә алмаслык сазлыкларын күреп, поход вагоннарында йоклап, карларына батып карагач кына ышанасың һәм ул батырларның көченә сокланасың.


Бик еш кыска гына вакыт эчендә очрашып, озакка истә калырлык кешеләр белән аралашасың. Идрис һәм аның коллективы шундыйларның берсе. Ибраһимов буйга озын түгел, яшүсмерләрчә төз, матур йөзле, салмак характерлы. Ул, күрешү белән, туган Татарстаны турында сораша башлады.

— Безнең анда чәчәк атар вакыт җитә, ә монда салкынга тимер чыдамый, — ди ул.

Ул инде дүрт тәүлек трассадан кайтмаган, бик арыган. Трубаларны салганда эшләр күп, карап, тикшереп кенә бетер. Тонналы трубалар салкыннан чатныйлар.

Быел танкерлар нефтьне Усть-Балыктан түгел, ә Демьянск авылы янында алачаклар икән. Омскига кадәр юл алар өчен 700 километрга кыскарачак!

Тайга һәм сазлыклар белән көрәшне безнең якташлар Мәкъсут Гәрәев, Альберт Гатауллин, Сафа Булатов башлап җибәрделәр. Самолеттан туры юл әзләделәр, кү



Хәзер биредә бишьеллыкнын удар төзелеше.

*Автор фотолары.*

агачларны кисеп, сазлыклар аша туры юл тәзи башладылар. Озакламый кышкы йортлар төзелеп бетте, вагоннар да китерелде.

Алтмыш градуслы салкыннар җирне гранитка әверелдерә. Мәхмүт Шәйхисламов, Салман Идрисов һәм аларның иптәшләре нефтьүткәргечләр өчен канау ясый башладылар, әмма сазлыклы урыннарга керә алмадылар. Кыш айлары юл салучыларга ярдәм дә итә икән. Январьда салкын — 63 градус булды. Тирә-якны калын боз катлавы каплаган. «Маз»лар, «Ураган» һәм «Краз»лар трубалар ташырга керешкәннәр. Шофер Әхмәт Җәлилов 33 әр метрлы биш трубаны зур сазлык өстеннән алып чыккан. Калын боз катлавы йөз тонналы авырлыктан да чатнамаган.

Тайгада иң авыры — бульдозерчы һәм җир казучыларга туры килә. Омскига кадәр 1380 километр араны казырга кирәк. Каты җир кабыгын шартлагычлар ярдәме белән генә ватып була.

Трассада трубалар күренгәч, бөек Октябрьның 50 еллыгына Омск шәһәрендә нефть фонтаннары белән салют бирергә, дигән өндәмә төзелеш буенча яңгырады. Хәзер һәр бригада, һәр эшче шушы уй белән яна.

Илебезнең иң төньяктагы нефтьүткәргече янында Татарстан егетләре — Әхтәм Шәрипов, Мирсәй Тимершаехов, Самат Габдуллин, Расих Һидиятуллиннар очрадылар. Алар «Дуслык» җир асты магистрален һәм «Бохара-Урал» газүткәргечен төзеделәр, ә хәзер себерлеләргә ярдәмгә килгәннәр.

Соңыннан мин аларның гаиләләре белән дә таныштым. Ибраһимовның 2 яшьлек улы бар. Ул Белоруссиянең ерак Мысь авылында туган. Бу вакытта Ибраһимов гаиләсе «Дуслык» трассасы буйлап күчеп йөргән.

— Трассачы диңгезчегә, очучыга охшаган. Туган якка — Азнакайга кайтып төзелештә эшли башладым, ләкин йөрәк үзенекен итте, түзмәдем һәм бер елдан соң үз эшемә кире кайттым, — дип, һөнәре турында сөйләде Самат Габдуллин.

Хәерле юл сезгә, өлгер егетләр. Бөек әдип Радищев сезнең тоным киләсен ул вакытта ук күргән, сез эшлисе эшләрне, сез күрсәтәсе батырлыкларны белгән икән...

Н. ГАЙНУЛЛИН.

Январь, февраль, 1967.

— — □ — —

# әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## ӘҺӘМИЯТЛЕ ВАКЫЙГА

СССР-Япон яшьләренең Казанда үткәрелгән III нче дуслык фестивале август аеның истәлекле вакыйгаларыннан булды. Бу көннәрдә шәһәребез урамнары русча, татарча, японча язылган транспарантлар, лозунглар һәм ал, кызыл, сары, яшел, зәңгәр төсләрдә җилфердәгән спорт флаглары белән бизәлгән иде. Бакчаларда, паркларда, су буйларында, спорт мәйданнарында бу ике илнең милли көйләре яңгырап торды. Иделнең иң матур җирендә, яшел нарат урманында, архитектураның иң соңгы казанышларын файдаланып салынган «Волга» спорт лагеренда, шәһәребезнең спортлар Сараенда, Үзәк стадионда һ. б. җирләрдә рус, татар, япон халыкларының уеннары, милли көрәшләре, спорт ярышлары уздырылды. Кунаклар яшәгән «Волга» лагеренда татарның милли бәйрәме — сабан туе үткәрелде. Ике ил яшьләре арасында промышленность һәм экономика, әдәбият һәм сәнгать, дөнья хәлләре һ. б. темаларга кызыклы бәхәсләр, фикер алышулар булды. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында япон сәнгать эшлеклеләре белән булган очрашуда һәм «Грузия», «Белоруссия» теплоходларында Идел буйлап йөргәндә язучылардан Мирсәй Әмир, Гариф Гобәй, Зәки Нури, Хәй Вахит, Рөстәм Кутуй, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Гөлшат Зәйнашева һ. б. иптәшләр катнашты.

## ИЛЬИЧ БУЛГАН ЯКЛАРДА

Даһи Ленин биографиясенә бәйле булган урыннарга сәяхәт итеп, бер төркем Ленинград язучылары август башларында Казанга килделәр. С. В. Ботвинник, Е. А. Вечтомова, Е. П. Серебровская һ. б. лардан торган бу группа шәһәребезне карап йөрде, Ленин исемен йөрткән университетта булдылар һәм журналистлар белән очраштылар, кичен телевидениедән чыгыш ясадылар.

Алар үзләренең бу сәяхәтләрен Октябрьның 50 еллыгына багышлыйлар.

## ХАЛЫКНЫҢ ЗУРЛАВЫ

Җырларда, дастаннарда җырланган Ирәндек-тау итәгендә утырган Баймак каласында (Башкортстан республикасы) татар, башкорт һәм башка тугандаш халыклар өчен әһәмиятле вакыйга булды: күренекле татар совет драматургы Мирхәйдәр Фәйзигә бюст куелды.

Халыкның бар әчке моңын үзенә туплаган һәм шуны искиткеч талантлы әсәрләре аша аның үзенә үк бүләк итеп кайтарган бу әдипне Баймак тирәсендә яшәүче бар халык үз итеп якын күрә. Чөнки 20 нче еллар уртасында Мирхәйдәр Фәйзи Баймактан 25 км чамасы ераклыктагы татар авылы Юллыкта яши. Ул анда үзенең «Юллык шигырьләре»н һәм башка күп кенә әсәрләрен иҗат итә.

Язучының бюсты Баймак шәһәренең үзәк урамында китапханә каршында куелды. Бюст бик уңышлы эшләнгән. Гимнастерка кигән, күзлекле, какча сынга карап торасың да «әллә тере микән» дип уйлап куясың.

Һәйкәлне ачу көне чын мәгънәсе белән тантанага әйләнде, анда район хезмәт ияләреннән йөзләрчә кеше катнашты.

## ЛАЕКЛЫ БҮЛӘК

Татар балалар әдәбиятында озак еллар эшләгән, аны баетуда зур көч куйган, әсәрләре белән татар укучыларына гына түгел, рус, казакъ, үзбәк һ. б. халыкларга да яхшы таныш булган Гариф Гобәйгә 60 яшь тулды. Язучылар җәмәгатьчелеге юбилярның иҗат бәйрәмен тантаналы төстә билгеләп үтте. Хөкүмәтебез аның хезмәтенә югары бәя бирде — аны «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләде. Без зур бүләк алуы белән каләмдәшебезне тәбрик итәбез, аңа озын гомер һәм зур иҗади уңышлар телибез.

## ӘДИП ИСЕМЕ БЕЛӘН

РСФСР Министрлар Советының 1967 ел 5 август карары белән СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтына язучы Галимҗан Ибраһимов исеме бирелде.

* * *

Казан шәһәренең 89 нчы мәктәбе дә яңа уку елын бөек әдипнең исеме белән каршылаячак, РСФСР Министрлар Советы карары буенча ул Галимҗан Ибраһимов исемендәге 89 нчы урта гомуми хезмәт политехник мәктәп дип исемләнә.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА КУНАКЛАР

Август аеның кояшлы бер көнендә Татарстан язучылар союзына кунак булып, «Александр Суворов» крейцерының капитан ярдәмчесе Якуб иптәш Ибраһимов килде. Крейцерда хезмәт итүче моряклар шагыйрь Муса Җәлилгә багышлап агит-кубрик оештырганнар икән. Кунак язучыларны шул кубрикның эше белән таныштырды. Киткәндә Муса Җәлил сүзләренә язылган җырлар һәм бик күп татар китаплары алып китте.

* * *

Озак та үтмәде язучылар җәмәгатьчелеге тагын бер кунакны — «Муса Җәлил» теплоходының капитан ярдәмчесе И. К. Кушаевны каршылады. И. Кушаев язучыларга экипажның сәламен тапшырды. Ул океан суларын гизүче «Муса Җәлил»дәге тормыш турында, илебездә эшләнгән товарларны дөньяның кай якларына илтүләре, чит илләрдә күргән хәлләр h. б. лар турында бик күңелле итеп сөйләде. Соңыннан язучыларны кызыксындырган бик күп сорауларга җаваплар бирде. Бу күңелле очрашуларда язучылардан М. Әмир, Г. Гобәй, Р. Мостафин, Г. Кашшаф, Ә. Еники, И. Юзеев һәм С. Сабиров иптәшләр катнашты.

## ЧИТ ИЛГӘ СӘЯХӘТ

Узган ел, татар халкының классик шагыйре Г. Тукайга 80 яшь тулу көннәрен бәйрәм иткәндә, шәһәребезгә күп кенә җирләрдән кунаклар килгән иде. Алар белән бергә Финляндиядән Хельсинки университеты профессоры Гомәр Таһир да Казанда булып, шагыйрьнең юбилей тантаналарында катнашты. Бу ел ул бер төркем галимнәрне Хельсинкига кунакка чакырды. Филология фәннәре докторлары язучы Мөхәммәт Гайнуллин һәм язучы Хатип Госман, филология фәннәре кандидаты Резеда Ганиева иптәшләр бу чакыруны кабул итеп, шушы елның август аенда Финляндиядә булып кайттылар. Алар анда ике атналап тордылар.

## УКУЧЫЛАР ФИКЕРЕ

Республика балалар китапханәсе туган якны өйрәнү темасы буенча укучылар арасында сорау үткәрде. Укучы балаларга тәкъдим ителгән анкетада түбәндәге сораулар бар иде:

1. Туган шәһәреңне син ни өчен яратасың?
2. Туган шәһәрең һәм аның атаклы кешеләре турында нинди китаплар укырга теләр идең?
3. Октябрьның илле еллыгына багышлап Татарстан язучыларының нинди әсәрләр язуын теләр идең?
4. Республикабызда чыга торган «Комсомолец Татарии» һәм «Татарстан яшьләре» газетасын укыйсыңмы?
5. Туган ягыңның тормышы турында газета-журналларда басылган материалларның кайсысы кызыксындырды?
6. Туган якны өйрәнү буенча нинди темаларга әдәбият җыйдың?
7. Китап сайлаганда «Татарстан язучылары балаларга» дигән кулланмадан файдаланырга туры килдеме?
8. Татар язучыларының нинди китаплары сиңа бик ошады?

Сорауларга укучы балаларның зәвыкларын, теләкләрен, аң дәрәҗәләрен күрсәтә торган күп кенә җаваплар алынды.

Без түбәндә анкетаның өченче соравына килгән җавапны гына урнаштырабыз.

Бу сорауга Казан шәһәренең 33 нче мәктәбеннән 6 класс укучылары мондый теләк белдерәләр:

Татарстан пионерлары турында язылган китапны укыйсы килә дип 5 укучы хәбәр бирә.

| | |
|---|---|
| Бөек Ватан сугышы геройлары турында — | 3 укучы. |
| Татар революционерлары турында — | 2 укучы. |
| Батырлык турында — | 1 укучы. |
| В. И. Ленин турында — | 6 укучы. |
| Казан турында шигырьләр — | 2 укучы. |
| Шәһәребез тарихы турыда — | 2 укучы. |
| Татар егетләренең чик буенда сакта торулары турында — | 1 укучы. |
| Октябрьга багышланган шигырьләрне — | 2 укучы. |
| Татар халкының Октябрьга кадәр тормышы турында — | 1 укучы. |
| Шәһәребезнең балалары турында — | 2 укучы. |
| Бөек Ватан сугышы елларында Казан халкының фронтка ярдәме турында — | 2 укучы. |
| Октябрь революциясе вакыйгалары турында — | 2 укучы. |
| Татарстанның гади кешеләре турында — | 5 укучы. |
| Октябрь һәм гражданнар сугышы геройлары турында — | 3 укучы. |
| Татарстанның хәзерге көне турында — | 1 укучы. |
| Татарстанның спортсменнары турында — | 1 укучы. |

Шундый ук теләкләрне башка мәктәп укучылары да әйткәннәр. Мәсәлән, 83 нче мәктәпнең 6 класс укучылары югарыда китерелгән темалардан тыш Казанның киләчәге, Татарстанның иң-иң беренче коммунисты, Казанка елгасы турында, кызылларның Казанны аклардан азат итүе һәм шул көрәштә балаларның катнашуы, Казан Кремленең тарихы һ. б. лар турында язылган китапларны укырга теләүләрен әйтәләр.

## ОНЫТЫЛМАС КӨН

25 август — патриот шагыйрь Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең дошман кулыннан һәлак булган көне.

Бу иртәдә башкаладан кайтучы «Татарстан» поездыннан бер кәрзин чәчәкләр төшерделәр. Үт янып торган бу кызыл канәфер чәчәкләрен Муса Җәлилнең тормыш иптәше Әминә ханым Җәлилова белән шагыйрьнең кызы Чулпан җибәргәннәр һәм бу чәчәкләрне Муса Җәлил һәйкәленә куюны үтенгәннәр.

Бу көнне данлы шагыйрьнең Казандагы дуслары һәм каләмдәшләре дә һәйкәл янына килгәннәр иде. Алар да, көне буе һәйкәл янынан китмәгән халык та үзләренең шагыйрьгә булган җылы хисләрен, хөрмәтләрен белдерделәр.

## «САРМАН ЧӘЧӘКЛӘРЕ»

Моннан берничә ел элек композитор Мәсгут Латыйпов Сарман районы укучыларыннан торган тынлы инструменталь ансамбль оештырган иде. «Сарман чәчәкләре» исемен алган бу ансамбль тиз арада халыкка танылып өлгерде. Аның чыгышла-

рын һәркайда яратып тыңлыйлар. Ансамбльдә «Беренче Май», «Җиңү», «Татарстан» һәм Серго исемендәге колхоз мәктәпләреннән җыелган 120 укучы кыз бар.

Бөек Октябрьның 50 еллык бәйрәменә багышлап әзерләгән программалары белән алар 11 августта Казанга килделәр. Казан телевидениесе буенча һәм М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркында чыгышлар ясадылар.

* * *

Казанның ял паркында август ахырларында тагын бер күңелле кичә уздырылды. Биредә «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе укучылар белән очрашу үткәрде. Бу кичәдә язучы Фатих Хөсни дә катнашты. Ул тыңлаучыларга язучыларның иҗат планнары турында сөйләде, язучының халык белән аерылгысыз булуын әйтте һәм язучылык осталыгы мәсьәләләренә кагылып, халыкның йөрәгенә үтә белерлек әсәрләр язарга, сүздә җыйнак, төгәл булырга кирәклегенә тукталды.

## КОНЦЕРТ ЗАЛЛАРЫНДА

М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында атаклы биюче Мәхмүт Әсәмбаевның чыгышлары булды. Искиткеч талантлы белән дөнья халыкларына таныш булган Эсәмбаевны Казан халкы икенче тапкыр инде яратып карый. Дөнья халыкларының милли биюләреннән торган программасында бу юлы «Башкорт аучылары» дигән яңа номер да бар иде.

* * *

Соңгы елларда республикабыз тамашачылары чит илләрдән килгән сәнгать осталары белән еш кына очрашалар. Күптән түгел генә Казанга Югославиянең «А В С» эстрада ансамбле килде. Аның чыгышларын казанлылар алкышлап каршыладылар. Югославия артистлары нефть районнарында да булдылар.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Азнакайда Мәхмүт Хәсәновның «Саф җилләр» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Конференциядә районның колхоз председательләре, терлекчеләре, китапханә мөдирләре катнашты. Соңыннан автор сорауларга җавап бирде.

* * *

Бюроның киңәйтелгән утырышында Татарстан нефтенең 20 еллыгына карата очерклар китабын язучы Ф. Мостафин, Ш. Бикчурин отчетлары тыңланды. Фикер алышуда катнашкан Ә. Маликов, Г. Афзал, Г. Ахунов китапның композициясе, эчтәлеге турында үз фикерләрен әйттеләр.

* * *

Әлмәт промышленность предприятиеләренең башлангыч комсомол оешмалары секретарьлары семинарында Г. Ахунов катнашты. Ул СССР язучыларының IV нче бөтенсоюз съезды турында, Татарстан язучыларының, шул исәптән Әлмәт бүлегенең дә, бөек юбилейга ничек әзерләнүләре, аерым язучыларның хәзер нинди әсәрләр язулары турында сөйләде.

* * *

Р. Төхфәтуллинның «Агымсу» исемле яңа повесте буенча бүлек утырышында фикер алышу үткәрелде. Чыгыш ясаучылардан Г. Афзал, Г. Ахунов, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, Ф. Мостафин, Ш. Максудова, А. Ганиев авторның әле моңа кадәр кул тимәгән яңа өлкәдә — нефтьчеләр белән колхоз авылы кешеләренең үзара мөнәсәбәтләре турында повесть язуын хуплап, әсәрнең нигезе нык булуын билгеләп уздылар. Повестьны камилләштерү өчен киңәшләр әйтелде. Нефть чыгаручы инженер С. Вәлиуллин да повесть белән алдан ук танышып, фикерләрен язма рәвештә язып җибәргән иде.

* * *

Ә. Маликов, Г. Ахунов, Г. Афзал Язучылар союзы бүлегендә чит ил журналистлары Эрнст Бах (ГДР), И. Лужанска (Чехословакия) белән очрашып, яшь нефтьчеләр каласы Әлмәт турында, аның культура тормышы турында әңгәмә үткәрделәр. Очрашуда АПНнан Г. Филатов, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре С. Хәкимова һәм шәһәр газетасы сотрудниклары катнашты. Халык демократиясе илләреннән килгән журналистлар иртәгесен, 14 июльдә, Чупай таш карьерында һәм шәһәрнең промышленность предприятиеләрендә хезмәт ияләре белән очрашып, язачак очеркларына материал тупладылар. Аларны Әлмәт язучылары Г. Ахунов, Ә. Маликов, С. Сөләйманова озатып йөрделәр.

* * *

Башкортстаннан килгән яшь язучы Х. Зариповның «Кала кызы сөйгәнем» исемле комедиясе һәм «Урланган гомер» романы буенча Әлмәт бүлегендә индивидуаль семинар үткәрелде.

* * *

Бүлекнең киңәйтелгән утырышында «Театр һәм драматургия» дигән темага сөйләшү булды. Язучылардан Г. Ахунов, С. Кальметов, Ш. Бикчурин, Г. Афзал, Әлмәт театрының баш режиссеры С. Өметбаев, театр директоры М. Шәйхетдинова, режиссерлар З. Туишева, К. ХаЛәпов, артистка Р. Гобәйдуллина фикер алышуда катнашып, бүгенге сәхнәнең, аерым алганда Әлмәт театрының, бурычлары, якын киләчәктә эшләргә тиешле эшләре хакында сөйләделәр. Әлмәт театрының шәһәрдә яшәүче драматурглар ярдәмендә үзенчәлекле репертуарын булдырырга дигән карар кабул ителде. Театр эшлекләләре Октябрьның 50 еллыгы уңае белән Әлмәт театрының эшен, коллективын халыкка пропагандалауда язучыларның ярдәм итүләрен сорадылар.

«Хезмәт байрагы» газетасында, яшь авторлар иҗатына багышланып, ике мәртәбә әдәби сәхифә чыгарылды.

# Әхмәт Ерикәй



Совет әдәбияты зур югалтуга дучар булды: күренекле татар шагыйре Әхмәт Фазлый улы Ерикәй үлде. Тирән хисле һәм тормыш сөюче шагыйрь социалистик Ватаныбыз һәм яңа кеше — төзүче һәм көрәшче турында дәртләнеп җырлады.

Әхмәт Ерикәй 1902 елның 16 декабрендә Башкортстан АССРның Дуван районындагы Өлкәнде авылында туган. Ул яшьләй үк халыкның якты һәм яхшы тормышы өчен көрәшенең иң алгы участокларында була, хезмәт ияләре белән иң якын бәйләнештә тору үрнәген күрсәтә.

Тарихи елда — Ленин призывы елында Коммунистлар партиясе сафына кергән Ерикәй үзен партия һәм халык җибәргән урыннарда эшләде: ул ВКП(б)ның Олы Ока волость комитеты җаваплы секретаре, аннары Мәсәгут кантонында халык судьясы, ВКП(б)ның кантон комитеты пропаганда бүлеге мөдире булды.

1927 елда Әхмәт Ерикәй Мәскәү журналистика институтына керә, уку белән бер үк вакытта үзәк татар газеталарының секретаре, аннары редактор урынбасары булып эшли. Киң колачлы художник яшьләр өчен «Ударниклар» әдәби журналын оештыручыларның һәм редакцияләүчеләрнең, пролетар язучыларның Мәскәү ассоциациясендә татар секциясе җитәкчеләренең берсе була. Әхмәт Ерикәй 30 нчы елларда илебезнең күп районнарында була, «Правда», «Комсомольская правда», «Литературная газета» һәм үзәк журналлар битләрендә очерклары һәм шигырьләре белән актив катнаша.

1941 елда, Советлар Союзына гитлерчылар һөҗүм иткәч, шагыйрь фронтка хәрби хәбәрче булып китә, «Ватан намусы өчен» дигән фронт газетасы редакторының урынбасары булып эшли.

Әхмәт Ерикәйнең поэзиясе гражданлык пафосы белән сугарылып тора. Аның поэзиясе совет халкының уй-хисләренә һәм омтылышларына аваздаш яңгырый. Нәрсә турында гына язса да, аның әсәрләре ялкынлы патриотизм хисе белән сугарылды, аның шигъри юлларында һәм җырларында халык арасыннан чыккан замандашыбыз образы гәүдәләнде.

Бөек Ватан сугышы елларында шагыйрь Совет Армиясе сугышчылары турында шигырь һәм очерк китаплары бастырды. Аның үзәк газеталарда һәм журналларда басылган сугышчан шигырьләре Ак диңгездән алып Кара диңгезгә кадәр фронтның барлык участокларында яңгырады. Армиядән кайтканнан соң Әхмәт Ерикәй Татарстан язучылар союзына җитәкчелек итте (1945—1950 еллар), актив иҗади эшчәнлеген дәвам иттерде.

Әхмәт Ерикәйнең зур әдәби мирасында рус һәм татар телләрендә шигырь һәм җыр җыентыклары уннарча исәпләнә. Аның әсәрләре күп тапкырлар тугандаш республикалар халыклары һәм чит илләр телләренә тәрҗемә ителде.

Шагыйрь җыр жанрында аеруча нәтиҗәле һәм рухланып эшләде. Аның җырлары халык арасында киң таралды.

Әхмәт Ерикәй илебезнең һәм республикабызның җәмәгать тормышында актив катнашты. СССРның икенче һәм өченче чакырылыш Верховный Советлары депутаты итеп сайланды. Шагыйрьнең әдәби һәм җәмәгать эшчәнлегенә зур бәя бирелде: ул Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнде.

Талантлы шагыйрь коммунист Әхмәт Ерикәй истәлеге каләмдәш дуслары күңелендә мәңге сакланыр.

* * *

Ә. Ерикәйнең гәүдәсе Мәскәү үзәгендәге Ваганьков зиратында 8 сентябрьдә җирләнде. Матәм митингысында Мәскәү язучылары һәм укучылар җәмәгатьчелеге, шулай ук Татарстан язучылары коллективы исеменнән Г. Кашшаф, З. Нури, Л. Хәмидуллин иптәшләр катнашты. Язучылардан А. Жаров, Н. Сидоренко, З. Нури, композитор С. Кац мәрхүм белән хушлашу сүзе әйттеләр.

*Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый*


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж*

Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары»*

## Бу санда:

Ә. Давыдов. Октябрь кояшы. Шигырь . . . 2
Ф. Миннуллин. Якты юллар сызып. Мәкалә . . . . . . . . . . . . . . 4
А. И. Ульянова-Елизарова. Казандагы тормыш. . . . . . . . . . . . . . . . 13
А. Расих. Ямашев. Роман. . . . . . . . . . 15
И. Гази. Кызыл томаннар артында. Хикәя. . . 55
М. Гафури. Кызыл байрак. Шигырь. . . . . . 61
И. Йосфи. Байларга. Шигырь. . . . . . . . 61
С. Сабиров. Дулкыннар ни сөйли. Очерк. . . 62
Р. Һидиятуллин. Ялкынлы елларда. Истәлек. 67
С. Данильченко. Чапаев Казанда. Истәлек. 73
Үткән еллар сәхифәсе. . . . . . . . 77
Х. Туфан. Кояш... Уралда. Завод ябылгач. Каспий яры. Уйланулардан. Татарстан бу. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . 84
Татар мәдәниятының көндәлек дәфтәреннән. . . . . . . . . . . . 88
Кабатланмас документ. . . . . . . . 91
Һ. Такташ. Алтын сарайларга. Шигырь. . . . 92
М. Хәмитов. Солдат даны. Очерк. . . . . . 93
М. Җәлил. Кошчык. Шигырь. . . . . . . . 104
С. Сөләйманова. Җир-су. Поэма. . . . . . 105
З. Нури. Яз көнендә туган кешегә. Шигырь. . . 115
С. Хәким. Яшьлегем искә төшереп. Шигырь . . 116
Ә. Баянов. Тыйнак кеше турында баллада. . . 117
Н. Фәттах. Мөдир Саҗидә. Повесть. . . . . 118
Н. Гайнуллин. Еракта гы якташларыбыз янында. Очерк. . . . . . . . . . . . . . 148
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . . 156

—— □ ——

*Журналның тышлыгын һәм художество оформлениесен художник Т. Хаҗиәхмәтов эшләде.*


Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/VIII-1967 ел. Басарга кул куелды 22/IX-1967 ел. ПФ 09030. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 56 346 экз. Заказ М-1329. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

# *ТАБЫН ҖЫРЫ*




А. КЛЮЧАРЕВ музыкасы
Н. АРСЛАНОВ сүзләре

Күтәр бокалларны,
Бөек даулы таңда
Кышны сарай алган
Ирләр хөрмәтенә:
Халыкларга ирек,
Шатлык, бәхет биреп
Ялкыннарда янган
Көннәр хөрмәтенә.

Яулар айкап йөргән,
Мәйданнарда җиңгән,
Гаҗәп дастаннарга
Тиңнәр хөрмәтенә.
Көрәш юлларында,
Сугыш кырларында
Мәңге ятып калган
Ирләр хөрмәтенә.

Күтәр бокалларны,
Тынычлыкны саклар,
Дөреслекне яклар
Җаннар хөрмәтенә,
Бөтен дәртен биреп,
Ярышларда җиңеп,
Эштә батыр калган
Саулар хөрмәтенә.

Бәйрәм шаулый, көлә!
Күз алдына кила
Бөек Октябрьның
Дәртле, ал таңнары...
Ватан хөрмәтенә
Алыйк бокалларны!

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

# Казан утлары

**(ОГНИ КАЗАНИ)**

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210